# Казан утлары

ноябрь № 11
1965

*Бөек Октябрьның*
*48 еллык бәйрәме белән*
*сезне, хөрмәтле укучыларыбыз,*
*чын күңелдән*
*тәбрик итәбез!*

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
*КЫРЫК ДҮРТЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

НОЯБРЬ **11**

РЕСПУБЛИКА ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАРЫ НӘШРИЯТЫ
КАЗАН 1965

## Бу санда:

### РОМАН, ХИКӘЯЛӘР, ШИГЫРЬЛӘР

Н. Арсланов. **Туган илем.** Шигырь . . . . . . . . . 3
Ш. Маннур. **Муса.** Роман. Ахыры . . . . . . . . . . 4
Г. Афзал. **Моң. Онытыма хат. Әрем.** Шигырьләр . . . . . 90
Р. Әхмәтҗанов. **Лирик әкият. Каеннарны үт тә. Җирдә июнь. Кар астында...** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 92
Г. Латыйп. **Озата һәм каршы ала. Атна түгел... Ай үтә, еллар үтә дә.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 94
Г. Рәхим. **Песнәк. Бәре тышчасы. Апрель. Алдауны яклау. Омтылыш.** Лирик парчалар . . . . . . . . . . . 97
Р. Фәйзуллин. **Нюанслар иле.** Шигырьләр . . . . . . 101
Г. Зәйнашева. **Ак чәлтәр уйларым. Язгы кичтә.** Шигырьләр 110

### ЯЗУЧЫ ТРИБУНАСЫ

Г. Әпсәләмов. **Түгәрәк өстәл янына** . . . . . . . . . 111

### М. ҖӘЛИЛ ЮБИЛЕЕН КАРШЫЛАП

Р. Мостафин. **Муса туган якларда.** Фоторепортаж . . . . 120

### Х. ХИСМӘТУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Ш. Абилов. **Хезмәттә яуланган хөрмәт** . . . . . . . . 123

### ПУБЛИЦИСТИКА

Җ. Фәйзрахманова. **Китап бәхете** . . . . . . . . . . 124

### СОВЕТ ВЛАСТЕНЕҢ ИЛЛЕ ЕЛЛЫГЫНА

**Ялкынлы еллар поэзиясе.** Шигырьләр . . . . . . . . . . 132

### ТЕАТР

И. Илялова. **Заман һәм театр** . . . . . . . . . . . 141

### КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. Миннуллин. **Тормыш һәм характерлар дөреслеге** . . . 147
**Яңа китаплар** . . . . . . . . . . . . . . 152
**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 154
**Журнал укучылар игътибарына** . . . . . . . . . . 158
Ә. Гайнетдинов. **Партия.** Җыр. З. Нури сүзләре . . . 160

***Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый.***

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана 19, Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик* ... »

*Нури Арсланов*

# Туган илем

(Кантата)

1

Тирән дә син, киң дә, әй чал Идел,
Күз җитмәслек ерак ярларың;
Анда элек даулар, яулар иде,
Ил елатты түрә-ханнарың...
Башка инде безнең бу заман:
Балкый ярда азат, шат Казан.
Идел, Идел, туклык елгасы,
Зур туганлык, дуслык елгасы:
Идел суы, уртак су аша
Казан Мәскәү белән тоташа.

2

Күтәреләм Ослан тауларына, —
Күзге булып балкый Иделем,
Шул күзгедә минем алларымда
Күренгәндәй була киң илем.
Күренгәндәй була ак чаннар,
Буровойлар, яңа фонтаннар,
Яңа җиңү — яңа батырлар,
Җир астыннан үткән зур юллар —
Татар нефте ерак юл аша
Туган илләр белән тоташа.

3

Болытларга очам хыялларда:
Күңел бит ул очар кош сыман.
Зур заводлар җәелеп ята аста,
Офыкларны сарган ак томан.
Хыял күчә илтми кайларга? —
Ракеталар оча айларга.
Канат биреп безне күтәрә
Партиябез биек күкләргә!
Туган илем гаҗәп юл аша
Планеталар белән тоташа.

4

Сөйгән татар халкым күңеле сыман
Киң һәм иркен илем Татарстан;
Шуңа иркен сулыйм, рәхәт тоям,
Бәхетле мин бу зур язмыштан.
Республикам — туган җирем син,
Биләвем син, бишегем минем син,
Туган йорты эшчән татарның,
Бер улы син газиз Ватанның,
Ленин юлы — бөек юл аша
Бар милләтләр бергә туплаша.

*Шәйхи Маннур*

# МУСА

## Роман [1]

— Һәнде һох! — диде бер немец тавышы һәм төзәп тоткан автомат күренде.

— Ви есть арештован! — диде икенчесе әллә полякча, әллә русча жаргон белән.

Муса, бер дә исе китмичә генә, борылып карады. Баягы ике кара козгын аның ике ягында бик дошман кыяфәт белән басып тора иде. Ул аларга берхәтле кинаяле төстә елмаеп куйды:

— Ялгышасыз, шаярмагыз минем белән! — ди иде кебек ул. — Минем үз капчыгымда да этем бар, һәм бик усалы!..

Шуннан соң ул күкрәк кесәсеннән үзенең әлеге кодрәтле документларын чыгарып бирде. Немец кәгазьләрне өстән генә карады да:

— Я, я! [2] — дип кычкырды кәҗә тавыш белән. — Беләбез! Бу кәгазьләрегез — чүп хәзер, Мусза Һумияроф — Ялил! Атлагыз!

Ә икенчесе автомат борыны белән аркасына да төрткәли башлады. Шунда гына Мусаның йөрәге бик каты сикереп, күкрәк сөягенә сугылды. Шунда гына ул нәрсә булганын аңлап алды һәм аскан аяклар белән атлап китте. Документларын кесәсеннән алганда чемоданын җиргә куйган иде. Ул шунда утырып калды. Немецларның моңа игътибар итмәвен һәм шулай онытылып калуын теләде Муса. Чөнки ул чемодан эчендә солдатларга дигән актыккы өндәмә иде...

Иптәшләре аны ничәмә тапкыр кисәттеләр, чемоданында листовка йөртүдән тыеп та карадылар. Шул листовкаларны легионга ташу өчен аерым кешеләр дә билгеләделәр бит инде. Әмма Муса, өйрәнгән гадәтеннән туктамыйча, һаман шуларны йөртә бирде. Ә бу юлы инде үзе белән алмыйча да мөмкин булмады, чөнки легион почтарьларының башкача килү ихтималы юк, ара бик тар калган иде...

Әнә хәзер ул чемоданын җир йотуын бик тели дә бит ул, әмма, каһәр генә суксын!.. — Кәҗә тавышлы немец, инде утыз-кырык адымнар атлагач, Мусага һәм артка таба ялт-йолт каранып алды да:

— Потшяму һандкоффер [3] оставиль? — дип кычкырды һәм, үзе йөгереп барып, чемоданны алып килде, көчләп тоттыргандай, Муса кулына сонды.

Күпме айлар буена Мусаның «серле юлдашы» булган җиңел һәм бәләкәй чемодан хәзер эченә биш потлы гер салган шикелле авыр, күтәреп баруы мөмкин булмаган дәрәҗәдә авыр иде. Алай гына да түгел, анда Мусаның үлеме салынган, һәм ул үз үлемен үзе күтәреп бара кебек иде. Соры томан сарган күк кисәге вокзал җимерекләре арасыннан актык мәртәбә күренде, ватык кирпеч өемнәренең гүяки күз яше белән чыланган битләре актык мәртәбә сагышланып калдылар. Аны тиф барагына охшаган акбурлы такта вокзалга, аннан инде Варшава төрмәсенә алып киттеләр...

Немецлар — кагыйдә һәм тәртип, педантларча тәгаллек һәм бердәм хәрәкәт ярата торган кешеләр. Шул сәбәпле алар бу эшне аеры-чоеры

---

[1] Ахыры. Башы 5, 6, 7, 8, 9, 10 саннарда.
[2] Әйе, әйе.
[3] Кул чемоданы.

китереп йөртмичә, берьюлы тәмамларга карар биргәннәр иде. Шул ук көнне Берлинда Абдулла Алишны, Карип Ишбулдинны, Хәбиров дигән художникны, ОКВның легион буенча бүлек башлыгы Людерсон әфәнде кабинетына чакырып, шулай ук кулга алдылар. Гариф Шабаев белән Фоат Булатовны «Идел-Урал» комитетыннан алып киттеләр. Әхмәт Симаев белән аның Зиннуров, Фәйзелхаков, Хәтфуллин дигән өч егетен «Винета» бүлегеннән килеп алдылар. Шул ук көнне капитан Гельс әфәнде Едлинодагы батальонга килеп төште дә бөтен культвзводны һәм пропагандистларны «Зольдатенхайм»га «киңәшмәгә» җыйды. Алар килеп беткәч, йортны тыштан немец автоматчылары камап алды. Анна-ры унлап автоматчы эчкә кереп басты. Шуннан соң разведка башлыгы капитан Гельс, исемлек буенча берәм-берәм чакырып, Гайнан Кормашевны, Хисмәт Рушатовны, Зиннәт Хәсәневне, Габбас Шәриповны, Габдулла Батталовны, Фоат Сәйфелмөлекевне, Гали Мичуринны, Фәритевне, Киекбаевны, Димскине, Мәмүт Ямалтаевны һәм болардан башка тагын егерме бишләп кешене кулга алды. Шул ук вакытта культвзвод белән пропагандистлар барагында тентү барды һәм теге яшерелгән листовкаларны табып алдылар. Шул ук көнне икенче батальондагы Уразаев белән Бикмулла хәзрәт һәм аларның унлап иптәше шулай ук тоткын ителде. Мең тугыз йөз кырык өченче елның унынчы августы иде бу... Тик Познань төркеме белән генә немецлар соңга калдылар, фабрикант Яушев: «Мин үзем гестапо, теләсәм үзем асам, үзем кисәм!» — дип, кодрәт күрсәтеп маташкан булды. Югарырак чакырып пешекләгәч кенә, «Зинһар тизрәк алыгыз» — дип үзе ялына башлады. Шулай итеп Познаньда яшерен эш алып барган Мулланур Гәрәев, Гани Сәләхев, Сөнгать Кәлимуллин, Зиннур Мөхәмәдиев, Кыямов һәм Рулан дигән егетләр, башта Берлинга кайтарылып, унбишенче августларда гына кулга алындылар...

# Дүртенче кисәк

## БЕРЕНЧЕ БАШЛАМ

### I

...Янгын өстендә уйнаган яшь лачыннар, кинәт канатлары көеп, җиргә егылдылар. Фаҗигале көрчек ябылды. Иң каһәрле көннәр башланды...

Едлинодагы оешма кешеләрен кулга алгач та, һәрберсен тентеп, бил каешларын салдырып һәм погоннарын йолкып, батальондагы изоляторга тутырдылар. Шунда ук башлангыч сорау алулар китте. Матраcларыннан листовка чыкмаган Рушатов, Фәритев, Димски, Киекбаев һәм башкалар белән кызыксындылар алар. Һәр кайсын аерым чакырып: «Бу листовкаларны беләсезме?» дип, борын төпләрендә җилбердәттеләр. Әгәр тансалар, ялган сөйләсәләр, Германия хәрби законнарының иң катысы буенча хөкем ителү белән куркыттылар. Егетләрнең барысы да: «Белмибез, күргәнебез дә юк!» дигән җавапны гына кабатладылар. Тәүлек буе азаплаганнан соң, кулларында бер генә фактик исбат та булмаганлыктан, кайбер егетләрне азат итәргә мәҗбүр булдылар. Ләкин Рушатов белән Фәритевкә, Димски белән Киекбаевка һәм Шәриповка бу бәхет барыбер насыйп булмады, чөнки алар Мәмүт Ямалтаев күрсәткән исемлектә оешманың актив членнарыннан санала иде. Икенче көнне аларның барысын да «кара козгын» машиналарына төяп, Варшава төрмәсенә алып киттеләр. Кичә кулга алынган Мәмүт Ямалтаевны да шул ук вакытта һәм алар күз алдында аерым машинага утырттылар. Әмма ул машинаның юлы ялгышты. Варшава төрмәсенә түгел, Радом вокзалы каршындагы фонтан янына килеп туктады

ул. Мәмүтне каравыллап утырган немец унтере аңа машинадан төшәргә кушты. Ямалтаев чыгып баскач, аның бил каешын һәм погоннарын үзенә кайтарып бирде, аннары түш кесәсеннән алып ниндидер кәгазьләр тоттырды.

— Монысы юл документларың һәм марка, — диде. Барасы юлын өйрәтте.

Мәмүт исә, тиз генә погонын киеп һәм бил каешын бәйләп, яңадан хәрби формага керде дә унтерга честь бирде. Машина күздән югалгач, Ямалтаев Радом поездына утырып Варшавага китте. Андагы җыелу пунктында Мәмүтне башка легионнардан килгән кешеләр белән кушып, Австриянең Инсбрук каласына экскурсиягә җибәрделәр. Ул якларда бер ай сәяхәт кылган «турист» Ямалтаев яңадан батальонга кайтты һәм: «Варшава төрмәсендә бер ай газаплаганнан соң, гаебемне таба алмагач, кайтарып җибәрделәр», дип сөйләде. Яхшы хезмәте өчен Зикендорф әфәнде аның чинын күтәреп, взвод командирлыгына билгеләде...

Варшава төрмәсенә китерелеп, аерым камераларга бикләнгән егетләр үз язмышларының кинәт болай җәһәннәм чокырына килеп төшүенә ис-акыллары китеп, ни дә булса аңлаудан гаҗиз иделәр. «Нәрсә булды икән соң? Кая икән безнең Муса бөркетебез? Кем сатты икән безнең башларны?..» — дип өзгәләнде алар.

Ә Муса бу вакытта Варшава төрмәсендә юк иде инде. Төрмә следователе Хайс әфәнде бары көн ярым гына кыйнап калды аны. Икенче көннең төнендә Мусаны Берлинга чакыртып алдылар. Капитан Хайс ул «ата җинаятьче» не туйганчы тукмый алмый калуына бик үкенгән иде, тик шул ук вакытта конвойлар аның иптәшләрен төрмәгә китереп тутыргач кына күңеле тынычланып китте.

— Ну эшлибез болай булгач! — дип куйды ул, җиңнәрен сызганып. Һәм «эшли» башлады. Ике ай буена каннарын суырды, җаннарын гарипләргә тырышты ул егетләрнең. Сораулар нигездә бер төрле иде: «Оешмагызда кемнәр? Батальондагы җитәкчегез кем? Листовкаларны кем чыгарды? Атаманыгыз Муса Җәлил сезне качарга ничек котыртты?» һәм шуның ишеләр.

Әмма егетләрнең берсе дә «белмим»нән башка җавап бирмәде. «Белмәгәннең башы авыртмас», — ди иде Муса. Ант кабул иткән чакларда һәм башка очракларда да оешманың һәр солдатын ул аеруча нык искәртә барды: әләгә калсаң, ни сорасалар да, «белмим» диген. Беләм дисәң, нәрсә белүең турында әйтергә кирәк. Белмәсәң, сүз шуның белән бетә...

Әмма белмәсәң дә, бер әләккәч, ансат кына котылып булмый икән, белмәгәннең дә башы авырта икән. Шул белмәгәнне белдерер өчен, Хайс әфәнде Гайнан Кормашны, гади кыйнау белән генә эш чыкмагач, тар бетон бункерга ябып, баш түбәсенә суык тамчы тамызып тотты. Ул төн буе тамып, ут тамчысыдай, баш сөяген тишеп, үкчәдән барып чыккан кебек тоела иде. Кормаш аңын җуя, гәүдәсе сыгылып төшә, ләкин, таш шүре эченә тыккан шикелле, авар урын булмагач, әлеге тамчы барыбер баш түбәсенә «тып-тып» тамып тора иде. Шуннан соң да кеше акылыннан язмый икән әле. Гайнанны шул бункердан алалар да Хайска китерәләр. Ул барыбер «белми». Һәм «клайн экзикуци»лар яңадан башлана...

Шул белмәве өчен Хайс әфәнде Габдулла Батталның тырнак асларына тутыккан инәләр батырды. Алай да булмагач, кулбашларын каерып чыгарды, һәм аларны төрмә фельдшеры иң тупас алымнар белән кире утыртты, чөнки болар икесе дә бер үк дәрәҗәдә газаплау иде. Шул белмәве өчен Хайс әфәнде Рушатовны шәрә тән яткырып, резин таяк белән суктырды, ул аңын җуйгач, канлы аркасына ярты чиләк тозлы су сибеп, һушына китерделәр һәм яңадан кабатладылар. Һәрвакыт

сабыр холкы белән танылган өлкән гәүдәле Рушатов «эһ»тә димичә ничә тапкыр сугуларын санап ятты. Ләкин озакка бара алмады: «алты... сигез... сигез...» дип кабатлады да һуштан язды. Аны камера идәненә сөйрәп кертеп ташлаганнар иде, күпмедер ятканнан соң шунда күзләрен ачты һәм каршында тәрҗемәче унтер торганлыгын күрде.

— Мин сезне бик кызганам, әйтегез, үзегезгә җиңел булыр, — диде көл күзле унтер.

Рушатов, йөзен чытып, яңадан күзләрен йомды. «Каян килгән кызганучы бу?.. Җир җирәнгән нәрсә!..» дип уйлады ул. Аның дөнья йөзен күрәсе килмәде, шулай күзләрен йомган килеш мәңгегә онытылырга теләде. Әмма булмады, дөбер-шатыр килеп, Хайс үзе камерага керде.

— Я актык сүз, яки фюрернең изге балтасы! — диде ул, тантана белән.

Рушатов аягүрә басты һәм, үзенең сабыр холкын, сүзне үлчәп кенә сөйли торган гадәтен онытып, ниндидер ярсулык белән әйтә башлады.

— Белегез, әфәндем, минем бер генә гаебем бар!

— Соң безгә шул җиткән, — дип көлде Хайс, — сал чыгарып, әйдә!

— Сез кулыгыздан кош очырып караганыгыз бармы? — дип сорады Рушатов. Немец аптырап калды. Ничек инде ул: тикшерүче Хайс әфәндегә тоткын тартарен допрос ясый?

— Но, но! — дип кычкырды ул русчалатып. — Филясофиясез генә!

— Германия — философлар иле. Немецлар — цивилизацияле халык. Шулай булгач, үзем әйтим алайса, анларсыз, бәлки... — дип дәвам итте Рушатов. — Әгәр кош читлектән ычкынса, үз оясына таба оча. Әгәр җәнлек аучыдан котылса, үз өнесенә кача. Мин дә шул закон буенча эш иттем: әсирлектән качарга җыендым. Сезне яратмавым да дөрес. Менә шулар өчен мине асыгыз, кисегез, атыгыз. Сүзем юк, әмма яшерен оешманы да, листовкаларны да, башка кешеләрне дә белмим.

Хайс, кергәндәге шикелле үк, дөбер-шатыр килеп, чыгып китте. Ләкин алай гына җиңелмәде әле ул, хәйләгә кереште. Тоткыннарны яңадан берәм-берәм чакырып:

— Иптәшләрегез инде барын да әйттеләр. Сез юкка танып маташасыз. Сезнең ул оешмада актив член булуыгызны да яшермәделәр. Менә, укыгыз! — диде. Кормаш биргән «җавап»ларны Рушатовка, аның «җавап»ларын Кормашка, Зиннәт Хәсәневнекен Габдулла Батталга күрсәтте. Бу җавапларның һәм төпкә куелган имзаларның никадәр тупас һәм примитив ялган икәнлеге бер дә көрәшче булмаган кешегә дә күренеп тора иде. Егетләр, әлбәттә, бу кармакка эләкмәделәр. Һерр Хайсның тагын пәрие котырды. Мондый мәкер белән алдыра алмагач, ул яңадан үзенең элекке экзекуцияләренә тотынды. Ерткычлык һәм садизм аның иң яраткан эшләреннән иде.

Бер көнне Зиннәт Хәсәневне кара канга батырып кайтардылар. Ул киң сөякле, итләч гәүдәле, һич тә борсаланмый торган сабыр холыклы, вак-төяк авыртуларны черки тешләвенә дә санамый торган тимер түземле егет иде. Хайсның резин таяк белән суктыруларына «эһ» дигән тавыш та чыгармады ул. Фашистның җене купты, сул кулы белән Зиннәтнең күзен сугып чыгара язды. Күз төбенә шунда ук кан савып шешеп чыкты. Егет тынын да чыгармады, Хайс уң кулы белән тагын да катырак итеп Зиннәтнең авызына сукты. Егетнең авыз эченә кан тулды һәм ике теше сынып чыкканлыгын тойды. Аларны да ул, берни дә булмагандай, тыныч кына итеп, төкереп ташлады. Ләкин авызына тулган җылы кан идәнгә лач итеп барып төште. Хайс сискәнеп китте, ни өчендер бу аның үз битенә барып төшкән шикелле тоелды, ул яңадан ярсып, Зиннәтне дөмбәсләргә тотынды. Йодрыклары авыртып беткәч, теге көнне Рушатовны «кызганган» тәрҗемәче палачына тапшырды. Егылганны түбәләүнең ул да бөтен ләззәтен татыгач, яңа бер «кызык» уйлап тапты: кесәсеннән бәләкәй генә тимер саплы йолдыз чыгарып,

утта кыздырды да Зиннәтнең ике бит уртасына басты. Егет һуштан язды, әмма ыңгырашкан яки кычкырган тавышы ишетелмәде. Шул кычкырмаганы өчен аның тагын күкрәген таптадылар да мәеттәй хәрәкәтсез яткан гәүдәне җәзалауның кызыгы калмагач, камерасына илтеп ташладылар. Ул көн буе идәндә хәрәкәтсез ятты. Тик калын тимер челтәрле тар тәрәзәнең югары башындагы ачык фрамугадан бәреп кергән кечкенә салкынча җил генә аны аңына китерде. Ул күзләрен ачты да, үзенең кайда ятканын күрмәскә теләгәндәй, шунда ук янадан йомды. Аның күңелендә шулкадәр авырту, шулкадәр үкенү иде, әле ни өчендер һаман да чыкмаган җанын хәтта кая куярга белмәде. Артык нәрсә, кирәкмәс әйбер иде ул. Күз алмаларын пешерә торган яшьләр йомык керфекләр аркылы камераның пычрак идәненә акты. Сөртмәде, кыймылдамады, һаман ята бирде. Тик бер сорау аның кан сауган миен гүя кадак очы белән казгычлый иде: «Ничек килеп чыкты бу җимерелү?..»

Ә ул, батальонның булачак командиры буларак, җиң сызганып эшкә керешкән, бөтенесен оештырган, туплаган, командирларын үз бүлекчәләренә беркетеп җиткергән һәм кузгалышның уңышлы тәгәлләнүенә җаны-тәне белән ышанган иде. Аның еракта, бик ерактагы Сарман ягында үзе генә өзелеп ярата торган сөйкемле Сариясе бар. Юк, әллә ни матур да түгел, атаклы да түгел ул, әмма җир сөюче гади бер тракторчы Зиннәтне үзенә тиң күреп яраткан, шул елларда колхозга беренчеләрдән булып килгән агроном кыз иде ул. Сария аңа җирнең, үсемлек һәм чәчәкләрнең, гомумән, табигатьнең әллә ни кадәр яшерен серләрен ачты, аны алга әйдәде, механик булыр дәрәҗәгә җиткерде, аңа берсеннән-берсе матур өч бала бүләк итте, әмма үзе, һич кенә дә укып чыгуы мөмкин булмаган хикмәтле китап шикелле, якты бер чишмә булып калды. Соңгы көннәрдә ул гел аны төшендә күрде, өнендә дә ул аның күз алдыннан китмәде, кая барса, нишләсә, Зиннәт үзенең Сариясе белән сөйләшеп йөрде, һәр эшен аңа багышлады һәм кавышу сәгатьләре инде кул сузымында гына кебек тоела иде. Шундый татлы һәм ялкынлы хыяллар канатында еракларга очканда, көтелмәстән атылган кош шикелле, кинәт кенә йөзтүбән мәтәлеп төшү Зиннәт өчен үлемнән дә авыр булды. Сугыш кырындагы үлем — тик бер сулыш! Тиле бер пуля килде дә тиште дә китте йөрәгеңне... Ә менә бөтен максат һәм якты хыялларың, бөтен эшең пыра-зара килеп, үзең берни эшли алмыйча җирдә аунап ятуның ачы үкенеченә ничек түзәргә? Бу хурлыктан җаныңны кая ыргытырга? Хәзер инде һичнигә дә кирәге булмаган җаныңны!..

Икенче бер камерада шул ук җәза эчендә Гайнан Кормаш ята иде. Кайда һәм нәрсәдә булды аның хатасы? Легиондагы оешманың җаваплы кешесе буларак, ул бит бөтен саклык чараларын да күрде шикелле, хәйлә-хәйлә һәм ялган юмалау белән немецның күзен дә тиешенчә капларга тырышты кебек, кузгалыш планын да бик аз кешеләр генә белә иде... Нәрсә булды соң? Кинәт аның күз алдына яньчек борынлы, тыңкыш тавышлы, калай күзлекле яңа бер кеше килеп басты. Шунда ук йөрәге жу-у итеп, бөтен гәүдәсе тетрәнеп, корышып калды. Ул бит Габдулла белән нидер хакында, әйе, «ил хатлары»н кайда яшерү турында, бугай, аның алдында сөйләшкән иде. Алай гынамы соң әле, Баттал сүзенә ышанып, ашык-пошык арада оешма члены ясады, ант иттергән булды, серне ачып ташлады. Ах алла, ах, егетләр! Неужели шул икән?.. Неужели провокатор?.. «Кала куыштан алыныр» дигәннәр... Юк, Иван Грозныйның тау астындагы Аблай мунчасыннан казып кереп, дистәләрчә мичкә дары белән көтмәгәндә Казан стенасын шартлатуы һәм шул арадан гаскәре эчкә агылып, шәһәрне яулап алуы гына түгел икән бу! Андый күренеп торган куыштан керүче гаскәрне эчке яктан кырып тору бер дә кыен булмас иде. «Куыш»ның башка мәгънәсе булырга тиеш!

Кормаш менә хәзер Хайс кусәгеннән башы ярылгач кына ул куркыныч мәгънәне төшенеп алды. Әйе, оешма да үзенә күрә бер кечкенә кала, бер ныгытма иде бит. Дошман, күпме генә тырышса да, аның эченә турыдан бәреп керә алмады. Ә инде битлек кигән бәндәсен җибәреп безнең серне алгач, ныгытманы шунда ук җимерде дә ташлады... Аһ, йөз тапкыр уяу булырга, мең тапкыр сак торырга, дошманга үз арада «куыш» ясатмаска кирәк булган икән шул! Ник ул шуны үз вакытында уйлап җиткермәде? Ник Батталны Мәмүт алдында сөйләүдән туктатмады? Моның өчен оешма аңа нинди генә җәза бирсә дә аз булачак. Муса абыйсы күзенә ничек күренер ул?.. Әгәр күренә алса әле...

Кормаштан ике камера читтә яткан Габдулла Баттал да инде ничәмә көннәр һәм төннәр буе шушы ук уйлар белән җан газабы кичерә иде. Бәләкәйдән үк һәрберсе тукмактай йодрыклы күп малайлы крестьян семьясында үскәнгә күрә, Хайсның суктыруларына гына артык исе китмәде аның. Газапның, әрнү һәм сызлануларның иң катысы допростан соң камерага кертеп ташлагач башлана иде. Иң элек ул уйлапүлчәп карады: моңарчы Фәритев белән күпме листовкалар ташыдылар, ябыштырдылар, тараттылар — һичнәрсә булмады. Ә бу чергән борын белән бер генә бардылар, һәм Габдулла аның юашлыгына ышанып, инде Кормаш янына кайтып җиткәч, сер сөйләп ташлады. Һәм менә нәрсә килеп чыкты! Да, шул гына хәрап итүе ачык... «Ник ышандың син шул тыңкыш җыланга, шул сатлык кара йөзгә ник сер ачтың? Ник ахырын уйламадың?..» дип инде йөзенче тапкыр үз-үзеннән сорау ала ул. Үзенең беркатлы, кешеләргә тиз ышанучан гади холкын хөкем итә. Кешеләрнең шундый мәкерле, тиз аңлап булмый торган кара эчле булуына бөтен йөрәге белән рәнҗи. Иптәшләренең һәм гомуми оешманың шушындый һәлакәткә очравына бары тик үзен генә гаепле саный. Чамасыз күп җан газабы кичерә торгач, инде ул катгый бер карарга да килде. Бу карарны ул иптәшләреннән раслатыр һәм, һичбер икеләнмичә, үз кулы белән үзе җиренә җиткерер...

Әллә каян гына төрмә тәрәзәсенә килеп эләккән кечкенә кояш өске өлгедән актык нурларын сузган иде. Рушатов та, Зиннәт тә, Кормаш һәм Габдулла да хәсрәт сауган күзләре белән шул зәгыйфь нурга үрелделәр. Сүнеп бара торган яшәү яктысы кебек тоелды ул мескен нур. Һәрбере аны үз гомере белән бәйләде. Һәрберенең гомере хәзер шулай сүнеп китәргә тора, шул соңгы чаткылар кебек яшәү җепләре тиздән бөтенләй өзелер төсле... Шул чагында ерак та булмаган кайсыдыр камерадан, йөрәк өзгеч таныш һәм якын тавыш, таулардагы юан имәннәрнең куышлары давылда шыңгырагандай көчле тавыш яңгырап китте:

Ераклардан балкып һай күренә
Ирәмәлкәй тауның ак ташы.
Кайларда гына йөрми, ниләр күрми
Ир-егеткәй белән...

Башкортка гына хас чикләнмәгән ирек сөюче, баш имәс холыклы, күңеле дәрья моңлы Кылычбай җырлый иде моны. Әле генә идәндә кан түкереп яткан егетләр ниндидер эчке көч белән тибрәнеп аягүрә бастылар, тәрәзәләргә ташландылар, аларның кан тамырлары буйлап ут йөгерде: яшәү, яшәү дәрте яңадан уянды.

Әмма бу көчле җырның ахыры, кабатлана алмыйча, кинәт өзелде. Аны көчләп өзделәр. Кылычбайны кереп кыйный башладылар һәм карцерга сөйрәделәр, күрәсең...

— Түкерәм мин һеззең шакшы битегезгә! — дигән арыслан тавышы гына күкрәп калды аның. Шул тавышка кушылып, әллә кайсы камералардан ачы нәфрәт, ерткычлыкка каршы протест һәм каһәрләү тавышлары яңгырады, ачулы йодрыклар камера ишекләрен төйделәр.

Әмма бераздан мондагы шыксыз дөнья тагын үзенең үле тынлыгына чумды...

Шуннан өч көннән соң Габдулла Батталов, төрмәнең тар гына ишек алдына прогулкага чыгарылгач, беренче тапкыр Рушатовны очратты. Бу киң гәүдәле, олы маңгайлы, тулы битле иптәшенең яңак һәм күз төпләренә кан савып, йөзләре бөтенләй суырылып, аркасы бөкрәя төшкән сыман булып калган иде. Габдулла аның бу тирән газаплы кыяфәтендә тагын үз гаебен күрде. Рушатовны барып кочаклыйсы, гафу үтенеп елыйсы килде. Ләкин аларга тезелгән рәттән чыгып, бер-беренә якын килергә һәм сөйләшергә рөхсәт ителми иде. Шулай да Габдулла прогулкадан керешли баскычтан менгәндә Рушатовның артына туры килде. Тирәсендәге кешеләр күбесе поляклар, ара-тирә чехлар да бар иде. Шунда ук Рушатовка әкрен генә әйтеп салды:

— Гаеп миндә... — диде. — Мин Мәмүт Ямалтаевка ышанып, аны оешмага тарттым, «ил хатлары»н да бергәләп яшердек... Безне ул гына саткан... Күрешә алсаң, иптәшләр белән сөйләш... Миңа үлем җәзасы чыгарыгыз... Үзем җиренә җиткерермен... Болай гына үз-үземә кул сала алмыйм... Сезне ташлап качу шикелле була.

Рушатов берни дә әйтә алмыйча калды. Чөнки үз этажларына менеп җиткәннәр һәм юллары аерылырга тиеш иде. Тик аның сагыш тулы күзләре генә зур ачылып, утлы күмердәй елтырап киткән төсле булды...

## II

Абдулла Алиш белән художник Хәбировны һәм Карип Ишбулдинны Берлин төрмәләренең берсенә китереп яптылар. Алар өчесе дә газетада эшләүче булгангамы, әллә башка берәр сәбәптәнме, бер камерага туры килделәр. Камерага аяк басу белән Карип тәмам изелеп төште. «Аталар инде безне... Балта белән башны чабалар!..» — дип, эч пошыргыч, ачу китергеч яшелле-күкле тавышлар белән елый башлады. Хәбиров үзенең ни өчен монда эләккәнлеген белмәсә дә, бөтен дөньясына кул селтәгән кешедәй, бер почмакта бөрешеп утырды. Алиш тар, озынча идән буйлап, тирән пошынулы уйлар эчендә әрле-бирле атлый да атлый иде. Ничек килеп чыкты соң бу?.. Күзләре ник күрмәде аның?

Карип хихылдап чыгып киткәннең икенче көнендә, ул аны типография подвалында туры китереп, җан ачуы белән буып алды. Яннарында Фоат кына бар иде. «Әйт, хәшәрәт, хәзер үк сөйләп бир! Барыбер буып үтерәм мин сине, әйтеп кал!» — дип кычкырды Алиш. Һәм чынлап та, ул соңгы чигенә килеп ярсыган иде. Карип, Алишның итекләрен кочаклап, аунап еларга тотынды. Бер нәрсә белмәве турында йөз тапкыр ант итте. Ишек төбеннән табылган кисәкне юри шаярып кына аңа кертүен әйтеп елады. Алиш ике арада аптырап калды, нишләргә дә белмәде, кулларын салындырды... Ачык авыз булдың, нинди тиз утырттылар үзеңне төп башына! Дошман оясындагы чын көрәшче шундый буламы соң? — дип, өзлексез әрнергә генә калды аңа.

Ул һаман атлый, һаман атлый... Кулын артка куя, кесәләренә тыга. Бармаклары, төптә кармаланып, шул матрицаны эзләгән кебек була. Аннары кулларын чыгара да бил каешына кыстырмакчы була, ә каешы һәм бөтен формасы салдырылган. Ялангач башының ярым җитү чәчләрен сыпыргалап ала да тагын шул әрнеткеч табышмакның төенен чишәргә азаплана башлый. Ник шул чакта ук Мусага әйтмәде ул? Ник моның һәлакәт китерү ихтималын уйлап бетермәде? Шундый шомлы хәлне тиз генә хәбәр итми калырга хакы бар идеме аның? Бәлки, бергәләп бер чарасын күргән булырлар иде. Аһ, никадәр акылсызлык! Моның җәзасын үзе генә күтәрәсе булса, бер хәл иде, әмма аның белән бергә нинди гүзәл иптәшләре һәлак булуы мөмкин... «Нишләргә миңа, нишләргә миңа?..» — дип ыңгырашты ул.

Карип Ишбулдин тагын шыңшый башлады.

— Әй газиз башкаем!.. Бер гөнаһсыз көйгә бетәсең. Дөнья рәхәтен күрми дә каласың...

— Илаулама әле ачу китереп! — дип кычкырды Алиш аңа. — Син юеш кыргаяк белән нишләсеннәр? Этемә кирәкме син? Юри генә алганнардыр әле. Күз буяу өчен генә...

— Ничек инде күз буяу өчен генә? — дип кабынып куйды Ишбулдин. Ләкин бу сүзне ишетү аны бик тиз юашландырып җибәрде. Алишның нәрсәгә ишарәләгәне бик ачык бит... Бу камерада аның белән ничек калырга? Әгәр төнлә, Хәбиров та, Карип тә йоклагач кына буып ташласа?..

Аның бөтен гәүдәсе калтыранып китте, арка сөякләре буйлап суык тир чыкты, тешләре шыкылдаганы ишетелмәсен өчен авызын кысып йомды, каны качкан битләрендә бала йоннары кабарып селкенә башлады, чамасыз курку баскан күзләре калай төсенә керде һәм инсәсен корыштырып, почмакка таба елышты.

Алиш аның соравына җавап биреп тормады, аның үз кайгысы ашып узган иде: ул әле һаман Мусаның нинди хәлдә, кайда икәне турында берни дә белми иде. Кайда булыр ул? Билгеле, ул да алынгандыр. Чемоданына листовкалар төяп чыгып киткән иде бит. Аны алгач, шул листовкалар буенча, Алишларны да шулай җыеп утыртканнардыр. Хәер, алай дисәң, ул листовкаларның Алиш, Булат яки Шабай кулы белән хәзерләнгәне беркаян да билгеле түгел ич, өсләренә язылмаган. Муса да «алар басып бирде» дип әйтми инде. Димәк, дошман аларны күптәннән күзәтеп килгән, мәгълүмат җыйган, дәлилләр туплаган. Һәм менә килеп... вәссәләм...

Алишның шулай җавапсыз калуы Карипне башта сөендерде. Ул күңелсез темага сүз куертып тормау, әлбәттә, яхшырак иде. Әмма торабара ул яңадан тәшвишкә төште. Алишның кич буена туктаусыз йөренүе, әледән-әле Карипкә күз ташлап алгалавы, алай гына да түгел, ятарга команда булып ут сүнгәч, бераздан соң Алишның яңадан торып, таш идән буенча ялан аяк таптануы шикле кешегә әллә нинди хәвефләргә төшәр өчен җитә калды: ничек итеп карый бит! Барын да белә, күрәсең. Буып үтерми калдырмас!

Карип төн буе йокламады, онытыла башласа, икенче ягына әйләнде, алай да йокы оета башласа, бармаклары белән күз кабакларына, сызлатканчы, ут күренгәнче басты. Яктыра башлау белән торып утырды, аннары өстен киенеп, таптанырга керешә, допроска чакырулары белән тикшерүченең өстәленә ятып үкерергә тотынды.

— Ник мине юкка газаплыйсыз? Чыгарыгыз тизрәк! — дип немецның аягына ташланды ул. — Юкса, үтерә ул мине, буып үтерә! Бүген дә төн буе йокламадым. Әһәр төнне йокламау мөмкинмени? Алиш шуны гына каравыллый, ул барыбер мине үтерәчәк!

Тикшерүче, кызыксынып, сораштыра башлады: ни сөйләде, әллә берәр нәрсә белән куркыттымы? Әллә син сатканны беләме?

— Юк, берни дә сөйләмәде. Куркытмады да, — дип лычкылдады Карип. — Аның шул сөйләмәве, шул куркытмавы куркыныч та инде! Сүзсез генә эшен бетерә торган кеше ул!

— Эх син, яухе! [1] — диде немец, җирәнгән төс белән. — Бар, сөйләштер, эченә кер. Безгә белергә кирәк!

Карип чыкмыйчарак торды. Бераз гына иркәләнергә уйлаган иде ул. Әлеге сүзләрен яңадан кабатлады, бер дә булмаса, икенче камерага ябуларын сорады. Немец җәһәт кенә урыныннан кузгалды да хәрби итегенең бүлтәеп торган башына карады, аннары Карипне ишеккә таба этәрде һәм шул уңайга аның йомшак җиренә тибеп җибәрде, әйтерсең,

[1] Җебегән сыер тизәге.

футбол тубын озатып җибәрде ул. Карип ике кулы белән шап итеп ишеккә барып сугылды, ишек ачылып китте һәм Карип идәнгә барып төште...

Шулай да аны биш көннән соң чыгарып җибәрделәр. Редакция кешеләренә ул үзен герой итеп сөйләде.

— Биш тәүлек буе пытка ясадылар, — дип пышылдады. — Нинди генә ерткыч җәзалар уйлап тапмый анда фашистлар. Коточкыч! Тимер түземең булмаса, бер көндә үк үләрлек! Шулай да мин бирешмәдем, авызымны келәшчә белән дә ача алмадылар — бер сүз әйтмәдем! Гаебемне таба алмагач, чыгармый хәлләре юк!..

Тыңлаучыларның кайберләре сокланып карагандай булды аңа. Ә кайберләре пырхылдап көлүләрен яшереп тә тормадылар. Әмма Карип мондыйларга игътибар итмәде. Ул һаман пафос белән сөйләвендә булды:

— Муса белән Алиш өчен генә кайгырам, — дип дәвам итте ул. — Слабыйрак егетләр иде. Пыткага чыдый алмыйча, чишелеп ташламасалар ярый инде. Хәтәр бит анда бик!..

Мондый «җәһәннәм газаплары» күреп кайткач, Гаптрахман абыйсы алдында да элеккечә юаш кыланмады ул. Тигез һәм хаклы кешедәйрәк сөйләшә башлады. Фәрештәләр бии торган йортларга барып кәеф-сафа кылу өчен кирәкле матди хәраҗәтләрне аяк терәбрәк, күбрәк һәм ешрак таләп итәргә тотынды.

## III

Мусаны «профилактика» тәртибендә генә кулга алырга уйлаганнар иде. Әйтик, мондый операция вакытында гаепләре ачык күренеп тормаган башкаларны да алган шикелле. Чөнки татар легионы эчендә ниндидер яшертен кайнау бара; листовка таратыла, буйсынмаулар, качулар һаман көчәя, мари егетләренең мәетләре юкка чыга, яшерен пропаганда алып барыла һ. б. лар. Моны нинди дә булса бер оешма эшләргә һәм аның җитәкчесе булырга тиеш. Кем ул җитәкче? Алишмы, Булатовмы, Симаевмы, Кормашовмы?.. Билгесез. Әмма табарга кирәк ул азиатны!..

Мусаның чемоданыннан листовка килеп чыгу — гестапочыларның башын тинтерәткән бу серләрне берьюлы ачып биргәндәй булды... Аны Варшава төрмәсеннән Берлин уртасындагы Александерплац урнашкан Полицайпрезидент төрмәсенә китереп, подвал камераларның берсенә ташладылар. Кызыл кирпечтән өелгән әллә ничә катлы бу биек йорт үзенең ямьсез һәм тупас эшләнеше, күз тукталырдай бер генә дә якты ноктасы булмавы белән Пруссия монархларының ерак заманнардан бирле үзгәрешсез килгән шыксыз символы кебек тора иде. Аның эчендәге бөтен нәрсәләр дә таш белән чуеннан ясалып, ишек, тәрәзәләренә хәтле тимердән төрелеп, кешеләргә бары тик газап, михнәт һәм рәхимсезлек тудыру өчен генә яшиләр иде. Шулар басымы астында калган Мусаны надзиратель тар озын һәм җансыз коридорлардан, баскычлардан озатып, ярым җир астындагы олы бер камерага кертеп япты. Иң элек монда караңгы гына бер ут януы ниндидер бик борынгы, сукыр лампалы авыл мунчасын хәтерләтте. Шунда ук аның борынына юешлек һәм әллә нинди нәҗесләр бергә кушылудан, гомер буе җилләтелмәүдән килеп туган зәһәр сасы ис килеп бәрелде, тыны кысылды, үзе дә абайламастан борынын тотты, ләкин шунда ук кулын кире алды: бу бит инде бер минутка керелгән бәдрәф түгел, күпмедер гомер итәсе урын, борын тотып кына котылып булыр микән, дип уйлады ул.

Камерадагы җан ияләренең күпчелеге аны кертү белән дәррәү хәрәкәткә килде. Барысы да аны чорнап алды да:

— О! О! О! Клайн тигер! [1] — дип кычкыра башлады. Берсе чыгарды бүре тавышы, берсе чыгарды мәче тавышы, берсе чыгарды үгез тавышы, берсе чыгарды кәҗә тавышы. Шунда ук күзләрен, бармакларын уйнаттылар, колакларын сикерттеләр, аңкау шартлаттылар. Берсенең баш очындагы бер генә чеметем калган чәче кинәт үрә торды, тагын яты һәм тагын торды. Әйтерсең, ниндидер җепләр белән уйнатып була торган парик кигән клоун иде ул. Шул арада Мусаның өстендәге киемнәрен чеметеп, кесәләрен капшап карый башладылар.

— О! — диде берсе, тамагына бәрәңге утырган тавыш белән. Костюм, костюм! Кулга йомшак күренә. Гут!

Калганнары шундый ук шамакайлык белән Мусаның чалбарын, эшләпәсен, туфлиен, күлмәген, хәтта оекбашын бәяләп, мактап чыктылар. Тиздән безнеке булыр! — дигән шикелле учларын учка ышкып алдылар. Тагын берсе Мусаның бөтен кесәләрен актарып, әйләндереп чыкты. Аннары бер кесәне чеметеп кенә тотты да авызын бүлтәйтеп:

— Эс ист леер... [2] — диде.

Муса, идән уртасына баскан килеш көлемсерәп, тик кенә торды. Аның йөзендә шундый садә гамьсезлек балкый, гүяки бернәрсәгә дә исе китми: «Алыгыз ал. Бар да сезнеке. Миңа барыбер кирәге юк аларның...» ди иде ул.

Боларның барысы да вак-төяк кесә карагы, аферист һәм һәртөрле блатной немецлар икәне күренеп тора иде. Яңа китерелгән кеше бертөрле дә каршылык күрсәтмәгәч, йөзенә ризасызлык билгеләре дә чыгармагач, аның белән артык мавыгуның кызыгы да бетте, ахрысы, кесә осталары берәм-берәм үз почмакларына таба тарала башлады.

Мусаның күзләре мондагы караңгыга шактый иялэнеп өлгергән иде инде: уң як почмакта бу «танышу» кызыгына катнашмаучылар да бар икән. Блатнойлар таралып беткәч, Муса, үзенә урын эзләгән кеше сыман, байтак каранып торды да шунда таба атлады. Алар өчәү генә иде. Рөхсәт сорап берсенең тапчан кырыена утырды.

— Муса абый, бу синме? — дип әкрен, ләкин кайнар тавыш белән пышылдады ул егет һәм аның кулларыннан каты итеп кысып алды. — Эх, язмыш!..

Муса үз янында утырган кешеләрнең Симай белән бергә «Винета» да эшләгән егетләр икәнен танып алды. Моңарчы әле аның үз иптәшләре турында бер хәбәрдарлыгы да юк иде. Ашыгып-ашыгып сораштыра башлады. Егетләрнең Фәйзелхаков дигәне барын да сөйләп бирде. Симай белән бергә аларның өчесен һәм редактор булып эшләүче Әлемчан Илдриси хатыны Шәмселхәят ханымны да алуларын, ә Симайны ни өчендер алардан аерым ябуларын әйтте.

— Ә кайчан алындыгыз соң? — дип сорады Муса.

— Унынчы августта...

— Ә башкалар нихәлдә икән, белмисезме?

— Белмибез, — диде егет. — Әмма чамалап була инде: сез дә алынган булгач, башкалар да шул ук хәлдәдер...

Муса озак кына уйланып утырды. Димәкки, гестапо аларның эшен алдан ук сизеп, хәзерләнеп хәрәкәт иткән. Бер көнгә туры китереп алган. Болай булгач, легиондагы оешма да тар-мар ителгән булыр. Аны Варшавада тотып алулары да очраклы түгел, ә немецка хас педант төгәллектән килеп чыккан эш, күрәсең...

— Абый, безне инде атарлар микән, асарлар микән? — дип сорады егетләрнең Зиннуров дигәне.

Гадәте буенча Мусаның көлемсерисе килде, ләкин ул үзен тотып

---

[1] Бәләкәй тигр!
[2] Ул буш.

калды, чөнки бу сорау беркатлы булып күренсә дә, бик житди иде, күңеленең бөтен тирәнлегеннән борчылып сорый иде егет.

— Сезне атмаслар да, асмаслар да, — дип җавап бирде Муса тыныч кына. — «Без белмибез, катнашмадык, күрмәдек», — дип барыгыз. Шулай дисәгез, сорарлар-сорарлар да чыгарырлар. Аларның сезгә карата бер фактлары да юк ич...

Шуннан соң байтак кына сүзсез утырдылар. Берәүнең дә артык җәелеп сөйләшәсе килми, урыны да андый түгел, һәркем үз уе, үз хәле белән мәшгуль иде...

Төрмә киче шулай бер килеш кенә дәвам иткәндә кинәт ниндидер хатын-кызның бик ачы итеп, каравыл салып кычкырганы ишетелде. Камерадагылар барысы да ишек күзенә ташландылар. Каршыда хатын-кызлар камерасы икән, анда бик нык шаулашалар, көлешәләр, сызгыралар, кайсыдыр ике кулы белән камера ишеген төя-төя: «Таладылар! Разбой!» — дип, «Кая монда власть кешеләре?» — дип, кызганыч һәм көленеч тавыш белән кычкыра иде. Ул арада надзирательләр йөгерешеп килеп җиттеләр дә, тынычланырга кушып, янаулы тавыш белән сүгенә башладылар. Теге ачы тавыш туктамады, ярдәм сорады. Шуннан соң авыр йозакларны шалт-шолт китереп ачтылар да:

— Кем монда хулиганлык итә? — дип кычкырдылар. Камера эченнән шәп-шәрә бер хатынны кемнәрдер ишеккә таба этәреп җибәрделәр. Ул һаман нәрсәдер таләп итә иде. Сакчылар исә аны тиз генә коридорга суырып чыгардылар да шлангтан суык су белән коендыра башладылар. Ул үрле-кырлы сикерә иде.

— Сез барыгыз да хөкүмәт дошманнары! — дип кычкырды ул хатын. — Мин фюрергә хезмәт иткән кеше! — диде. — Мин шикаять бирәчәкмен! — диде.

Аны барыбер ай-ваена куймадылар, шлангтан көчле басым белән атылган суык су тәмам аягыннан екканчы коендырдылар да яңадан камерага сөйрәп ташладылар. Бөтен коридор буйлап шау-шу, сызгыру, көлешүләр, бик үткен әйтелгән әшәке сүзләр гөрләп тора иде.

— Нәрсә булды икән соң ул хатынга? — дип сорады Муса.

— Тавышына караганда, безнең Шәмсел апа булырга тиеш, — диде Фәйзелхаков. — Безнең каршыда урам кызлары камерасы, ул шунда эләккән. Күрәсең, тегеләр аны чишендереп алганнар — шәп-шәрә бит. Ә ул монда хаклык эзләп маташкан була, мескен...

Муса аптырабрак китте. Кара әле бичараны, Шәмсел апа икән. «Ирек»тә чакта Илдрисиләрдә булгалаганы бар иде аның. Якташ булып чыктылар. Илдриси, кайчандыр Льеж университетын бетергәч, Оренбургта укыткан. Шәмселхәят апа да шуннан. Ул бик яхшы күңелле хатын: совет әсирләреннән берәр егет килеп керсә, чәй эчертергә тырышкан була, «И мескенкәйләрем, сез инде бәлшәвикләр кысканга гына камунис булып йөргәнсез, монда эләккәч иманга килегез инде», дип кызгана һәм үгетли иде. Ә хәзер әнә үзен ничек иманга китерәләр...

Бу подвал камераларындагы тормыш алда да шулай «күңелле» дәвам иткәндерме, юкмы — Муса белә алмады. Иртәгесен аны өченче катка аерым камерага яптылар һәм шул көннән үк допрослар башланды.

Варшава һәм Берлин төрмәләрендә узган өч-дүрт көн эчендә генә Муса әле үзен допросларда ничек тотарга, нинди тактика белән хәрәкәт итәргә кирәклеген уйлап бетерә алмады. Әгәр ул бер үзе генә алынган булса, тактика бик тиз ачыкланыр иде. Әмма хәл алай ансат түгелдер, күрәсең. Кичә Фәйзелхаков әйткән яңа хәбәр аны уйланырга мәҗбүр итте: Симайны алуларына карап, Алишны да, Фоатны да, Шабайны да алганнар дип белергә кирәкме? Легиондагы иптәшләр исәнме? Киресенчә булса, кемнәр алынган? Гестапочылар барысын да беләләрме, оешма бөтенләе белән провалга очраганмы, әллә Мусаның [illegible] ік-

кан листовкалар хакында гына сүз йөртерләрме? Башкалар да алынган булса, алар допроста ничегрәк җавап биргәннәр? Менә шул хәлләрне әзме-күпме белмичә торып, бер фикергә килү бик кыен иде. Муса бу хакта озак кына баш ватты. Белмәгәнне ничек белергә? Ә тикшерүче һәрхәлдә башкалар язмышы турында да белә инде. Әгәр тикшерүченең үзенә тикшерүче булып карасаң?.. Әмма ничек эшләргә моны? Аңа сораулар биреп булмый ич...

Шулай ачык бер фикергә килеп өлгерә алмаган Мусаны допроска алып киттеләр. Ул ишектән килеп кергәч, тикшерүче булган кеше, бик кадерле кунак көткән кебек, үзенең зифа буен, бәләкәй генә башлы нәзек озын муенын, бамбук таякларыннан ясалгандай нечкә генә ботларын сузып, озын шүре кунычлы күн итекләрен ялтыратып, аягүрә басып тора иде. Әмма бу сәер кеше үзе көткән «кунак»ны түргә кыстарга бер дә ашыкмады әле, хәтта аны күрмәде дә шикелле. Нечкә ботларын бераз юанайтып торган галифеенең ике кесәсенә ике юка кулын тыгып, бик арыган кеше кәяфәте белән стенадагы фюрер портретына карап каткан иде ул. Аның йөзендә бертөрле дә соклану билгесе күренми. Гүяки бу кеше портретның үзенә карамый, ә аның бай инкрустация белән эшләнгән рамындагы алтын бизәкләрен өйрәнә иде. Ул эшен озак кына вакыттан соң тәмам иткәч, үз креслосына килеп утырды да зур кара өстәл астыннан сызыклы бланк чыгарды, өстенә зәңгәр йомшак кәгазь салды, аның өстен дүрт почмаклы постау кисәге белән каплады, аннары уң кулының аскы кырыен угалады да шул постау өстенә куйды. Кулының шул төше туңа яки сызлый, күрәсең, дип уйлады Муса. Күп допрослар яза торгач, зәңгелә зәхмәте төшкәндер, ахрысы.

Шуннан ары гына тикшерүче кеше бик йомшак кына, хәтта ягымлыга якын тавыш белән Мусаның исем-фамилиясен, туган елын, милләтен, кайдан булуын, хатын, бала-чагасын һ. б. ларны сорап алды. Аның һәр җавабын гаять бөтеркәле готик хәрефләр белән бер дә ашыкмый гына язып чыкты. Аннары тагын каядыр билгесез ноктага текәлде. Тәрҗемәче кирәкме, дип сорады. Үзенең тәрҗемәче аркылы эш йөртергә яратмавын әйтте. Клиент биргән җавап тәрҗемәче авызы аркылы үткәч, машинкада борылган ит шикелле ләззәтсез була, имеш.

— Ничек телисез бит... — дип кенә куйды Муса.

Болай дусларча сөйләшү нәтиҗәсендә тикшерүче әфәнде үзе белән гаепләнүче арасында кечкенә генә бер күпер салырга теләде. Аныңча, бу бик кирәкле нәрсә иде. Хәзер инде ул гаепләнүченең хокукын һәм бурычларын аңлатырга кереште. Моның белән ул әлеге күперне тагын да ныгыта төшәр, һәм эшне алып бару күп өлеш җиңеләер.

— Сез минем каршымда тоткын булып кына утырмыйсыз, — дип башлады ул. — Сезнең хокукларыгыз да бар. Мәсәлән, сез үзегез күрсәткәннәрнең һичбер бозусыз, арттырмый-киметми, төп-төгәл язылуын сорый аласыз. Кирәк урында үзегез теләгән кеше белән күзгә-күз куелуны таләп итә аласыз һ. б. һ. б. лар. Сезнең хокук һич тә чикләнмәгән! Әмма шул ук вакытта сез фәкать туры җавап кына бирергә тиешсез. Без бары тик дөреслекне генә белергә телибез. Яшерергә һич тә ярамый!

Муса көлемсерәп куйды: «чикләнмәгән хокук!» һәм «ярамый!»... Кызык булыр сыман күренә бу әфәнде...

Тикшерүче аның көлемсерәвен күрмәмешкә салынды.

— Сез, нинди генә үтенечегез булса да, һәрвакыт миңа мөрәҗәгать итә аласыз. Мин кулымнан килгәннең барын да эшләрмен. Минем фамилиям фон Геденктафель. Бик сирәк очрый торган, бик борынгы фамилия! Унтерзухунгерихтер [1] Геденктафель әфәндене сорасагыз, сезгә һәрвакыт юл ачык булыр...

---

[1] Следователь.

Муса бу юлы да көлемсерәми түзә алмады. Хезмәт исеме дилбегә буе сүздән торган бу әфәнденең бик борынгы фамилиясе — «мемориаль такта» дигән мәгънәне бирә иде. Хәзергә бик йомшак сыман кыланган бу әфәнде үзе дә мемориаль такта гынамы соң? Исме җисменә муафикъ булса, әллә бик зыянлы да булмас әле. Әгәр гап-гади такта гына булса?.. Ул чакта... маңгаеңа шап итеп сугылуын көт тә тор инде!..

Геденктафель әфәнде төп эшенә керешер алдыннан тагын стенадагы карачкыгамы, әллә түшәм орнаментларынамы текәлде. Аның өстәл кырыена тезелгән маникюрлы бармаклары, рояль телләре өстендәге шикелле тырпаеп, гүяки әкрен генә нидер уйныйлар, тик музыка тавышы гына чыкмый иде.

— Сез, минем белүемчә, шагыйрь кеше, ахры?.. — диде ул, бөтенләй сорамаган да тон белән.

— Ә моның нинди әһәмияте бар сезнең өчен? — дип куйды Муса, аңа туры карап. — Әллә анысы да бу илдә җинаять саналамы?

— Юк, әһәмияте бик бар, майн һерр, — диде немец, шул ук йомшак тавыш белән. — Сезнең шундый югары хисләр кешесе булып та, бу тикле түбән җинаять юлына басуыгыз мине бик борчый. Нәрсә мәҗбүр итте сезне?.. Көчле шәхес булу өчен кызыктыгызмы? Әмма белегез, дөньяның көчле шәхесе бер генә хәзер!

«Сез тудырган кыргый тоткынлык мәҗбүр итте, азат кешенең азатлык сөюе мәҗбүр итте!» дип кычкырасы килде Мусаның. Ләкин ул алай дип әйтмәде. Ул бер ноктага караган килеш озак кына дәшми утырды. Тик шуннан соң гына, тикшерүченең йөзенә яңадан текәлеп:

— Мин әле үземдә бер төрле дә җинаять күрмим, — диде.

— Менә ничек? — дип көлде немец. Азау тешендәге алтын коронка әз генә уйнап китте. — Сез алайса, изге фәрештә шикелле, поэзия күгендә генә очып йөргәнсез? Хәер, сезнең җинаятегез безгә җитәрлек кадәр мәгълүм. Тик әле үз авызыгыздан раслату гына кирәк иде.

— Мәгълүм булгач, аны раслатып тору нигә? Чыгарыгыз да атыгыз.

— О, майн Либстер [1], сез ашыгасыз! Германия — законнар иле. Шул изге закон тәмамән җиренә житкерелмичә торып, берни дә эшләнми. Законсызлыкка бездә юл куелмый!

Муса, авызын дөмберәйтеп, кыска гына көлеп җибәрде:

— Ко-ко-ко! — дигән шикелле ишетелде ул. — Халыкара законнар да сакланамы?

— Әлбәттә, әлбәттә! — диде немец, муен уртасындагы төерен сикертеп. — Сез аны үзегез күрәсез. Мәсәлән, кайчандыр Германия сугышта газ кулланмау турындагы конвенциягә кул куйган. Һәм фюрер аны бозмый! Юкса, без әллә кайчан бөтен дөньяны аяк астыбызга салган булыр идек!

— Газ! — диде Муса. — Ә бәлки ул газ баллоны икенче баштан да сиптерә ала торгандыр һәм бөтен Германия өстен каплавы да ихтималдыр?..

— Сез онытыласыз, шагыйрь әфәнде! — диде немец, ни өчендер уң кашын сыпырып. — Сез әле Дойчландның чын бөек рухын белмисез!..

— Нигә белмәскә? — дип җавап бирде Муса. — Ничәмә-ничә лагерьларда үз җилкәмдә татыдым. Искиткеч шәп һәм мәңге онытылмас көннәр иде. Бер селтәүдә җаныңны ала торган батыр вахтманнар дисеңме, аларның арысландай овчаркалары кирәкме, ачтан шешенеп һәм тифтән үлүче мең-мең әсирләрне текә яр асларына үләксәдәй тутырулармы... Ә немец халкы — дөньяга Фихте, Фейербах, Һегель, Энгельс, Маркс, Шопенгауэр, Ницше кебек философларны, Лессинг, Шиллер, Һете, Һумбольд, Бетховен, Вагнер, Лист, Эйнштейн һәм башка йөзләгән-мең-

[1] Күгәрченкәем, сөеклем.

ләгән сәнгать ияләрен, галимнәрне биргән халык. Без яшь чагыбыздан ук ул халыкка ихтирам белән карап үскән кешеләр. Әмма хәзер ни күрәбез? Юк, таный алмыйм мин ул халыкны хәзер...

Тикшерүче башта, кызыксынып тыңлаган кешедәй, сигарет кабызып җибәрде. Аның йотлыгып эчкә суырган һәм кире чыгарган төтеннәре пенсне пыялаларына сыланып, аларны тоныкландырган төсле булды. Аннары авызын киң ачып, ясалма тешләрен күрсәтеп, искәп куйды. Аннары башын кыңгыр салды, тагын бугаз төере сикереп куйды. Тик Мусаның соңгы җөмләсендә генә уянгандай булып, учы белән өстәлгә сукты.

— Сабыр итегез, күгәрченкәем, — диде ул мыскыллы тавыш белән. — Бик тәэсирле сөйләдегез. Шагыйрь кеше шул, күренеп тора!.. Сезнең белән сөйләшүе дә күңелле. Дөресен әйткәндә, мин үзем дә сәнгать кешесе. Кайчандыр ач студент чакларымда мин дә бөтен дөньяга мәшһүр музыкант булу турында хыяллана идем. Алай гына да түгел, Бетховен яки Штраус булу белән саташа идем. Шул ук вакытта, зәңгәр томаннарга уралып, ефәк корты шикелле генә яши торган зәп-зәңгәр күзле, алтын чәчле, сусылудай зифа нәзек буйлы профессор кызы Лизеттага Ромеодан да кайнаррак гыйшык тота идем. «Яшь Вертерның газап чигүләре»н еламыйча укый алмый идем. Шулай булгач, мин сезне аңламыйммы соң? Бик аңлыйм! Әмма шулай да без рольләрне алмашмыйк. Сез миннән допрос ала башладыгыз, майн либстер. Ялгышасыз, мин алыйм әле сездән ул допросны...

Немец, өстәл артыннан кузгалып, Муса каршына килде. Ниндидер дусларча елмаю һәм йомшак тавыш белән генә:

— Ауфштеһен зи! [1] — диде.

Муса аягүрә басуга, немец тар учын җәеп, аның йөзенә сугып җибәрде. Муса стенага барып бәрелде. Аның күз алларында ут биеде. Шулай да Муса, башын калкытып, немецка карады: ул үзенең үтүкләнгән керфекләренә һәм нечкә кара кашларына ниндидер нур тутырып, идән уртасына ботларын ерып баскан хәлдә, һаман шул ук дустанә төс белән елмаеп тора иде. Әйтерсең, ул Мусаның бик күптәнге дусты, һәм ул аңа һич сукмады, ә бары тик дусларча шаярган булып, этәреп кенә җибәрде. Аннары, өстәленә борылып, кнопкага басты да бүлмәнең аргы почмагында торган сары кранлы ак юынгычка таба атлады. Кулына сабын тидереп, бик ныгытып уа-уа, тырнак асларында кер калмавын җентекли-җентекли, юа башлады. Ул арада ишектән ике кара күләгә керде дә Мусаның ике култыгын артка каерды.

— Кляйн каммерконцерт [2], — диде Геденктафель, тавышын бер дә үзгәртмичә.

Мусаны кичәге подвалның бирге башына алып төштеләр. Тәрәзәсез-нисез бер таш бүлмәгә керттеләр дә, ут яндырып, шыр-ялангач чишендереп, төрмәче немецлар гына эшли ала торган рәхимсезлек белән аңын җуйганчы җәзаладылар. Аннары шлангтан боздай су сиптереп һушына китерделәр. Бу эш барганда, кайдагыдыр бушлыкта, чыннан да, ниндидер концерт бирелә, ниндидер пәри музыкасы уйнап тора кебек иде. Озын тимер чыбыкка чуен бөҗра кидертеп бәйләгән усал эт ишек алды буйлап чапканда чыжлап-чыжлап чыккан тавыш та, калай пычкыны әллә ниләр кыландырып бөгә-бөгә чыгарылган сыкраулы-чыңгылдаулы авазлар да, челпәрәмә килеп коелып төшкән пыяла тавышлары да, ярык саксофон улаганы, төнге ябалак кычкырганы да — һәммәсе дә бар иде ул музыкада һәм, барысы да бергә буталган төсле, көйсез-моңсыз шыңгыравык булып яңгырый иде. Шул музыка астында аны тагын дөмбәсли-дөмбәсли киендереп, өскә алып менделәр. Мусаны

[1] Аягүрә басыгыз.
[2] Кечкенә генә камерный концерт.

тик бер сорау газаплый иде: «Кем бу? Шул ук Хайсның икенче данәсеме?.. Юк, бу аннан йөз мәртәбә кабахәтрәк, куркынычрак икән. Кем соң бу? Достоевскийның Свидригайловымы? Юк, ул да түгел, бу немец аннан әллә никадәр пычкәртелгән әшәкелекне эшли ала, бу синең җан жепләреңне көлә-көлә суырып, бармагына чорный торган тәмуг зәбаные, фәкать гестапода гына өйрәтелүе мөмкин булган суык канлы садист икән...»

Мусаның бит сөякләре, яңак һәм маңгайлары берничә төштән суелып канаган, ияк астына кан сауган һәм күз төпләре күгәреп чыккан иде. Тикшерүче аны ишектә күрүгә ук кычкырып куйды:

— Ой, блут![1] Булдыралмыйм, күрсәтмәгез күземә, йөрәгемә ярамый! — һәм читкә борылды. «Алып китегез» дигән шикелле, кулын кирегә селтәде. — Кая соң медик? — дип, тиз генә өстәлендә килде дә кнопкага басты. Хәрби форма өстеннән ак халат кигән медфельдшер килеп җитте һәм Мусаны күршедә генә булган икенче бүлмәгә җилтерәтеп кертте дә, күренеп торган канлы җирләренең барысын да юеш мамык белән юдырып, бит һәм маңгайларына ямау ябыштырды, күп төпләренә, муен асларына ниндидер ак кершән сибеп, марля белән ышкыды. Шулай ямаштыру һәм буяштырулардан соң ул аны янадан тикшерүче ишегеннән кертеп җибәрде. Боларның һәммәсе вакытында да Муса һаман шул «мемориаль такта» белән мәшгуль иде: кан күрә алмый, ә?.. Йөрәгенә ярамый. Адәм актыгы! Ак перчаткалы палач шушыдыр инде ул.

Немец аңа баягыча ук дус кыяфәт белән урын тәкъдим итте.

— Бу юлы, шәт, пафоска бирелмәбездер инде, — диде ул кургаш тынычлык белән. — Максат һәм планнарыгызны сөйләгез. Бөтен Европаны арт тәпиенә бастырган Өченче Рейхка каршы ниләр кырмакчы булган идегез?..

Муса авыз ачарга ашыкмады. Аның күз алдына иптәшләре килде. Ул аларның күңелләренә беренче тапкыр очкын салучы булды, изге максатның бөеклеге белән мавыктырып, үз артыннан ияртте. Алар адым саен үлем куркынычы булган авыр бәйгегә чыктылар. Шулай булгач, аның һәр сүзе шул иптәшләренең язмышына бәйләнгән. Мусаның аларны корбан итәргә һич кенә дә хакы юк. Киресенчә, ул аларның гомерен үлем авызыннан тартып алырга тиеш. Яшь кенә көйләренә дөнья матурлыгыннан мәхрүм булмасыннар... Шул максаттан чыгып эш иткәндә, «Берни дә белмим» дип котылу мөмкин түгел. Дошман бит аның чемоданында нәрсә ятканын барыбер белде инде...

— Яхшы,— диде Муса, шулай ук кургаш суыклыгы белән. — Пафоссыз гына сөйләшербез... Мин, үзегезгә мәгълүм булуынча, шагыйрь кеше. Гомер буе сугышка каршы шигырьләр яздым. Тынычлыкны яратам. Монда да мин кешеләрне сугышмаска өндәдем. Үзебезнең әсир егетләрнең яңадан корал күтәреп, фронтка барып үлүләрен күрәсем килмәде... Минем гаебем шул. Әгәр сугышмаска өндәү — җинаять саналса, мин дар агачына менәргә әзермен.

— Ге-ге-ге-ге! — дип көлде Мемориаль такта, бәләкәй малайларны үчекләгән төсле. — Сез нинди олы рухлы тынычлык фәрештәсе! Искиткеч! Ә легион зольдатларын, корал белән күтәрелеп, поляк партизаннарына качарга чакырмыйсыз? Нинди ак күгәрчен! Ге-ге-ге-ге. Күңелле сезнең белән әңгәмәләшү... Ә иптәшләрегез кем? Большевистиш оешмагызда кемнәр иде? Бәлки аларны сез белмәгәнсездер, ге-ге-ге?

Вертерне елап укый торган немец инде, баягы ясалмалыгыннан чыгып, үзенең табигый холкына кайткан, кәефе тәмам уйнаклаган һәм үз тырнагына эләккән корбанны көлә-көлә кытыклап үтерергә әзер булган шүрәлене хәтерләтә иде. Аның бу мыскыллавына карап, Муса үз тигезлеген җуймады, ашыкмый гына әйтте:

[1] Кан!

— Мин үзем.

— Тагын сез мине көлдерәсез, шагыйрь әфәнде! — диде немец, нечкә мыегының бер койрыгы белән генә көлеп. — Кызыксынсагыз, бездә кайбер документлар да бар... — Ул, өстәл астындагы кәгазьләрне актарып, берсен тартып чыгарды. — Рәхим итегез. Хәтта русча язылган. Сезнең юлдашларыгыз үз куллары белән язып бирделәр. — Муса допрос беркетмәсенең арт ягына язылган бер үтенечне укыды.

«Без, «Дүртенче комитет» дигән яшерен коммунистлар оешмасы төзеп, «Идел-Урал» легионын эчтән җимерергә теләдек. Татар солдатларын немецка каршы атарга өндәдек. Листовкалар чыгардык. Оешмада без белгәннәрдән Муса Җәлил (Гумеров), Гариф Шабаев, Абдулла Алишев, Фоат Булатов, Әхмәт Симаев, газета художнигы Хәбиров бар иде. Безнең һәммәбезне дә Муса Җәлил котыртты. Без бу җинаять эшебездән чын күңелдән тәүбә итеп, безне исән калдыруыгызны үтенәбез. Г. Шабаев, А. Алишев».

Бу кәгазь кисәген Муса ике рәт укып чыкты. Бөтенләй диярлек дөрескә якын. Максатлар, эшләр һәм кешеләр туры килә яза. Текстны Шабай кулы язганга охшый. Муса аларның имзаларының да нинди мыеклар, нинди койрыклар белән куелганын белә иде: аларда да шик сизелми... Тик бу кәгазьнең фәкать Муса өчен генә мәгълүм булган бер кимчелегә ачык ярылып ята иде. Ул — Хәбиров фамилиясе. Әгәр моны, тикшерүче әйткәнчә, аның юлдашлары үзләре теләп язган булса, анда Хәбиров фамилиясе булмаска тиеш. Чөнки алар Хәбировның бу оешмага катнашы юклыгын яхшы беләләр. Нигә гөнаһсыз кешене бутасыннар икән?.. Димәкки, кәгазьне Алиш та, Шабай да язмаган, ә гестапо хөҗрәсендә әвәләп чыгарганнар. Ихтимал, имзалар да шунда ясалгандыр...

Муса, ниндидер бик әшәке нәрсәдән җирәнгән шикелле, бу кәгазь кисәген ике бармагының очы белән генә тотып, тикшерүче алдына кире салды һәм тыныч кына әйтте:

— Юкә. Ягъни мәсәлән, липа.

— Вас ист дас, «липа»? — дип сорады тикшерүче, нәзек кашларын дугаландырып.

— Юкәдән ясалган, дигән сүз. Руслар мондый фальшивканы шулай дип атыйлар.

— Ничек ул фэльшунг? — дип кабынды немец. — Аны гаепләнүчеләр үзләре язды! Алай гына да түгел, әгәр бик теләсәгез, мин аларны сезнең белән кара-каршы китерә алам! — Мемориаль такта өстәл сукты, урыныннан торып басты, ишекле-түрле йөреп китте.

— Конфронтатион! [1] — дип кабатлады ул, кинәт ярсып купкан ачуы белән.

Ярсымаслык та түгел иде шул. Мусаның бик куркыныч һәм бик кире, үз сүзендә каткан коммунист икәнен әйттеләр аңа. Шуңа күрә аны телдән яздыру өчен бик аяктан еккыч фактлар кирәк булачак иде. Ул каллиграф һәм графологлар тапты. Шәфи комитетыннан Шабай белән Алишның язу үрнәкләрен китертте. Күпме көч һәм осталык, сәләт һәм нечкәлек белән үз консультациясендә шушы документны әзерләтте. Ә бу бәләкәй генә татар шуны «липа» дип мыскыл итә. Ярылып үләрсең!

— Бик телим күзгә-күз куюны, — диде Муса, аның чәпченүенә игътибар да итмәгәндәй, салмак кына тавыш белән. — Сез нәкъ минем хокукларым турында әйткән идегез. Менә хәзер мин алардан файдаланасым килә...

— Ә-ә-ә, хокуклар! Яхшы, яхшы. — Геденктафель кинәт тынычланып киткән төсле булды. Нәрсәдер исенә төшкән кебек, атлаган җирен-

[1] Күзгә-күз кую, кара-каршы китерү.

нән кире борылып, өстәл янына килде. — Хокук, әлбәттә, зур һәм бик кирәкле нәрсә... — Шул сүзләрне борын эченнән кабатлап, кнопкага басты. Бер минут үтүгә баягы ике зөбани килеп керде. Йомшак немец аларга карамыйча гына, гамьсез генә боерык бирде:

— Гроссконцерт[1].

Мусаны шул ук баягы рәвештә алып чыгып киттеләр...

Бер сәгатьтән соң аны, ике култыгыннан сөйрәп, үзенең тар гына, бәләкәй генә камерасы идәненә кертеп ташладылар. Йозаклар шалт итеп бикләнде. Ул, бөтен сөякләре таралган хәлдә, идәнгә йөзтүбән капланып калды. Озак, бик озак аңсыз, хәрәкәтсез ятты. Әмма торабара чуерташ катыш цемент белән катырган идәннең әкренләп үрмәли торган дымык салкынчасы аңа әз-әз тәэсир итте. Ул, ниндидер авыр саташулы, газаплы төштән уяна алмый җәфа чиккән кеше кебек, чак кына исенә килә башлады. Таш бастыргандай күз кабакларын көч-хәл белән ачуга дөм-караңгыдан башка һични күрмәде. «Әллә сукрайттылармы?» дип, тетрәнеп китте ул. Ләкин күзләре ияләшә төшкәч, түрдәге тәрәзә аша әз генә тыш яктысы саркылганын күрде, сөенеп куйды. Камерага ут бирмәгәннәр икән. Ә кай вакыт соң хәзер? Бөтен дөнья караңгы: кичме бу, төн уртасымы, әллә таң алдымы? Хәер, барыбер түгелмени... Озак йөзтүбән ятудан аның бөтен гәүдәсе укмашкан, сөм тоймый башлаган иде. Әйләнеп чалкан ятарга теләде. Әмма суелып беткән тире эчендә капчыкка тутырган шикелле тарау сөякләре, бөгелмәс булып каткан буыннары, кинәт балта төйтәсе белән төйгәндәй, сын катырып, чатнап сызлый, итләре авырта, тире өсте әрнеп-әрнеп әчетә башлады. Ул, кузгалу фикереннән кайтып, әз генә калкыган башын түбән төшерде дә уң битен салкынча идәнгә куйды һәм тынсыз калды. Аның хәле шундый авыр, шулхәтле соңгы чигенә килгән иде, — ул инде шушы яткан җиреннән кабат кузгала алмас, алда туасы таң яктысын да, иртәнге кояш нурларын да күрмәс, шулай тын гына үләр кебек тоелды.

Мондый хәлгә төшкән кеше үзенә бөтен матурлыкларын бүләк иткән якты дөнья белән, рәхәт һәм михнәтләрен кызганмаган һәм бик кыска булып тоелган татлы яшәү белән, иң зур куаныч һәм ләззәт биргән кадерле яшьлек хисләре, сөйгән яры, бәгырь кисәге баласы белән, дөньяның һичкемендә дә булмаган йомшак кулларында сөеп үстергән газиз әнкәсе белән саубуллаша башлый. Әгәр ул аллага сыгынучы кеше булса, үзенең изге догаларын укый, тәүбә-истигъфарга килә. Әгәр ул аллалар белән чикләнүне вак нәрсә дип санаучы ирек сөяр лачын егет булса, кычкырып бер җырлап җибәрә. Шуның белән эчен бушата.

Шулкадәр ерткычларча изеп ташлаганнан соң таш идәндә кыймылдый алмый яткан Мусаның да хыял канатлары ерак омтылырлык түгел иде, юк, имгәтелгән, каерылган иде алар. Әмма шулай да аның күңеле, сүнмәс рухы, гүя авыру тәненнән өскә күтәрелеп, әнә шул лачын егетнеке шикелле җыр белән, шигырь белән тулды. Аның кәгазе дә, каләме дә, хәтта карандаш очы гына да юк иде. Ул кан сауган авыр башын янадан күтәрде, уң кулының имән бармак тырнагы белән, инә тыгылган шештән кан китү сәбәпле ансы авырта башлагач, бүтән бармак тырнаклары белән цемент идәнне тырный-тырный шигырь язды. Тора-бара шул каты идәндә, якты сибә торган күкерт белән язган шикелле, юл-юл булып шигырь сүзләре уелып кала кебек тоелды. Ләкин бу — хәлсез күзләрнең алдануы гына иде. Ул көчсез тырнаклар таш идәнгә эз төшерә алмадылар, шигырь анда язылмады, шигырь Мусаның күңел түренә генә язылды. Үлем чигендәге газап эчендә туган бу җырны таңга кадәр кабатлап ятты ул:

[1] Зур концерт.

Җир йөзе шундый киң,
Күңелле һәм якты!
Тик төрмәм караңгы,
Ишеге йозаклы.

Күктә бер кош оча
Югары, югары!
Мин аулыйм идәндә,
Кулларым богаулы.

Тышта бер гөл үсә
Яңгырга коенып,
Мин кибәм, мин сулам
Төрмәдә боегып.

Мин беләм: бик татлы
Хөр яшәү тойгысы!
Тик инде мин үләм,
Бу җырым — соңгысы!..

Әмма үлмәде ул. Үлем әле алай ансат кына килергә теләмәде. Ул әле аңа тагын иксез-чиксез газап һәм җәберләр күрсәтә-күрсәтә, шырсөяк суык аякларының вак-вак адымнары белән генә үрмәләде... Югарыдагы тәрәзәнең тимер челтәре аркылы таң яктысы камерага үзенең үтә күренмәле юка гына ак ефәген суза башлады. Очып китәргә талпынып та, урыныннан кыймылдый да алмыйча, атылган бөркет төсле яткан Муса таң яктысына яңадан башын калкытты, мөлдерәмә күзләре белән шактый озак карап торды.

— Болай булгач, кояш нурын да күрәм икән әле... — дип пышылдады ул һәм нечкә җыерчыклар тезелгән кумгәк иреннәре белән елмаерга теләде. Күзләрен тәрәзәдән алмаска тырышты. Әмма тубалдай авырайган башы тагын аска төште һәм ул таш мендәргә йөзен каплаган килеш йоклап китте...

## IV

Башка иптәшләре белән Абдулла Алишны да бу төрмәгә китереп, аерым камерага япканнар иде инде. Аның тикшерүче йөдәтүләренә, куркыту һәм кыйнауларына артык исе китмәде. Ул гел бер уй, бер үкенеч белән газап чикте. Аны үзен иптәшләре алдында гаепле санау изә иде. «Ни өчен мин сак булмадым? Ник шунда ук Мусага әйтмәдем, ник яшердем?..» дип, ул инде йөзенче тапкыр үз бәгырен үзе телгәли иде. Аңа, әгәр яшермичә шунда ук чарасын күрсәләр, менә бу хәлгә төшмәсләр иде кебек тоелды. Ә хәзер аны һәм тагын күпме лачын егетләрне фашист хөкем итәчәк! Аларның каны Алиш йөзенә төшәчәк!.. Нишләде ул, нишләде?..

Ул шулай өзгәләнә дә, яшь тулган күзләрен гүя кешеләрдән яшерер өчен, бер почмакка сыена һәм, йөзен караңгы стенага төртеп, яшьләре беткәнче елый, үзен «Йомшак син, ачык авыз син, шул матрицаны рәтләп күмә дә белмәдең!» дип әрли иде. Аеруча бәгыренә тигәне — иптәшләренең ышанычын аклый алмавы булды. Аңа ышаналар иде бит, билеты булмаса да, коммунист саныйлар иде, ә ул аларны алдады...

Шул хакта уйлый башлагач, ул үзен иптәшләренең хөкеме каршында торган кебек хис итә, маңгаена салкын тир чыга, моның оятыннан шундук үләсе килә башлый иде.

Шулай үзен-үзе җәзалап арганнан соң күңеленең кайсыдыр почмагыннан икенче бер тавыш та күтәрелә: туктале, Алиш, ди, син үзеңне артык бетереп ташламыйсыңмы?.. Син кече яшьтән үк йомшак күңелле, турылыклы булып, кешеләрнең яхшылыгына ышанып, аларны дус күреп үстең һәм гомер юлыңнан да шул якты терәкләргә таянып атладың түгелме? Син алдау-йолдауны, бозыклык һәм азгынлык кылуны, дусларыңа хыянәт итүне, ялачы һәм ялагай булуларны нәфрәт белән чит-

кә кага идең түгелме? Син кеше өендәге тар гына почмагыңда төннәр буе хикәяләр язганда, үз күгәрченнәреңне генә түгел, ә шуларга охшаган тагын бик күп зәңгәр күзле, кара чәчле, сөт бөрчекләредәй ап-ак энҗе тешле, төймә борынлы, аю баласыдай камыт тәпиле, әмма шулай да синең каршыңда барысы да сөйкемле, барысы да сөекле нәниләрне күз алдыңда тотып иҗат иттең түгелме? Син, гади солдат буларак, сугышның бөтен авырлыкларын татып, камалышта ачлыктан үләр хәлгә житкәч, актык патроныңны аткач кына, командирың белән бергә әсирлеккә төшәргә мәҗбүр булдың түгелме? Ә дусларыңның беренче чакыруы белән үк, син, үлем куркынычын белә торып, янадан көрәшкә ташландың һәм сез күпме эшләр эшләдегез! Синең тирәдә койрык болгап йөргән Алабайның кем икәне бик билгеле! Шул матрица ертыклары белән генә сезнең эшегез фаш ителер идеме? Дошманның үзәк оясында, аның өзлексез күзәтүләре астында яшәгән бу оешманың кинәттән һәлакәткә очравында башка төрле тирәнрәк сәбәпләр юк микән? Уйлап кара: сез бит анда, аквариумдагы балык төсле, кай почмакка гына сыенсагыз да йөзләрчә күзләргә күренеп тора идегез!..

Бу аклаучы тавыш тынычландыра башлауга, эченнән тагын әрнү күтәрелә: «Юк, юк! — ди ул. — Син үзеңне сөттән ак, судан пакь итмәкче буласың? Булмый, дөрес түгел! Дошман кулына җеп очы тоттыру — бөтен йомгакны сүтәргә мөмкинлек бирү дигән сүз!..»

Ничәмә тәүлекләр буена сузылган бу вөҗдан газабы, акыл һәм хисләр тартышы Алишның чыраеннан каннарын суырып алды, каш араларына тирән сызыклар уелып, ияк очындагы сөйкемле чокыры тирәнәеп калды.

Тикшерүче биргән сораулардан үзенчә нәтиҗә ясап, оешма өстенә олы һәлакәт килгәнен, дусларының бары да төрмәләргә тутырылганын аңлагач, тагын ачы хәсрәткә батты, бик тиз арада Мусаны күрәсе һәм барын да сөйләп бирәсе килде, тик аның кайсы төрмәдә икәнен белү мөмкин түгел иде. Ә икенче бер уйлаганда бу нияте аңа ошамады. Хәзер инде моның мәгънәсе юк. Мусаның болай да яралы йөрәгенә тагын бер яра салудан нинди файда?.. Алайса, әйтмичә үлсенме ул, авызына су кабыпмы? Монысы инде тагын да начаррак... Аһ, бәхетсезлек!

Тикшерүче кайвакытны өчәр көн чакыртмыйча тора. Мондый көннәрне Алиш ничек уздырырга, үзен кая куярга белми. Бер эш юк. Укыр идең — китап-фәлән бирелми, язар идең — кәгазь юк, йоклар идең — тимер койка стенага бикләнгән, йөрер идең — камера идәненең буе дүрт адым, тәрәзәдән карар идең — биек. Әле кергәннән бирле һавага чыгарганнары да юк. Допроска алып барсалар, ичмаса, әз булса да һава сулыйсың, сөякләрең ватылганчы кыйнап кайтаралар, ботарлап ташлагандай идәндә ятасың, каһәр төшкән газаплы уйлардан онытылып торасың...

Мондый халәттә туктаусыз янулар, тимерне әле утка, әле суга тыгу шикелле өзлексез газаплар, кешенең бәгырен ташка әйләндереп, баш бирмәс дәрәҗәдә үзсүзләндереп җибәрәләр икән. Моны Алиш тикшерүче янадан чакырткач сизде. Ул аның мәкерле сорауларын, башын югары күтәреп, үзен горур тотып кире какты. Немец әлеге матрица кисәкләрен үзенең иң көчле козыре итеп, Алиш алдына тезеп салды.

— Ә бу нәрсә?..

— Мин каян белим? — дип көлде Алиш. — Күргәнем дә юк!

— Беләсең! Аны син күмгән җирдән тапканнар!

— Ә мин күмгән чакта килеп тоткан гуаһларыгыз бармы? Кемнәр ул, китерегез!

— Ах, сиңа гуаһ кирәкме?.. Коммунист этенә гуаһ?.. — Немец, бөтен гестапода кагыйдә буларак йөргән гадәт буенча, куллары белән «гуаһ» күрсәтергә тотынды.

— Рәхмәт сезгә, — диде Алиш, теш сыныгын кан белән төкереп ташлап. — Сез мине коммунист дип атадыгыз. Ә мин әле үземне ул әйбәт исемгә лаек түгел дип йөри идем. Ленин булган дөньяда! Бөек акыл иясе, бөек революционер, бөек демократ. Димәк, мин аның солдаты! Ә солдат буларак, кулымда нинди корал бар, шуның белән мин үз илемне сакларга тиешмен. Һәм мин шулай эшләдем дә. Теләсәгез асыгыз, кисегез, әмма мин солдат булуымнан кайтмам!

Тикшерүченең «эше» кул белән дә, тел белән дә тагын барып чыкмады. Чөнки ул Алиштан бер генә кирәкле җавап та ала алмады. Ә аңардан гаепләнүченең тизрәк үз гөнаһсын тануын таләп итәләр. Ул Геденктафель кул астында эшли иде, аның алымын кулланып карады. Алиш алдына «Аһмет Зимаев күрсәтүләре»н чыгарып салды. Әхмәтнең имзасын күрсәтте һәм немецча язылган беркетмәдән бер өзек укып бирде. «Листовканың текстын Абдулла Алишеф язды, матрицага мин суктым» диелгән иде анда. Алиш имзаны күргәч, бераз уйланып, аптырабрак калды. Аны шулхәтле нык охшатып ясаганнар, фәкать имза дөреслегенә генә игътибар иткән кешегә бик тиз алдану мөмкин иде. Шуның өчен Алиш текстка ябышты. Андагы беренче җөмләнең дөреслектән ерак булуы елмаерга мәҗбүр итте аны. Чөнки текстны Муса язган иде, ә Симайның Алиш өстенә ялган сөйләве мөмкин түгел.

Алиш немецның күзләренә туп-туры карады да бармак очын үпкәндәй итеп алды:

— Вас ист дас? — диде тикшерүче аңламыйча.

— Бармактан суырылган. Ягъни, сезнең бармактан!..

Бая гына допросны «сагынган» Алиш «теләгенә» иреште: аны аңсыз хәлдә камерасына кертеп ташладылар.

...Әхмәт Симаев исә беренче допроста ук үзенең һәм иптәшләренең бу кара чытык стеналарны үтеп, якты дөнья йөзен кабат күрә алмаячакларын аңлап алды. Шуңа күрә ул, иптәшләрен саклап калу өчен үзе корбан булырга теләп, фәкать үз тактикасы буенча гына эш итте: әгәр үләр көнең җиткән икән инде, матур итеп үлә бел, үкенечкә калмасын!..

Тикшерүче аның эшен тиз тотмакчы булды. Чөнки Карип Ишбулдин матрицаны урлап китергәч үк: «Моны ясаучы Әхмәт Симаев кына булырга тиеш. «Винета»дагы тәрҗемәчеләр арасында иң оста куллысы, иң грамотные да шул...» дип күрсәткән иде. Ләкин Симай белән бергә алынган егетләр телләрен бик нык тешләгән булып чыктылар. Нинди генә экзекуцияләр дә алар авызыннан сүз чыгара алмады. Хәзер эш Симайның үзенә терәлеп калган иде. Бусы да тел тешләп маташырмы, әллә берәр нәрсә әйтерме?.. Алиш эшен алып барган шул ук Гробер әфәнде, каршы якны куркыту өчен баштан ук үзенең козырь тузы белән йөргән уенчы шикелле, әлеге матрицаны Симай каршына да тезеп салды:

— Я, нәрсә әйтерсез, танышмы бу сезгә?

Әхмәт, иронияле күз төшереп кенә, синтетик җаймә кисәген кулына тотып караган булды.

— Ник таныш булмасын? — диде ул, бер дә исе китмәгәндәй итеп. — Бик таныш. Мин суктым аны машинкада.

Тикшерүче, мыш-мыш килеп, тиз-тиз яза башлады.

— Шуннан соң? Тагын, тагын?

— Шул! — диде Әхмәт, күкрәген киерә төшеп, — кирәк булса, эчтәлеген дә укып бирә алам: анда Совет информбюросының сводкасы сугылган.

— О, найн! — диде немец, Симайга каршы учын җәеп. — Кирәкми.

— Нигә? — дип гаҗәпләнде Әхмәт, җилкәләрен күпертә төшеп. — Анда бер төрле дә кефер сүз юк бит. Курск — Орел сугышлары турында дөрес хәбәрләр генә. Аны бөтен дөнья матбугаты баса. Тик немес газитләре генә...

— Туктагыз әле, тукта, өлгерә алмыйм, — диде немец, кирәкмәс сүзне туктатырга теләп. Аннары тел очы белән иренен ялады да, актык хәрефен куеп, башын күтәрде, сигарет кабызды.

— Сез инде, немес гәзитләре андый ялганны басмагач, үзегез гәзит чыгарырга булдыгыз алайса?

— Гәзит түгел, листовка гына. Ялганны түгел — чынны! — диде Әхмәт, һаман һөҗүм итә баргандай. — Сезнең эшләрнең Курск тирәсендә ничек кәкәй барганын белсеннәр әле татар солдатлары, мин әйтәм!

Тикшерүче авторучкасын атып бәрде.

— Кайда дип беләсең үзеңне!

— Нигә? — дип тагын гаҗәпләнгән булды Әхмәт. — Моның нинди гаебе бар? Сез әле шул сводкадан да куркасызмы? Алайса, сер итеп кенә әйтим, фәкать үзегез генә белегез: мин сезнең Гитлерны үтерергә йөрдем!..

— О, майн Готт! — дип ыңгырашты немец. Күзләре, куркып шашкан кешенеке төсле, акаеп чыкты, кеше ишетмәгәе дигәндәй, тиз генә ишеккә карап алды, өстәл артындагы олы итләч гәүдәсе кинәт корышып, бәләкәй генә булып калды. — Туктыйсызмы сез, юкмы?!

— Әйе, әйе! — диде Әхмәт, берни дә булмагандай. — Шундый ниятем бар иде. Рейхстагка кергән яки чыккан чагын саклап торып, лимонка тондырмакчы идем. Чөнки бөтен дөньяны канга батыручы — ул бит! Тик шунысы кызганыч, теләгемә ирешә алмадым: иптәш булмады. Ә мондый эшне, үзегезгә мәгълүм, бер ялгызың гына башкару мөмкин түгел. Менә бу — эш булыр иде ичмаса! Бөтен дөнья тынып калыр иде!..

Гробер, урыныннан торып, Симаевны әйләнеп чыкты. «Акылдан язмаганмы бу? Әллә юри генә идиот булып кыланамы?» дип уйлады ул. Аннары, бар ачуы белән, нәкъ Геденктафельчә, Симайның йөзенә сугып җибәрде. Ләкин Әхмәт кинәт кенә ике беләген аркылы куеп өлгерде.

— Эх, суга белмисез,— диде ул.— Менә мин суксам иде, тешләрегезне җыеп бетерә алмас идегез!

Немецның иемнәре тараеп, эссе булып китте, якасын чишеп җибәрде. Симай аның бармаклары калтыраганын күреп калды.

— Курыкмагыз, — диде ул. — Әле бит сез миңа бер генә суктыгыз, ул да уңышсыз булып чыкты. Ә менә кабат суга калсагыз инде, бигайбә!

Гробер әфәнде эндәшмәде. Аның кипкән иреннәреннән кан качкан иде. Әлеге бизгәкле бармаклары белән, ашыга-ашыга, кнопкага басты. Бусагада колга буе ике кара дәҗҗал күренде. Алар тиз генә тимер куллары белән Симаевны култыклап алдылар да ишеккә юнәлделәр.

— Богауга! — дип кычкырды тикшерүче.

Әхмәткә берничә көн буена суд медицинасы экспертиза ясады. Аның нервлары бик какшаган булса да, психикасында зыян барлыгын тапмадылар. Тумыштан яки контузия-фәләннән идиот булмавын да расладылар. Димәк, ул сәламәт акылдан фюрергә кул күтәрмәкче булган! Коточкыч! Иң куркыныч җинаятьче! Гробер әфәндене тәне генә түгел, җаны да тетрәнде: тизрәк эшен бетерергә дә бу тартарның, балта астына!..

V

Инде айдан артыкка сузылган төрмә тормышы, нинди генә кабахәтлеге һәм вәхшилекләре белән җәберләмәсен, барыбер Мусаны изеп ташлый алмады. Хәтта мескенәйтмәде дә. Тора торгач ул үзенең очсызкырыйсыз авыр уйларыннан, үкенү һәм пошынуларыннан барыбер айнып китә, еш кына кайчангыдыр якты хәтир... ен-

ләй онытыла, хәтта берни дә булмаган шикелле елмаеп та куйгалый иде. Шундый чакларда ул, гүя һич кайгысыз һәм борчылусыз кеше шикелле, кулын артына куйган килеш ишекле-түрле йөренгәләп, үз камерасының әлмисактан бирле агартылмаган стеналарын «өйрәнә» иде. Алар бөтенләй чуарланып беткән. Монда утырган һәрбер кеше үз календарен ачкан да кыска гына итеп үзенең әрнүле фикерләрен, нәфрәтен яки йөрәк хисләрен язып калдырган. Ул юллардан көйдергеч каһәр белән тулы йөрәк ачысы бәрелеп тора, дөнья белән саубуллашу авазы яңгырый.

Нинди генә телләрдә язылмаган алар! Немецча, французча, голландча, серб һәм хорватча, русча, полякча, украинча һ. б. һ. б. Бакчы, хәтта 1918 елгылар да бар: «Хуш, Шарлотта! Иртәгә миңа капут. Әмма мин карак түгел, шуны исеңдә тот! Синең Гансың». Шуның янында ук: «Яшәсен Германия революциясе! Полиция палачлары мине асып кына җиңә алмас! Сәлам якты дөньяга! Курт Гауфер, ташчы». Муса, шуларны укый-укый, түшәмгә таба үрелде: «Һитлер — бандит. Безне алдады. Ф. Нейман. 1933». «Хай живе Украина! Тарас. 1942. III». «Лучше умереть здесь, чем быть власовцем. Иван Власов. 1943».

Йөрәк каны белән язылган бу язулар бик күп иде, аларның һәрберсе уйландыра, билгесез бу көрәшчеләрнең йөрәк тавышын ишеттерә, өч авыз сүз белән олы бер тарихның фаҗигале сәхифәләрен ачып биргә кебек иде.

Шулай күңеле урыныннан кузгалып, алар язмышы өчен кайгырып, уйланып йөри торгач, бер көнне стенага яңа бер язу өстәлде. «Егылсам да җиңәм» дигән антым хәтеремдә минем һәркайчан. М. Җәлил. 1943. IX». Шуннан соң ул, туфли үкчәсеннән теше белән суырып алган нечкә кадакны, шушы хезмәте өчен кадерләп, пинжәк чабуының капшалмастай бер җөе эченә яшереп куйды.

Шул билгесез корбаннардан аның уйлары үз иптәшләренә күчте. Теге Мемориаль такта әвәләгән язуга караганда, Берлиндагы дуслары бар да төрмәдә булырга тиеш. Тик аларның берсен дә Мусаның очратканы юк. Ә менә легиондагы дусларының язмышы турында ул һаман әле һичнәрсә ишетә алмый иде. Исәннәр микән алар?.. Әгәр алынмаган булсалар... Әгәр...

Һәм ул кинәт татлы бер хыялга чума. Мавыктыргыч кыю планнар күз алдына килә: үзенең монда утыруына да карамастан, нинди дер юллар белән бәйләнеш тотып, эшне һаман дәвам иттерү мөмкин булмас идеме?.. Әгәр бөтенесе дә болай кинәт кенә өзелеп калса, күпме көч куелган эш сүнәчәк, күпме меңләгән солдат, котелгән иреккә чыга алмыйча, хәрап булуы мөмкин!..

Муса, бу хәвефле билгесезлекнең очына чыга алмыйча, әрле-бирле йөрене, ишек янына килеп туктый. Югарыдагы тәрәзәгә күзе төшә дә, андагы иптәшләре бәлки алынмагандыр, әле алай өметне өзәргә ярамыйдыр кебек тоела башлый... Нишләргә? Җеп очын каян табып, каян ялгарга соң!..

Ул шулар белән баш вата да, уйлары таркала башлагач, тагын стена белән сөйләшергә тотына. Ишек янындагы почмакта моңарчы бөтенләй укылмаган яңа бер язу бар икән: «Тоглер — провокатор. Сак булыгыз! Вилли. 1933».

Муса, өстенә суык су койгандай, чирканып китте. Аның үзеннән-үзе йодрыклары йомарланып килде: «Кем сатты безне? Кем ул шакшы җан — провокатор?..»

«Идел—Урал» тирәсендәге күп кенә адәмнәр турында уйлап карады ул. Ишбулдин, Хәнәфи, Шиһап, Нигъмәти, Солтан.

Болар ышанырга ярамастай шикле кешеләр иде. Ул аларны каршысына бастырып, мәрхәмәтсез кырыслык белән һәрберсен җентекләп күз-

дән кичерде: шуларның берсеме? Әллә Шәфи Алмаз үземе? Кем генә булыр соң? Ихтимал, бу хакта Алишмы, Булатмы, Шабаев яки Симаевмы бик яхшы беләә торганнардыр? Эх, менә хәзер аларның язуын да шушы стенадан табу мөмкин булсын иде! Ул чакта Мусаның хәле нинди җиңеләер, һәм тикшерүченең этлекле сорауларына каршы ул үзе провокаторны фаш итәр иде! Хәер... барыннан да элек үзе гаепле ул. Әйттеләр, күпме кисәттеләр! Ә ул, барыбер колагына элмичә, чемоданына листовка төяп чыкты. Шул җитмимени бөтен эшне җимерергә! Шул листовка булмаса, аны кем гаепли алыр иде? Һәм ул моннан тиз генә чыгып, оешманы саклап калмас идемени?..

Шундый каршылыклы һәм чияләй төендәй чишеп булмый торган уйлар белән интеккәндә, тикшерүче тагын аны допроска чакыртты. Бу инде унынчы яки унбишенче тапкырдыр, Муса хәзер аларның бөтенләй исәбен җуйган иде. Кайчандыр үзенчә бик нечкәдән башлаган һәм бик нәзакәтле кыланган Геденктафель, һәр очрашкан саен һаман усаллана барып, Мусаны ничек тә куркытырга, тел яздырырга, аяктан егарга тырышты. Мусадан кем кушуы буенча эшләвен, «шпионлык үзәген», «Мәскәү кулын» таптырырга тели иде ул. Әмма нинди генә хәтәр кеше булып кыланмасын, сәбәбен үзе дә белмәстән, Муса аңардан курыкмады. Аның шул кәмит кәяфәтен күргәч, ниндидер эчке горурлык белән үзендә өстенлек тоя һәм җирәнеп көлемсери генә иде. Ихтимал, шушы санга сукмавы Мусаның үз башына күп бәлаләр китергәндер дә. Чөнки үчлекле немец, үз корбаныннан әз генә булса да әдәп һәм буйсыну шикелле сыйфатлар күрмәгәч, отыры котыра барып, үзенең «клайн» һәм «гросс» концертлары белән күңел ачарга тотына иде. Бу чакыртуында да ул, Мусадан берниндн яңалык та ишетә алмагач, тагын шулар белән үк сыйлап кайтарды аны. Тоткындагы кеше түзә икән. Иректә чакта мондый ерткычлыкны күтәрә алуы мөмкин түгел кешенең, үзен-үзе һәлакәт чокырына ыргытыр иде ул.

Юеш тоз капчыгыдай сөйрәп кертелеп ташланган Муса, камера суык булганлыктан, озакламый аңына килеп туңа башлады. Куллары белән бер кырыйга шуышып, параша ящигына үрелде һәм, көч-хәл белән гәүдәсен калкытып, аның өстенә утырды, стенага терәлде. Суелып беткән аркалары шундук ут янып әчетергә тотынды. Ләкин таш стенадан бәргән салкынлык, ниндидер йомшак компресс шикелле, ул әчетүләргә әз генә җиңеллек биргәндәй булды. Һәр буыны аерым-аерым сулкылдап сызлый, күз алмалары кургаш баскандай кызып авырта иде. Шулай аркасын һәм башын таш стенага терәгән, күзләрен йомган килеш озак, бик озак утырды ул. Аңын каплаган соры томан әкрен-әкрен таралып киттеме, әллә кан йөреше үз эзенә төштеме, аның зиһене әз-әз ачыклана барды, күзләре ачылып, каршы стенаның түшәм почмагына терәлде. Үзе абайлаган беренче уе: «Бу соң нинди Германия?..» дигән газаплы һәм һаман аңланмый торган ачы сорау иде. Чынлап та... Синме соң бу, Муса белгән ил?.. Ул әле яшь чагында ук, Европа әдәбияты белән таныша башлагач та, Шиллерне, Һетене, Һейнене һәм немецның тагын бик күп шагыйрь вә әдипләрен укып, береннән-бере талантлы һәм кинрәк колачлы композиторларына таң калып, яңа идея титаннарына табынып, үзе белгән шул Германиягә бөтенләй гашыйк булып йөргән егет иде бит. Кайда шул Германия?!.

Ул, сызлаган сөякләрен көчкә сөйрәп, тәрәзә каршына килде. Аңлау мөмкин булмаган шушы ачы сорауга, үзенең шушы караңгы кичерешләренә инә күзедәй генә бер якты нокта табарга теләгән кебек, тимер челтәр артындагы киң дөньяга йотылып карады. Ләкин ул тар дүрткелдән бары тик кызыл кирпеч өемнәре, көл төсле соры суык стеналар гына күренде, сокланып кояш та, күңел җилкетерлек якты киңлекләр дә юк иде. Гүяки, моңарчы ул белгән тылсымлы йолдызлар бу караңгы илнең күгендә беркайчан да балкымаган, анда бөтенләй [illegible] ба-

ры тик алдавыч аҗаган гына уйнаган! Гүяки бу ил, мәңге шулай вәхши караңгылыгында яшәп, фәкать әнә шул әшәке кара көчләрне, Гитлер, Геббельсләрне генә тудыра алган! Гүяки бу илнең күгенә ничәмә-ничә урыннардан бары тик биек кара морҗалар гына күтәрелә һәм алардан адәм баласын яндырган сасы кара төтен дөньяга тарала! Әллә соң бу зур халыкны шушы кыска гына вакыт эчендә фашизм дигән йогышлы чир шундый кабахәтлеккә китереп җиткергәнме? Әллә бу әшәке сыйфатлар тумыштан ук немецның канына салынганмы? Бу ил кешеләре шуңар күрә үзләреннән башка бер кешене дә яратмаулары, аларны түбән санау, җәберләүләре белән горурланамы? Шуңар күрә комсызлыкны үзләренә алла итеп, бөтеннәрнең актык сыныгын, актык чүпрәген тартып аламы?..

Муса сәгатьләр буена шушы авыр уйлардан котыла алмады. «Синме соң бу — бөек Маркс иле һәм давыллы Шиллер ватаны?..» дип пышылдый иде ул. Үзенең яралы аркаларын да, сулкылдап сызлаган буыннарын да оныткандай булды. Бу ил белән, бу халык белән сөйләшәсе, үзенең актык тавышын ишеттерәсе килә иде аның. Җанын газаплаган уйларны әйтеп бирсә, җиңелрәк булыр кебек тоелды. «...Тоткын итеп сиңа китерде дә, «кол» дип мине немец атады...» Бу аның күп җәберләрдән соң туган һәм җаны-тәне белән әрнеп әйткән үпкә сүзе иде. Үзен шулай тетрәткән караңгы һәм әшәке Германия турында шундый тирән борчылып уйланулары, әмма шуның белән бергә, аның каядыр яшеренгән якты көчләреннән әле һаман өмет өзмәве, аларга хаклык сүзен ишеттерәсе һәм аларны көрәш мәйданында күрәсе килүе, ниһаять, кайнар җырга әверелеп, күңел түреннән түгелә башлады:

Әйт син миңа: утлы, «Рот-фронт»лы
Көннәреңне кая югалттың?
Нигә мине — Клара әбисенең
Сөйгән улын — кыйнап елаттың?

Шулай дипме сине белә идем,
Гете белән шашкан чагымда?
Бетховенның кыю симфониясе
Ник яңгырамый мәрмәр залыңда?

Хөр йөрәкле Гейне гашыйгына
Хуҗаң тимер богау кигезде.
Карл белән Роза каны тамган
Төрмәләрнең бозып имезде.

Мин күрмәдем синдә кояш нурын,
Баскан аны канлы тузаның.
Тик татыдым батыр Тельман яткан
Подвалларның авыр йозагын...

. . . . . . . . . .

Арагызда кем бар Цеткин улы,
Тельман егетләре кайсыгыз?
Ишетегез бөек хаклык сүзен,
Төрмәләрне безнең ачыгыз!..

Әмма Цеткин уллары да, Тельман егетләре дә килмәде, төрмәләр ачылмады. Чөнки алар үзләре дә Бухенвальд, Дахау, Маутхаузен шикелле йөзләгән исемдәге үлем чокырларына тутырылган иде. Ихтимал, шуңа күрәдер, Муса иректә чакта да аларның берсен дә очрата алмады, ә бик тә эзләп йөргән иде, югыйсә. Булмады шул. Инде немец төрмәләрен ачарга Ленин егетләре килми булмастыр. Башка һичкем моны эшли алмаячак! Тик ул егетләр әле еракта, һай бик еракта. Өзелмәсме Мусаның нечкә генә булып калган гомер җебе?.. Өзелмәсме алар килеп җиткәнче?..

Иртәгесен Мусаны икенче тапкыр прогулкага чыгардылар. Башка бөтен бәхетләре үтерелгән төрмә кешесе өчен моннан да зур бәхет юк. Беренче мәртәбә аны унсигез көннән соң чыгарып, унбиш минут йөрт-

кәннәр иде. Үз этажларыннан чыккан утыз-кырык кеше арасыннан бер генә таныш-белешен дә, һич югында берәр русча сөйләшкән кешене дә очратмады ул. Тик бер озын гәүдәле кеше генә аңа: «Син хорват түгелме?» дип, немецча эндәште. Шул да, шушы чит кешенең кешечә эндәшүе дә, бәхет иде.

Менә бүген, унбиш көннән соң, тагын чыгардылар. Тар гына озынча ишек алды. Сентябрьнең шактый түбән иңгән кояшы, ишек алдына төшеп җитә алмыйча, төрмә корпусы башларына эленеп кала. Шул шыксыз мәйданчык уртасына ярты метр биеклектә, бер генә кеше басарлык итеп, бетоннан озынча түгәрәк ясалган. Надзиратель үз карамагындагы тоткыннарны алып чыга да шул бетон «күпер» өстенә тезә. Үзе түгәрәк уртасындагы буш урынга кереп баса. Һәм тоткыннар унбиш минут буена аның житез күзәтүе астында әйләнеп йөриләр. Гүя алар кешеләр түгел, ә кыргый киекләр. Уртадагы надзиратель шул кыргый киекләрне цирк һөнәренә өйрәтүче маэстро. Аның күзгә күренмәс камчысы озын һәм зәһәр. Әз генә читкә тайпылдыңмы, камчының кылдан ишкән очы чажлап синең ботыңа яки биләңә килеп төшә...

Түгәрәкнең тар башыннан борылганда, үзеннән арттагырак бер кешенең аны тырышып күзәткәнлеге Мусаның күзләренә чалынып калды. Икенче башны әйләнгәндә, ул аның үзен күзәтә башлады: өстендә легион солдаты кителе, ялан баш, чем-кара кыл чәчле, төптәс гәүдәле, бүрәнкәрәк авызлы... Туктале, тукта... бу бит Кылычбай түгелме соң?.. Димәкки, алар да... Алар да!..

Муса, кинәт хәле киткән гәүдәсе белән артка борылып карый-карый атлый торгач, хәтта панель өстеннән егылып төшә язды. Надзиратель аңа кычкырып җибәрде:

— Алдыңа бак, швайн!

Алар никадәр карашсалар да, бер-беренә якын килү мөмкин түгел иде. Тик унбиш минут узып, баскычтан менгәндә генә, гомуми буталчык арасында, Кылычбай Мусаны куып җитте, биленнән кочаклады, алай уңайсыз булгач, култыгыннан кысты. Алар икесе дә бер-берен сагынышканнар иде. Башкорт егете, Мусаның сорауларына тиз-тиз җавап бирергә тырышып, өлгерә алган хәтле барын да сөйләп алды.

— Уныңчы август. Кырыклап кеше. Кайберләрен легионда ук кире чыгардылар. Кайберләре Аршау төрмәһеннән кайтарылды. Рушатов, Кормаш, Фәритев, Сәйфелмөлеков, Батталов, Хәсәнев Зиннәт, Шәрипов, Фәхри Димски һәм мин — Берлинга китерелдек. Мин монда Зиннәт белән генә бугай. Аның хәле бик авыр. Башкаларны Тегельгә озаттылар шикелле. Монауда урын юк, имеш...

Бу фаҗигале хәбәр Мусаны артык таушалтып җибәрде, бишенче катка көч-хәл белән генә менеп җитте ул. «Бөтен тармаклар буенча һәлакәт... Нишләдек соң без?..» дип кабатлый иде ул. Актык баскычларны менгәндә:

— Допроста ничек соң үзең?.. — дип сорады.

— Без нык торабыз, беребез дә бирешмәй, Муса абый, — диде егет.— «Белмәем!» — җавап шул...

Егет үзенең 95 нче камерасына җитте дә ишеккә карап басты.

— Шулай дәвам итегез! — дип пышылдады Муса һәм үз камерасына узып китте. Кылычбай аның кайда туктаганын күз кырые белән генә карап торды: бер, ике... биш... җиде, сигез... Әһә, сигезенче булып туктады: 103 нче камерада икән...

Камерасына кайтып кергәч, Мусага тагын да авыррак, моңсу һәм күңелсезрәк булып китте. Бөтен дөнья караңгы болытлар астында, таш төрмәләр куенында калган кебек тоелды. Инде ничә мәртәбәләр кабатланган үкенү сүзләре тагын кабатланды. «Кемдер сатты безне... Юк, немецлар үзләре генә берни дә белә алмаслар иде... Кем? Кем булыр ул мөртәт?..»

Шул каһәрле сорауга җавап табудан гаҗиз булып, ишекле-түрле йөренә торгач, тәмам алҗып, талчыгып идәнгә ятты. Аны шундук кандала сарып алды. «Цивилизацияле немецларның Берлин уртасындагы зиндан камераларында бу комсыз хәшәрәтләр мыжылдап тора һәм, тоткыннарның актык каннарын суырып, симереп беткәннәр иде. Монда кергәннән бирле Муса алар белән байтак кына сугыш алып барды, хәтта үткен кинаяле бер шигырь дә язарга мәҗбүр булды. Әмма бүген ул аларга игътибар итәрлек хәлдә түгел иде, үзен бөтенләй таркатып ташлаган яңа кайгыдан әз генә онытылмакчы булып, күзләрен йомды, йокларга теләде. Ләкин алай җиңел генә онытылып китәргә язмаган икән әле, уйлар газабы тагын ялганып китте: «Каберебез шушы төрмә булыр микәнни?.. Кабер... Кайда ул кабер?.. Бәхетлеләрнең кабере билгеле бер зиратта, тимер чардуган эчендә, гөлләр арасында, якыннары янында була. Ә безнең кабер?.. Ул инде адәм аяк басмый торган нәмәгълүм бер урман эчендә, ач бүре өере генә улый торган текә ярлы ташландык бер чокырда булыр. Анда безнең шикелле йөзләгән-меңләгән гаепсез кешеләр аударылыр. Җир белән тигезләп күмәрләр... Кая сина киртә, кая сиңа, ичмаса, сыңар гына гөл сабагы? Хәтта исемең язылган такта башы да булмаячак. Илеңнән балаң килеп, дустың килеп эзләсә дә, тик бер генә эзеңне табудан да гаҗиз калачак...»

Камерага кичке эңгер керде. Мусаның күзләрен сөртелмәгән яшь ярысы каплаган иде. Ихтимал, шуңадыр, ишек катындагы почмакларны күк томан сарган шикелле күренде. Хәрәкәтсез күзләр шунда төбәлгән килеш уйлар газабы һаман дәвам итә иде әле... Менә кинәт уң почмактагы юка гына томан эчендә үлем шәүләсе пәйда булды. Ул үз төсендә иде: шыр-сөяк гәүдә, шүрәленекеннән дә озын һәм шылтырап торган бармаклар, упкындай караңгы күз чокырлары, ыржаеп торган тешләр тезмәсе, чиртсәң — шыңлап көй чыгарыр сыман юка кабыргалар арфасы. Болар һәммәсе беравык эчендә Мусаның күзенә чалындылар да, ул сискәнеп китте. Хәтта курыкты да шикелле. Урыныннан сикереп торып, каядыр качарга теләде, ләкин кузгала алмады, әйтерсең, кадаклап куйганнар иде аны. Бәләкәй чактагы шикелле, «тфү-тфү» дип, як-ягына төкермәкче булды, тик иреннәре ачылмады, әллә нинди сагыз сыман нәрсә белән ябыштырып куйганнар икән. Төрлечә борылырга маташса да, барып чыкмады — ниндидер таш астында калган кебек иде. Шуннан соң үлем аңа көлемсерәп бераз якын килгәндәй булды да, «Курыкма!» дип, бармак янады. Мусага бик кызык тоелды бу: үзе үлем, үзе курыкмаска куша! Һәм ул кычкырып көлеп җибәрде. Бу юлы аңа иреннәрен ябыштырган сагыз да комачау итмәде. Ул әле хәтта: «Ник килдең монда?» дип сорый да алды. Әмма монысы инде бөтенләй әрсезлек иде, үлемгә ошамады, ахрысы, ул шундук көлүен сүндерде дә, шыр-сөяк чыраен ачу белән ыржайтып, Мусаның тезенә китереп типте.

— Аллаһ! — дип кычкырып җибәрде Муса һәм үз тавышына уянып китте. Ул, чыннан да, йокыда булган икән. Камера эче дөм-караңгы иде.

— Фу, шайтан алгыры, — диде ул һәм кузгалмакчы булды. Баягы тезе тагын авыртып китте. Җентекләбрәк караса, аның нәкъ өстенә диярлек, автоматик ачыла торган койка аягы төшеп баскан иде. Муса көлеп җибәрде: менә ничек икән ул әҗәл типкән тез!

Хәзер инде ул койкасына менеп ятты да үлемне хәтерләде. Каян килеп керде әле ул аның төшенә? Ә-ә, каберләр турында уйлаган иде бит... Гаҗәп, «Курыкма!» дип көлемсерәве нәрсә икән? «Яшәрсең, үлмәссең, үтерә алмаслар!» дигән сүзме?.. Муса эчке өмет яктылыгы тулган күзләрен югарыга, караңгы түшәмгә текәде. Тик анда бәхет йолдызлары күренми иде.

— Эх, бер әйбәт кенә төш юраучы, фал ачучы әби булса икән монда! — дип куйды ул, үз-үзеннән көлеп. — Һәммәсен әйтеп бирер иде...

Шундый җан һәм тән газаплары белән, төрмәнең бөтен әшәкелекләре, бөтен катылыклары һәм бөтен шакшылыклары белән, тагын унбиш көн узып китте. Яңадан прогулкага чыгу сәгате якынлашты. Дөньяның искә дә алынмый торган иң гади генә ирекләреннән дә мәхрүм булган кешеләр өчен тышта үткәрелә торган бу унбиш минут, ачы көләнеч булса да, үзенчә бер бәйрәм сыман тоела иде. Шул шырпы тартмасыдай тар һәм сасы ишек алдында булса да саф һава аласың, бәхетле буласың — танышларыңны күрәсең, хәтта бер-ике сүз алмашу хәйләсен дә табасың. Муса да бу минутларны зарыгып көтеп алды. Допроста умырылган сәдәпләрен, балагының эчке чабуыннан җеп суырып, әлеге кадак ярдәме белән урыннарына такты. Чалбарын астына салып «үтүкләде», шул ук допроста өч-дүрт кенә теше калган тарагы белән чәчләрен тарады. Таушалып беткән күк күлмәге белән костюмын да рәткә китереп киде, соры туфлиен дә чистартты. Ул бүген Кылычбайны яңадан күрү өметендә иде. Башка иптәшләре очраса да, өс-башының ыктымат күренүе яхшы, алар борчылмасын...

Әйе, әгәр дә унбиш көн эчендә андый-мондый хәл булмаган булса, Кылычбайны, әлбәттә, күрер ул. Ә күрсә, легион хәлләрен, андагы дусларын яңадан сорашыр. Кемнән шикләнүен, кемнең хыянәтче булу ихтималын белергә тырышыр. Аннары егеткә үз адресын бирергә уйлады ул. Чөнки Кылычбайның болар тырнагыннан котылу ихтималы шактый зур: аның күренеп торган гаебе юк, аңардан листовка чыкмаган, оешмада торганы немецлар өчен ачык мәгълүм түгел. Шулай булгач, бәлки ул якты дөнья йөзен күрә алыр. Ә шуның белән бергә Мусаның да соңгы эзләре кайда югалганын якыннарына хәбәр итәр. Бер утырып искә алырлар...

Муса әйләнә-тирәсен күзәтенде. Нәрсәгә язарга соң? Бармак битедәй кәгазь кисәге дә, тырнак очыдай карандаш сыныгы да юк. Ул кесәләрен актарынды, әйләндереп селкесә дә, әлеге тарактан башка һичнәрсә чыкмады. Кара пластмасса таракның актык тешләренә карап торды. Һәм аларны тиз генә кырып ташлады да әлеге бәләкәй кадак белән тарак сыртының бер ягына Казан адресын, икенче ягына Мәскәү адресын тырнады. Әйбәт чыкты, җуелмаслык булды.

Һавага чыгару башлангач, Кылычбай белән күрешүне көткән Мусага, баскычтан төшкәндә үк, бөтенләй икенче кеше очрады. Кайчандыр һәрвакыт көләч йөз белән йөрүче, йомшак баритон тавыш белән җырлаучы, ә хәзер бик боек чырайлы күренгән Фәхри Димски иде бу. Кинәт кенә болай бер-берс белән очрашуларыннан икесе дә бик куаныштылар һәм шунда ук сөйләшә-сөйләшә түбән төшә башладылар. Муса сораулар яудырырга тотынды. Аңа һәр очраган кешедән ичмаса бер генә, бәләкәй генә яңалык ишетсә дә, ниндидер бер тотка, ниндидер бер таяныч булыр, хәтта котылу юлы ачылыр кебек иде. Фәхри үзе белгәннәрнең барын да сөйләп бирде, теге көнне Кылычбай әйткәннәр дә кабатланды аның сүзләрендә. Әмма Муса барыбер бүлдермичә тыңлады. Аннары Димски тагын нәрсәдер әйтергә теләп тә, тыелып калган кыяфәт белән башын кашып куйды.

— Сөйлә, сөйлә, — дип кызулатты аны Муса. — Тагын ниләр бар, ниләр беләсең?

— Ниләр, дип... Әллә ни юк та кебек инде дә... Әйтүе дә кыен шунда...

— Сузма, сузма, — дип түземсезләнде Муса. — Сузмый гына сук!

— Сук, дип, ни бит... Әйтмичә дә булмый шул... Әшәке нәрсә инде ул... — дип уңайсызланды егет, сүзләрен өзгәләп. — Безне сатучы Мәмүт Ямалтаев булган...

Муса алдан төшә иде, кинәт борылып, күзләре тулы аптырау белән Фәхригә карады.

— Ямалтаев, дисеңме? Кайсы ул?

— Ник, теге, күзлекле тыңкыш бар иде бит. Яңа пропагандист. Бөтен кыланышларын ук яратмый идем шуның, сагыз шикелле сылана иде, җырла да җырла, имеш...

— Ничек, ничек соң ул? — дип ашыктырды Муса.

Озын буйлы Фәхри, Мусага иеләрәк төшеп, үзенең Варшава төрмәсендә прогулкада йөргәндә Рушатов белән очрашуын һәм аңа Габдулла Батталовниләр әйткәнен сөйләп бирде. Алар баскычтан төшеп җиттеләр дә әлеге бетон панель өстенә менеп тезелделәр. Кинәт тетрәнеп киткән Муса, башын түбән иеп, байтак кына сүзсез атлады. Аның артыннан атлаган озын муенлы Фәхри сузылып-сузылып аңа караштыргаласа да, ул тиз генә эндәшмәде, үз уйларына күмелде. Менә ничек икән ул... Әйе, хәтерли: тәбәнәгрәк буйлы, яньчек борынлы, тыңкыш тавышлы... Песидәй юаш кына кылана... Кормаш ашыгып ышанды микәнни соң? Якташ ди иде, бугай. Баттал да ашыгып эш иткән икән шул... Ә хәзер үзенә хөкем чыгарган. Хөкем... Кяшки ул хөкем белән генә хәлен төзәтеп булса иде! Муса хәтта үзенә дә андый хөкемне кабул итәр иде. Төп җитәкче буларак, тимер дисциплина урнаштырмавы өчен...

— Муса абый, — диде Фәхри. — Сез ул хәтле кайгырмагыз. Әгәр башым исән кала икән, мин ул бәндәне дөнья йөзендә йөртмәячәкмен. Җиде кат җир астына качса да табып алырмын. Менә синең алда ант итеп әйтәм, минем хөкем аңа шул. — Фәхри ике кулының озын бармакларын бөҗраландырып күрсәтте: — Барыбыз өчен дә! — дип өстәде ул.

— Рәхмәт, мин әйтәсе сүзне син әйттең, — диде Муса, кәефсез генә тавыш белән. — Әмма аның илгә кайтмавы бик мөмкин бит. Көнбатышка качар ул.

— Аңарчы! — дип кайнар пышылдады Фәхри. — Тик моннан гына ычкыныйм... һәм ычкынырмын да! Мин җырчы гына бит. Артист. Гел йөреп тордым. Берни белмәдем — шулай сукалыйм мин.

— Шулай сукала, — дип раслады Муса. — Дөрес булыр. Сине ничек кенә булса да котылдыру өчен тырышырбыз...

— Әмма минем өчен бер корбан да кирәкми, Муса абый, — диде Фәхри, калтыранганрак тавыш белән. Аның күңеле нечкәреп, өмет, яхшылык һәм нәфрәт белән дулкынланганы сизелеп тора иде. — Сез болай да минем өчен мәңге онытылмаслык изгелек эшләгән кеше. Сез миңа хаклык юлын күрсәттегез, дөньяның яңа матурлыкларын ачтыгыз!..

Муса эндәшмәде. Аның уйлары, яхшылык-явызлык, җинаять-хөкем шикелле мәңгедән килә торган кыен төеннәр эчендә чуалган иде. Кешегә кул күтәрү — нинди авыр эш! Әмма берәү, үзенең кешелек сыйфатын югалтып, башкаларга зыян сала башласа, бик күпләр аның аркасында бәхетсезлеккә дучар булса, ул чагында нишләргә?.. Бөтен кешелек җәмгыяте өчен уртак яхшылык — гуманизм дип атала. Ләкин гуманизмның да җәмгыять иминлеген саклау өчен каты хөкемнәре бар. Ә Ямалтаев иң әшәке хаинлек эшләгән. Димәкки, Фәхри чыгарган хөкем дөрес!..

— Корбан турында баш ватмыйк, — диде Муса, ниһаять, сүзгә килеп. — Барыбыз да гаделсезлек корбаны... Ә хөкемгә мин дә кушылам. Ләкин без әле оешманың бары ике генә әгъзасы. Әгәр син башка иптәшләрне күрсәң, безнең карарны аларга әйт. Мин күрсәм дә әйтермен. Алар да шуңа кушылсалар, бу хөкем, иртәме-соңмы, җиренә җиткерелергә тиеш!

— Антым шушы! — диде Фәхри, гәүдәсен турайта төшеп. — Үтәлер!..

Кыен сүз иде бу. Озакка сузылды. Башка нәрсәләр хакында сөйләшергә дә өлгермәделәр, керергә команда булды. Муса Кылычбайны да күзәтә алмыйча калды. Чыккан идеме ул, юкмы — күзенә чалынмады. Һәм алда тиз генә күрә алырмы ул аны?.. Баскычтан менгәндә, Муса Фәхринең артына туры килде. Шунда аның адрес мәсьәләсе исенә төште. Нишләргә соң? Әгәр Фәхригә генә тапшырса? Нигә, икесе дә якын

дуслар ич. Һәр икесе дә кыенсынмый үтәр аның соңгы теләген... Һәм ул әлеге тарак сыртын чыгарды да Фәхринең китель кесәсенә төшереп җибәрде. Баскычтагы ыгы-зыгы белән егет аны үзе сизмәде дә.

— Беләсеңме, Фәхри, — диде Муса, өченче катка менеп җиткәндә. — Дөньяның хәлен белеп булмый... Кайсыбыз исән калсак та, гаиләләребезгә хәбәр итешик... Мин синең кесәңә адрес салдым. Сакларга тырыш, әйбере сакланмаса, күңеленә сеңдереп куй. Шул адреслар белән барып табып, минем кызыма, әгәр көткән булса, Әминәмә, безнең бергә тартышканнарны, бергә газап чиккәннәрне сөйләрсең... Икенче прогулкага син дә адресыңны язып алып чык. Мин дә Зәй буйларындагы Акбаш авылына, әниең янына барырмын... Һәм белмәссең, бәлки без шунда, кочаклашып тагын күрешербез!..

— Мин дә шуны бик телим, Муса абый, — диде Фәхри. — Шундый куанычта исән-сау күрешсәк иде!

— Шуңа күрә допросларда нык тор. «Белмим»нән башканы белмә! — дип, тагын бер кисәтте Муса. — Чыгармый хәлләре юк, чөнки синнән һичнәрсә табылмаган бит. Ә инде моннан котылгач, Франкфуртка бар, Одердагысына. II вокзал, пивзавод. Шилов. Кайсы баракка кереп сорасаң да аны беләрләр. Ул сезгә ярдәм итәр һәм нишләргә кирәклеген дә әйтер. Безнең хәлләрне дә сөйләп бир. Ул хикмәтле кеше. Әлемтәсе зур... Тиешле чараны күрми калмаслар...

— Ярый, Муса абый. Әгәр тиз генә легионга озатмасалар, обязательно барам.

— Берлинда калырга тырыш. Радиога сора. Җырларга.

Димски үз ишеге төбендә тукталып калды, сүзләре дә кинәттән генә өзелде. Тагын әлләниләр сөйләшәселәре бар иде әле, ләкин булмады... Аның янында бер генә авыкка тоткарланган Мусаны надзиратель төрткәләп ары таба алып китте...

Икенче тапкыр күрешү насыйп булмады аларга. Фәхри Димскине, тагын ундүрт көн буена җәфалап та, гаебен исбат итә алмагач, унбишенче көнне икенче каттагы махсус бер кабинетка чакырдылар. Әйберләрен җыеп төшәргә куштылар. «Күчерәләрме, әллә расходкамы?» дип уйлады егет. Надзиратель аны ашыктырды һәм, йөзе белән төрле ямьсез кыяфәтләр ясап, «русь капут», диде. Фәхри аның мыскыллавына карамады, монда андый гына хәлләр игътибарга гомумән алынмый иде. Икенче кат коридорыннан барганда, бер ишекнең ике ягында ике кеше стенага каратып бастырылган, куллары артка куелган иде. Димски аларны баштан-аяк карап узды һәм берсе Алиш, берсе Шабаев икәнен танып алды. Күрәсең, аларны да берәр башка урынга озаталардыр. Бергә туры килсәләр, нинди шәп булыр иде. Эндәшү, әлбәттә, мөмкин түгел, шулай да тамак кырып узды егет. Бу аның сәламе иде. Һәм егетләр, башларын бора төшеп, карап калдылар. Таныдылар микән?..

Надзиратель, өченче ишекне кагып, Фәхрине китереп кертте. Ул зур кабинетта өч хәрби немец утыра, дүртенчесе гади киемле тәрҗемәче һәм тагын өч татар егете бар иде. Аларның барысына да сәясәт белән шөгыльләнмәскә бик каты кисәтү ясадылар һәм шул хакта русча язылган кәгазьгә кул куйдырдылар. Аннары капитан дәрәҗәсендәге берсе рус телен вата-җимерә һәм имән бармагын яный-яный әйтте:

— Ми вась осьвожжаем пот надзор! Помнить? Пафторяеть — вешайть! [1]

Егетләр куанычларыннан нишләргә белми чыгып киттеләр. Баскычта ук танышып өлгерделәр: Симаев дигән кеше белән бергә эшләгән Фәйзелхаков, Зиннуров, Хәтфуллин икән алар...

---

[1] Без сезне күзәтү астында ирекккә чыгарабыз! Исегездә тотыгыз, кабат тотылсагыз — асабыз!

...Кулга алынуларына ике ай тулганда, Муса һәм аның иптәшләренең эшен тикшерү, нигездә, тәмамланды. Гаепләрен исбат итү мөмкинлеге табылмагач, кайберләрен чыгарырга мәҗбүр булдылар. Әлеге егетләрдән тыш, Мичурин, Омаров, Сафиннарны, икенче батальоннан Уразаев белән Бикмулла «хәзрәт» һәм башкаларны кайтардылар. Берлин төркеменә кергән Мусаны, Алишны, Фоатны, Гарифны һәм Әхмәтне Лертер урамындагы төрмәгә күчерделәр. Алар хәзер суд булуын көтәргә тиешләр иде. Едлино төркеменнән Гайнан Кормашны, Габдулла Батталны, Фоат Сәйфелмөлекевне, Зиннәт Хәсәневне, Рушатовны, Фәритевне, Габбас Шәриповны, Варшавадан китереп, Тегель төрмәсенә бикләделәр. Алты кешелек Познань төркемен озак вакытлар Александерплац төрмәсендә тоттылар. Аларга куелган төп гаеп: совет радиосын тыңлау һәм совет пропагандасы тарату иде. Намуслы татар егетләрен шул гаепне танытыр өчен сигез ай җәзалап та, барыбер һичнәрсә икърар иттерә алмагач, һәммәсен дә Бухенвальд концлагерена, мәңгелек каторгага җибәрделәр.

Муса, шул ук төрмәдә ике ай ятса да, Фәхри Димски белән Кылычбайдан башка үз дусларының берсен дә күрә алмады.

## VI

Легиондагы оешма кешеләрен гестапо алып киткәч, Зикендорф әфәнде җиң сызганып эшкә кереште.

Батальоннардагы бөтен солдатны, төн уртасында хәрби тревога ясап, тентетеп чыкты. Бөтен баракларны, солдатның шәхси әйберләрен актарып, таң атканда салам матрацларны тышка кактырды. Билгеле инде, берәүдән дә инә очы кадәр шикле нәрсә табылмады. Шул табылмаган өчен булса кирәк, ахры, бөтен солдатка резин таяклар белән «маленьки экзекуци» ясадылар. Бөтен шомлы эшләрнең башы шуннан гына чыккан кебек, музыкаль капелланы туздырып ташладылар. Анда калган артистлар взводларга таратылды, элекке пропагандистларны да шунда сөрделәр, курслардан кайткан яңа пропагандистлар куелды. Легион солдаты кулында корал заты калмады, складларга сакчылар бермәбер көчәйтелеп, гел немец солдатлары гына куела башлады. Ә легион солдатлары, көненә ике сәгать агач таяк белән уйнаганнан соң, якын тирәдәге станцияләргә йөк төяргә яки бушатырга, төрле хуҗалык командаларында эшләргә җибәрелә торган булды. Шулай итеп, немецларның күпме көч һәм сәрмая түгеп хәзерләгән «Идел-Урал» легионы сугышчан бер көч булу сыйфатын тәмам җуйды.

Бер ай шулай узды. Солдатлар арасында тынычлык та урнаштырылды төсле. Ләкин Зикендорф әфәнде яхшы аңлый: утын кисүчеләр легионы нигә кирәк? Югары командованиенең, әлбәттә, моның белән килешеп торуы мөмкин түгел. Орел—Курск тирәсендәге грандиоз һөҗүм тагын кире якка борылды, Русь һаман болай таба килә... Көн саен кырып-себереп резерв җибәрелә, немец җитми. Димәк, легионнар да сугышка озатылырга тиеш!..

Зикендорф әфәнде шулай уйлаган иде дә бит, иртәгесен ОКВ дан сак булу өчен яшерен депеша килде. Аннан аңлашылуынча, Радом артындагы әрмән легионы, фронтка җибәрелә башлагач, баш күтәргән. Тиз генә коралсызландырып, төньяк Франциягә озатырга туры килгән. Восстание башлыгы, Тулиян кушаматлы медик, качып котылган. Озын буйлы, кара чәчле, күе кара сакаллы, Кавказ, Кырым татарына яки нудага охшаган кара йөзле кеше, каш өстендә әз генә җөе дә бар икән. Башка көнчыгыш легионнарына килеп посуы ихтимал булганга, һәр җирдә күзәтелергә кушылган... Шул ук сәбәп буенча грузин батальоны да коралсызландырылып, Голландиянең Балтиктагы бер атавына җибәрелгән... Кельце шәһәрендәге әзербәйҗан легионында фетнә таратучы,

солдатларны поляк партизаннарына качыручы дүрт башкисәр строй алдында атылган. Легион шефларына мондый чаралар кулланырга киң хокук бирелгән...

— Хо-хо-хо, — дип куйды легион башлыгы, бу язуны укып чыккач, бик борчылып. — Нигә соң әле безнең хәлләр сөйрәлеп беткән иске шинельгә әйләнде? Кай җиреннән тотсаң, шуннан сүтелә...

Ә шул ук көнне кичке якта яңа боерык алды ул. «ОКВга мәгълүм булуынча, «Идел-Урал» легионында тынычлык урнашып килә. Ихтимал, явызлар котыртуы артык тирән йогынты ясый алмагандыр. Шул сәбәпле сезгә боерык бирелә: Краков, Конськи, Радом, Кельце шәһәрләрендәге тыл частьлары карамагына берәр рота солдат җибәрергә. Корал бирмәскә. Урында, хезмәтләренә карап, бирелер...»

Зикендорф әфәнде җиңел сулап куйды: ниһаять, бу татарлар немец ипиен әрәмгә черетеп ятмаячаклар! Иртәгесен үк китәсе роталар билгеләнде. Тиешле амуниция һәм коры паеклар өләшенде.

Хәзер инде взвод командиры булган һәм икенче медаль таккан Мәмүт Ямалтаев, бу хәлне күрү белән, фельдфебель Блокк янына йөгерде. Бу көннәрдә ул бик нык куркуда яши иде. Чөнки төрмәдән кайткан егетләр ашамы, әллә башка юл беләнме, кемнәрдер аның башына җитәчәген ишеттерделәр. Ул хәтта төн йокыларыннан калды, моннан качарга ниятләп йөри башлаган иде, тик анысы тагын да куркынычрак күренде: немец тотар да атар, синең кем икәнеңне сорап торамыни ул...

Тыны-көне бетеп, ишектән керү белән гестапочының аягына егылды:

— Калдырмагыз мине монда. Җибәрегез берәр рота белән! — дип ялварды ул.

Аны-моны аңгармаган Блокк иягенә тибеп җибәрә язды аның. Ашыкма тибәргә, Ямалтаевның да синә кирәк чаклары булды түгелме соң ди иде аның итагатьле күзләре һәм шул хәлендә килеш ул үзе ишеткән хәбәрне әйтеп бирде. Блокк аның белән сөйләшеп тормады. Зикендорф янына алып керде дә:

— Озатыгыз бу черегән борынны да берәр рота белән, — диде немецчалатып. Мәмүт ул телне рәтләп белми иде, ләкин Блоккның җирәнеп сөйләвеннән сүзнең үзе турында баруын бик тиз аңлап алды...

Роталар китүгә ун көн дә узмагандыр, шомлы хәбәрләр, берсе артыннан берсе, һерр Зикендорф башына ява да башлады:

«Сезнең егерме легиончыгыз кырык немец солдаты белән бергә Украина фронтына амуниция эшелоны озатырга җибәрелгән иде. Бары өчәве генә кире кайтты, калганнары качканнар. Өстәмә җибәрегез».

«Краков читендә тимер юл полотносы сакларга куелган татарларыгыз качып бетте. Өстәмә җибәрегез».

«Кельцедән ары Н. станциясендә складлар саклаучы ике взвод татар төнлә белән полякларга качты. Андый дуңгызларны монда ник җибәрдегез? Ышанычлы өстәмә кирәк!»

— Тагын бишәү, тагын унбер, тагын тугыз, тагын унөч! — дип утырды Зикендорф әфәнде, кәгазьләрне чөя-чөя. Аның ачуы башына капты, креслосыннан торып, ишекле-түрле йөри башлады. Күз алдында Муса, Кормаш һәм Рушатов пәйда булды. Тамырлары бүрткән йодрыгын югары күтәрде ул. — Ах, чәчкәнсез икән агуыгызны! Ну мина эләксәгез!..

Икенче батальонда да хәлләр шундый иде. Уразаев төрмәдән кайтып төшкәч, ярты батальонны танымады. Анда хәзер Демблин һәм Седельцедән яңа кешеләр китерелгән, ә батальонның иске солдатлары кая җибәрелсәләр, шуннан качып беткәннәр. Харис белән Бикмулла төрлесен уйлап карадылар. Эшне яңадан әүвәлгечә торгызып булмаячак иде, элекке сыналган кадрлар таралып беткән. Качучы вак төркемнәрнең башында шулар торганнар. Хәзер андыйларны яңадан тәрбияләү өчен күп вакыт кирәк булачак. Батальон составы да һаман үзгәреп тора. Поляклар белән дә элемтәләр өзелгән. Шуңар күрә алар шушы вакытта ачу

стихиясен куәтләргә булдылар. Урыны-җае килгән саен, шул утка керосин сиптеләр. Озакламый үзләре дә Карпат тираләренә җибәрелә торган ике рота белән китеп бардылар. Һәм шул роталарның берсе, Польша Карпатындагы сөзәк тау итәген каплаган урман эчендә яңарак кына эшли башлаган корал заводын сакларга баскач, шул төндүк Уразаев белән Бикмулла «хәзрәт» командасында тауларга качты. Бу вакыйга бигрәк тә җайлы чыкты: шул беренче төндүк партизаннар һөҗүм итте. Аларның көче шактый һәм хәрәкәтләре кыю иде. Немецлар шашынып ут алып барганда, татар егетләре, күккә ата-ата, алга, як-якка караңгыга үрмәләделәр. (Уразаевның командасы шулай иде.) Һәм немецлардан аерылу белән үк атудан туктап, полякларга йөгерделәр... Оберкоманде Вермахтны бөтенләй аптырауга төшерде: татар легионы кача алмастай нинди урын табарга?.. Күп кенә баш ватканнан соң тагын яңа боерык язылды: «Идел-Урал» легионын Көньяк Франциянең Лепьюи шәһәрчегенә күчерергә. Француз партизаннарына каршы файдаланырга».

Шулай итеп, легионның калдык-постыгын эшелоннарга төяп, дөньяның икенче читенә җибәрделәр. Менә моннан качып карасыннар инде!..

Бу куанычлы хәлләрне тик Муса Җәлил һәм аның дуслары гына белми иде. Ә Мусаның иң хафаланган нәрсәсе дә шушы легиондагы кешеләрнең язмышы иде бит: дошман кулында корал булып һәлак булмасалар иде, туган илгә атмасалар гына ярар иде!..

Ат караучы аксак Арыслан, башкалар белән үзе әле һаман кача алмаса да, легиондагы шушы хәлләрне күреп, ишетеп, чиксез куанычта йөрде.

— Кайда син, бәләкәчем! — дип офтана иде ул.— Нинди генә юллар белән, нинди генә җилләр белән шушы әйбәт хәбәрләрне ишеттерергә сиңа?.. Язмышың бик авырдыр инде синең... Әмма мондагылар өчен син кайгырма, дустым! Сез чәчкән энҗеләр, кара туфракка сибелгән саф бодай шикелле, татар, башкорт, мари һәм чуваш егетләренең һәйбәт күңелләрендә тирән тамыр җибәрделәр. Аларга канат үстерделәр, алар лачын булып очтылар.

## ИКЕНЧЕ БАШЛАМ

### I

Тегель төрмәсенә китерелгәч, ун көннән соң гына Кормашны прогулкага чыгардылар. Ул инде эч пошудан, иптәшләрен юксынудан тәмам йөдәп беткән иде, хәтта иyләшелгән Варшава төрмәсен сагынып алгандай булды. Анда бит, ни дисәң дә, легион кешеләре белән очрашып була иде... Ләкин монда ул үз иптәшләреннән берәүне дә очрата алмады. Кыска минутлар узып та киттеләр. Әйләнеп кереп, үзенең өченче катына күтәрелгәч, төрмәнең шомлы тынлыгы тагын басып алды аны. Әмма бу шомлы тынлык озакка сузылмады. Кормашны онытмаганнар икән әле: аны янәдән допроска йөртә башладылар. Монда инде эшне яңа кеше алып бара. Холкының явызлыгы Хайснлыкыннан берхәтле кимрәк төсле, ләкин сораулары һәм мәкере шул ук искечә: «Едлино төркеменең башлыгы сез булгансыз, моны иптәшләрегез әллә кайчан әйттеләр инде. Оешмагызда кемнәр, ничә кеше иде? Монысын иптәшләрегез ачык белмиләр, бу хакта Курмашоф яхшы белә, диделәр. Ачыгын сөйләгез, җиңелрәк булыр...» һ. б., һ. б. Болар һәммәсе дә бик билгеле инде.

Кормаш аларга каршы әллә кайчан өйрәнеп беткән стандарт җавапларын кайтара. Шуннан соң кыйный башлыйлар. Анысы да искечә, бер генә яңа алым да юк. Мөмкин хәтле әшәкерәк ерткычлык күрсәтү, аннары су сибеп яки дару иснәтеп аңга китерү һ. б. лар.

Икенче сорауда Берлин оешмасын, Мусаны әйтергә кушалар, аның үз гаебен таныганлыгын укып күрсәтәләр. Гаҗәп бу немецлар, үзләре

акыллы гына халык та бит югыйсә, ә допрос алганда әллә нинди ахмаклыклар ясыйлар. Әллә инде чиновниклары шулай башсыз, әллә инде совет кешесен аңгыра дип уйлыйлар.

Өченче сорауда баллы прәннекләр, чуар тәтиләр, хәтта матур кызлар вәгъдә иткән булып, ансат кына тел яздырырга маташалар. Монысы да инде татар егетенең сафлыгын, горурлыгын белмәүдән килә. Кем генә булмасын аның юлдашы — русмы, чувашмы, башкортмы, маримы — мең алтынга да алыштырмый ул аларны!..

Керпегә дошман очраса, түгәрәк туптай йомарланып ята, ташбака үзенең таш сараена бикләнә. Гайнан да үзенең рух көчен, эчке ныклыгын күзгә күренмәс корыч кабыклар белән каплады. Тән итен күпме генә таласа да, сөякләрен күпме генә имгәтсә дә, дошман аның ыңгырашуын, зар сүзен ишетә алмады. Камерага сөйрәп кертеп ташлаулары белән аның күз алдына Муса килә, кулын суза, «Тор, дустым!» дип әйтә кебек тоела иде. Һәм Гайнан күзләрен ачып елмаерга тырыша, кычкыртырлык булып сызлаган сөякләрен хәрәкәткә китереп, эскәмиягә утыра, сәләмәләре эченә яшергән кәгазь кисәге белән карандаш очы чыгара да шигырь яза башлый. Аның иреннәре кыймылдый, пышылдап кына чыккан сүзләр кәгазьгә төшә бара. Ә Муса һаман күңел түреннән китми. Яратыр иде микән бу шигырьне ул?..

Шундый көннәрдә Кормаш «Карчыга», «Төн», «Төрмә», «Сез бәхетлесез», «Соңгы сүз» исемле шигырьләр язды. «Карчыга» шигырендә ул йөрәгенең бөтен ачы нәфрәте белән сатлык җан Ямалтаевны фаш итте, аны хурлык баганасына терәде. Бу шигыре генә түгел, башкалары да көрәшкә, туган илне сөюгә, турылыкка, ныклыкка чакыра иде аның. Чын мәгънәсендәге шагыйрь йөрәкле егет иде ул. Тик шунысы кызганыч, аларның шушында, якты дөнья йөзе күрмичә, үлүләре мөмкин...

Кошлар, үз балаларын үстергәч, очырып җибәрәләр һәм шуңа куаналар. Шигырь дә бит, синең йөрәгеңнән чыккач, икенче бер йөрәкләргә барып керергә тиеш. Ләкин аның, кош баласыныкы шикелле, төрмә тәрәзәсеннән үзе очып чыгарлык канаты юк. Беренче укучы йөрәгенә барып кергәч кенә канат үсә аңа. Ничек итеп беренче талпынышны бирергә соң?.. Нәүбәттәге һавага чыгуда да иптәшләре күренмәде. Кечкенә генә итеп бөкләп бармак арасына кыстырылган шигырь Кормаш белән кире әйләнеп керде...

Бернечә көн узгач, союзниклар авиациясе Берлинны көпә-көндез бомбага тота башлады. Төрле яклардан бөркелгән кара төтеннәрне, күккә үрләгән көчле ялкыннарны төрмә тәрәзәсеннән дә күрерлек иде. Гайнан рәхәтләнеп карап торды. Шул чагында төрмә эче ниндидер тавышлар белән гүләгән күк тоелды. Рәтләбрәк тыңлагач, төрмәдәгеләрнең үзара сөйләшүләре беленде. Һәр милләт кешесе үз телендә нидер әйтә, кемгәдер кычкыра, ә тыючы барлыгы сизелми иде. Надзирательләр аска качкан, күрәсең. Гайнан да кычкырырга тотынды: «Солтанай!.. Габдулла!.. Рушат!» Әмма бер җавап та килмәде, татарча сөйләшү дә ишетелмәде.

Икенче көнне кемдер «Синий платочек» көенә сызгыра башлады. Гайнан тыңлап-тыңлап торды да көйнең икенче яртысын үзе сызгырып җибәрде. Әмма теге кеше сүз белән җавап кайтармады. Шуннан соң Кормаш үзе:

— Кем сызгыра болай шәп итеп? — дип сорады.

— Я! — дип кычкырды тегесе, тере тавыш белән русчалатып. Я — Александр Русанов, капитан госбезопасности, личный адъютант генерала Строкача, начальника штаба партизанского движения Советского Союза.

«Кара, нинди батыр сөйләшә!» — дип сокланды Гайнан. Тик нигә ул үзенең кем икәнлеген шулай ачып бирә икән?.. Әллә ничегрәк яңгырый. «Менә мин кем, белеп торыгыз!» дигән шикеллерәк...

Ул арада булмады, капитан Русанов «Широка страна моя родная»ны кычкырып җырлап җибәрде. Эх, җан рәхәте! Ә шулай да бусы артык. Хәзер үзен эт итеп кыйнап ташлаячаклар, бер дә кирәкмәгәнгә... Батырлыгы белән мактанамы соң, әллә күкрәгенә сыймас йөрәге ярсыймы?

— Курыкмыйсыңмыни, юкка кыйнатырсың бит үзеңне, — диде Гайнан, аның өчен борчылып.

— Инде куркыр эш калмаган. Хөкем — кесәдә. Үлем — муенда! — дигән җавап килде. Аннары, байтак тын торганнан соң, өстәде: «Әгәр күрәсең килсә, мине француз офицеры белән алып чыгалар. Үзең кем, танышырбыз...»

Артык сөйләшү мөмкин булмады. Гайнанның ишеген шалтыр-шолтыр ачып керә башладылар. Һәм ул дөбер-шатыр керүчеләр яман да яхшы ниятле адәм булып чыктылар: кемнең нәрсә укырга теләвен сорап йөриләр икән. Менә нинди цивилизация! Ышаныргамы моңа, юкмы? Шулай да төрле камералардан төрле тавышлар ишетелде, һәркем үз телендәге китапны сорый иде. Кормаш рус телендәге Пушкин томын сорады. Икенче көнне аңа Пушкин урынына ак эмигрант Шульгин китабын китерделәр һәм власовчылар чыгара торган русча бер газета ташлап киттеләр. Гайнан газетаның беренче битендә үк нииндидер офицерның баштанаяк совет хәрби формасында төшерелгән рәсемен күрде. Рәсем астына «Капитан Александр Русанов» дип язылган иде. Ул, үз күзләренә ышанмагандай, ашыгып укырга тотынды. Коточкыч! Капитан Русанов, совет разведчигы һәм генерал Строкачның шәхси адъюданты гына түгел, немец разведчигы буларак та танылган кеше! Ул совет командованиесенең аерым заданиесе белән бу якка чыккан булып, немец командованиесе өчен бик кыйммәтле мәгълүматлар алып килгән! Ул хәзер бөтенләй немецлар кулына тапшырылып, Вермахт разведкасында эшләячәк!?

Исләрең-акылларың китәрлек! Гайнанның укый торган газетасы кулыннан төшеп китте, ишекле-түрле таптана башлады. Менә сиңа горур тавышлы Русанов, менә сиңа үлемгә хөкем ителгән кеше!.. Алай разведчик булгач, нигә аны монда, аерым камерада утырталар? Нигә булсын, провокация өчен! Аның шулай кычкырып җырлаган һәм курыкмый сөйләшкән булуы да, бәлки, сезнең эше беркатлы тинтәкләрне фаш итү өчендер?.. Ах, егетләр, дөньяда шушындый җаһиллек тә, мөкатдәс саналган бөтен тойгыларны аяк астына таптап мыскыллый торган шушындый көферлек тә булуы мөмкинме?.. Гайнанның хәзер үк тәрәзәгә килеп бөтен көче белән кычкырасы килде: ышанмагыз сүзләренә! Русанов — предатель!

Ләкин аның ярсу хисләрен акылы тыеп калды. Ниләр генә булмавы мөмкин бу каһәрле илдә! Җитмәсә, власовчылар газетасында басылган бит әле. Бәлки, нык йөрәкле совет офицерын урталай сындыру өчен шундый кабахәтлек уйлап чыгарганнардыр... «Менә, газетада фаш ителдең, янәсе. Хәзер сиңа совет ягында беркем ышанмаячак. Анда сине үлем көтә. Шулай бу.гач, юлың бер генә: бирeләсең дә безгә хезмәт итәсең...» Бу фикер Кормашны бераз суыта төште, ашыкмаска, сынарга булды. Икенче көнгә бомбага тоту вакытында әз генә сөйләшергә мөмкинлек килеп чыкты. Ул аңа болай дип кычкырды: «Русанов, газетада синең хәрби киемнән төшкән рәсемеңне күрдем...» Секундның нииндидер бер өлеше узуга, Александрның борчулы тавышы килде: «Син шуңа ышанасыңмы? Провокация бит ул!..»

Гайнан икеләнебрәк калды: ышанамы ул моңа, юкмы?.. Һәм үзенә-үзе ачык кына җавап бирә алмады.

— Белмим... — дип кычкырды, басынкырак тавыш белән.

Шул сүздән соң Русанов тынып калды. Көн буе аның тарафыннан бер сүз дә ишетелмәде. Нигә эндәшмәде ул? Кешеләрнең шулай икеләнүенә борчылыпмы, әллә бер сүз белән үзенә ышандыра алмавына газапланыпмы? Әллә, чынлап та, кешеләрнең «ул хыянәтче» дип уйлаула-

ры мөмкин дигән фикер аны бөтенләй изеп ташладымы? Гайнан үзе дә күп уйлады: «Белмим» дип әйтү «Сиңа ышанып бетмим, тегендә язылганнарга ышанарак төшәм» дигән шикелле яңгырый бит. Кормашның үз хәле дә шундыйрак түгелме соң? Әйтик, иптәшләре бар да һәлак булып, ниндидер очраклы бер могҗиза белән Гайнан үзе генә исән калса, ул үзенең вөҗданы саф, намусы пакь икәнне ничек исбат итәр иде? Бер шаһитың юк, бары тик керсез намусың да яралы йөрәгең генә. Ә Русановның кеме бар? Ул бит аерым задание белән бу якка чыккач кулга төшкән. «Белмим...» диючегә шартлатып исбат итәрлек бер шаһиты да юк ич ул мескеннең!..

Иртәгесен прогулкага чыккач, Гайнан капитан Русановны танып алды. Ул бәләкәйрәк буйлы француз офицеры белән бергә йөри иде. Кормаш мөмкин хәтле алар тирәсеннәнрәк узгаларга тырышты. Спортчыларда гына була торган җыйнак, тыгыз, озын гәүдәле, кавказча матур йөзле, кара чәчле, кара кашлы, тишеп карый торган яшькелт-караңгы күзле икән ул егет. Өс-башы хәрбиләрчә ыктымат, бөртекләп кырынган, шуңа күрәме, төс-бите төрмә тормышына бирешмәгән кешенекедәй җегәрле булып күренә иде. Кормаш үзен белгертер өчен берничә тапкыр кул болгады. Бераздан Русанов та күреп алып, шуны ук кабатлады, ерактан бер-беренә елмаешып та куйдылар. Шул ук вакытта Гайнанның үз иптәшләрен дә бик күрәсе килә иде, әмма бүгенге прогулкада ул аларны тагын очрата алмады. Йөзләгән кеше арасыннан күпме генә күзәтенеп йөрсә дә, һичбере туры килмәде. Алар хакында Кормаш Русановтан сорап карамакчы булды, бәлки ул белә торгандыр.

Аскы ишек төбенә өелгән тоткыннарны ыра-ера кергән Гайнан беренче баскычта ук Русановның терсәгенә килеп кагылды. Капитан ялт борылды да кулын сузды һәм: «Неужели ты этому веришь?» — дип, кичәге соравын кабатлады.

— Ышанмыйм! — диде Гайнан, һич икеләнүсез.

— Менә монысы өчен мин сине яратам! — дип елмайды Александр. Аның очлы күзләрендә йомшак яктылык күренде. — Анда язылганнарның барысы да ялган. Сволочьлар алар, үлемгә хөкем итеп тә, әллә нинди уткалар белән маташалар. Тыныч үләргә дә ирек бирмиләр! — Аның йомры урам ташыдай авыр йодрыгы үз алдына тибрәнеп куйды. — Син дә «политикус»мы?

Кормаш, «әйе» дигәнне аңлатып, эм какты.

— Монда җәлилчеләр утыра, теге канаттарак, — диде Русанов пышылдап. — Күргәнең бармы?

Гайнан аңа карап, көлеп куйды: кара, җәлилчеләрне беләләр икән!.. Әйтеп бирәсе килде, горурлык хисе уянды. Әмма икеләнде. Моның өчен тагын үзен әрләде: тагын ышанмау! Тагын шикләнү! Юк, Русанов хаин түгел, яшеренмә! — дип кычкырды аның эчке тавышы. Һәм Гайнан буйсынды:

— Мин үзем дә шул оядан!.. — диде ул.

— Вот как! Это здорово! — дип сокланды капитан. — Үзе дә мондамы ул?.. Күрәсе иде, бик хәтәр егет булса кирәк, күп сөйлиләр аның хакында...

— Әйе, — диде Гайнан, тагын да ягымлырак елмаеп. — Шәп егет, алтын кеше. Орлиная повадка, орлиный полет!.. Ләкин ул икенче төрмәдә. Минем дә бик күрәсем килә...

Өченче катка менеп тә життеләр, юллары аерылды, сүзләре киселде. Үз камерасына кергәч тә, Гайнанның тәэссораты тиз генә сүнмәде. Димәк, аларны да белүчеләр, танучылар һәм ихтирам белән телгә алучылар бар икән әле!

«Нет, весь я не умру — душа в заветной лире
Мой прах переживет и тленья убежит!..»

Бу олы шагыйрьнең олы өметенә сокланып, бәлакәй генә Гайнан да үзенең тыйнак өметен әйтеп бирә алмасмыни?..

Юк! Бөтенләй үк онтылмабыз әле,
Югалмабыз томан эчендә.
Кем дә булса бер жылы сүз әйтер,
Исмебезне саклап исендә...

## II

Мусаны, Лертерштрассе төрмәсенә китергәч, өченче каттагы камерага ябтылар. Ул керүгә камера буш булса да, кайбер вак-төяк нәрсәләргә карап, анда кемдер яшәвен аңларга мөмкин иде. Кичен надзиратель ул кешенең үзен китереп кертте. Алар, бер-беренә ияләшә алмыйча, озак кына суык тынлык эчендә утырдылар. «Бу миннән сер урлар өчен алдан ук кертеп куелган шпик түгел микән?..» дип уйлады Муса. Каршысында утыручы да шулай уйлагандыр, бәлки... Әмма дошманың белән дә сөйләшергә туры килә ич дөнья булгач. Ә Муса, гомумән, сүзсез тора алмаучан кеше бит әле ул. Ниһаять, кыскача гына танышып алдылар: милләте белән Силезия полягы булган немец солдаты икән, икенче бер төрмәдә повар итеп эшләтәләр икән. Муса да үзен ике сүз белән генә әйтеп бирде.

Озак сөйләшмәделәр, поляк көн буе эссе кухняда эшләп, талчыгып кайтканга, урынына сузылды да, солдатча гырлый да башлады. Иртәгесен алтыдан ук тагын эшенә алып киттеләр. Муса көн буе ялгызлыкта үткәрде, алдагы көннәрне дә шулай дәвам итте. Допроска чакырып жан кыйнаулар, бәлакәй һәм олы «концерт»лар белән тән үтерү газаплары тукталып киткәч, Муса бөтенләй «эшсез» калгандай булды. Аңа соңгы очрашуда үлем вәгъдә иттеләр...

Кыз-тәкәгә охшаган Геденктафель үзенең ике ай буена алып барган тикшерү нәтижәләре белән Мусаны таныштырды да кул куярга кушты. Ләкин «дөреслекне яратучы» музыкант әфәнденең язмаларында уйдырмалар шактый күп иде. Муса аларны берәм-берәм инкарь итә барды да:

— Кыскасы, монда язылганнарның туксан биш проценты фальсификация, — диде һәм кул куюдан баш тартты. Тикшерүче әфәнде бер генә секундка күзләренең агы белән карады, ләкин йомшак теллелек һәм мәдәнилек тонын бозмады.

— Яхшы, күгәрченкәем, — диде ул шундый ягымлы итеп, гүяки сөйгән кызы белән сөйләшә иде. — Яхшы. Сезнең һандкоффердан чыккан листовкалар үзләре генә дә тубыкларыгыздан асып куярга бик рәхәтләнеп житәчәк. Мәсәлән, виолончельне ал тасма белән колакларыннан асып куйган шикелле... Мин сезгә моны тантаналы рәвештә вәгъдә итәм!

Муса жавап кайтарып тормады, нигә сүз әрәм итәргә? Чөнки бу «вәгъдә»нең чын булачагын ул үзе дә яхшы аңлый. Мусаның эше билгеле. Шулай булгач, икеләнер урын юк: вәгъдә, әлбәттә, төгәл үтәлер...

Үлем. Әйтүе нинди ансат: бары ике ижекле сүз генә. Нәрсә соң ул үлем?.. Бу хакта ул фронтка китәр көннәрдә үк бер уйланган иде. Әмма ул чакта, солдат булып, сугыш кырында үлү генә күз алдында иде. Үлмәстәй батырлык күрсәтеп үләргә теләгән иде ул. Ә хәзер бөтенләй башка урында, башка төстәге үлем тора аның каршында...

Үлем. Бу сүз үк салкын, әйткәндә үк тәннәрне чымырдатып ала. Бу сүзнең артында иге-чиге билгесез еракларга сузылган мәңгелек бушлык. Дөм-караңгы чүл. Күгендә ае түгел, сукыр уттай гына йолдызы да күренми. Ул чүлдә хәтта елан-чаяннар сызгырганы да ишетелми, жилләр дә исми. Киттең. Беттең. Мәңге-мәңгегә эзсез, авазсыз йотылдың...

Үлем. Аңа вәгъдә ителгән бәхет — әнә шул. Төньяк суыкларыннан качып кыйбла тарафларына ашыккан кыр казлары кебек, туган жирләр-

гә тизрәк кайту өчен ашкынып башлаган юлның соңгы ноктасы шунда килеп терәлә...

Үлем. Куркыныч һәм куркыныч та түгел кебек ул. Аның хакында бөек философ: материянең бер рәвештән икенче рәвешкә күчүе дигән. Нинди тетрәнүсез, нинди айнык акыл белән гади генә итеп, гади генә нәрсә турында шикелле әйтелгән сүзләр! Ә шулай да үләсе, икенче рәвешкә күчәсе килми. Кешенең шушы формасы матур, шушы рәвеше әйбәт!..

Шунда ук Муса күз алдына икенче сүз килеп баса: яшәү!

Бу да ике генә иҗекле һәм тагын да ансатрак әйтелә. Әмма ул шундый кайнар, шундый якты, әйтерсең, аның һәрбер хәрефен яшен утлары белән язганнар!

Яшәү! Бу сүз артында дөньяның күреп туйгысыз бөтен матур чәчәкләре хуш ис аңкыткан очсыз далалар җәелеп китә. Зифа урманнар, көмеш күлләр, ефәк елгалар, зөбәрҗәт диңгезләр ята. Карлар һәм яңгырлар ява, салават күпере чыга. Җирдәге барлык җан ияләре үз җырлары белән яшәүне мактыйлар. Җилләр курай тавышы булып, давыл һәм өермәләр Бетховен музыкасы булып, океан һәм диңгез дулкыннары яшәү сулышы булып яңгырыйлар.

Яшәү, яшәү! Яшәүдән ничек аерылырга кирәк? Әмма туры киләчәк. Чөнки аны тоткын итүчеләр аның яшәвен теләмиләр. Яшәвен теләмиләр... теләмиләр... Яшәү... Аһ, яшәү! Аерылырмы? Юк, юк! Аерылу мөмкин түгел! Яшәргә, яшәргә! Ничек кенә булса да яшәргә!!

Муса, елан чаккан шикелле, кинәт урыныннан сикереп торды. — Ничек?.. — дип, үз-үзенә карчыгадай очып кунды ул. — Ничек кенә булса да яшәргә, дисеңме? Иманыңны сатып булса дамы?.. Кул-аяксыз, канатсыз хәшәрәт төсле, пычракта шуышып булса дамы?.. Башыңа кем сукса да, койрык болгап, мескен һәм ялагай күзләрең белән хуҗаңа карап, ул нинди сөяк ташласа — шуны ялап, ул кемне кушса — шуны талап, карусыз Алабайдай яшәргәме?..

Аңа кинәт суык булып китте. Тәне чиркәнде, арык арка сөякләре буйлап боздай кырмыскалар өскә таба үрмәләгән төсле булды, калтыранып куйды һәм маңгаена суык тир чыкты. Гүя яшерен бизгәк җәфалый иде аны. Озак кына бер хәрәкәтсез басып торды. Гаҗәп, бик гаҗәп. Яшәү шикелле гүзәл нәрсәнең дә хәтта бизгәк тоттырырлык ямьсез ягы да бар икән. Чыннан да, шушы хәтле кыен һәм озын юллар үтеп, калган гомереңне «ничек кенә булса да яшәргә» белән канәгатьләндерү, шуның белән килешү, шуңа риза булу мөмкинме? Күрәсең, ямьсез һәм аяныч итеп яшәгәнче, үлем артыграк икән...

Аның кинәт язасы килде. Бала чактан ук үзе яраткан җыр телендә дөнья белән, туган халкы белән, күз карасыдай газиз Әминәсе һәм баласы белән, якын дус-ишләре белән сөйләшәсе килде. Аның үле гәүдәсе монда калса да, яшәүнең чын матурлыгы һәм үлмәс дәвамы җырларына күчеп, туган җиргә кайтып җитәргә тиеш...

Язу өчен хәзер аңа бөтен «мөмкинлек» бар: элеге «концерт»лардан соң кан сауган тәннәрен, шешеп чыккан күз төпләрен, сынган яки какшаган тешләрен төзәттереп йөрисе, яңа допросларга хәзерләнәсе юк. Көн буе тынычлык һәм бер үзе!.. Хәтта кәгазь дә табарга була: һәр көнне «Филькишер...» газетасын кертәләр, аның иң кызыклы материалы — кырыйларында киң булып калган буш урын. Шуны иплә кенә ертып алырга да, рәхәтләнеп шигырь язарга, бәләкәй кесә дәфтәре ясарга мөмкин.

«Хат язарга кирәк иде» дип үтенгәч, поляк егете аңа бәләкәй генә шәмәхә карандаш кисәге бирде. Шуннан соң Муса җиң сызганып эшкә керешә. Уйлар, хисләр, кичерешләр, дәртләр һәм хыяллар белән тулы шигърият дөньясына чумгач, үзен кысып торган тар стеналар, коридорда йөрүче надзирательләр барлыгын да онытты кебек ул. Якты өмет һәм ышанычлар, кошлар һәм чәчәкләр, сөю һәм вәгъдәләр, теләк һәм

ашкынулар, сагыну һәм кавышулар, көрәш һәм антлар белән бизәлгән үз дөньясында яши башлады. Аның каршында үзе генә белгән нәфис гөлле болыннар, мәрмәрдәй ак ташлы тау итәкләре, үзе генә йөргән борма сукмаклар, экияттәге төсле зифа наратлы карурманнар җәелеп ята, үзенә генә таныш яшерен исемнәр күз алдына килеп баса. Ул алар белән пышылдап кына серләшә. Алар үзләренең йөрәк серләрен шагыйрь дусларына тавыш-тынсыз гына тапшырып китәләр. Тау итәгендәге чишмә белән сандугач, сукмак буендагы ромашка, юл чатындагы ялгыз имән һәм тагын бик күпләр үзләренең иң кадерле хикәяләрен аңа сөйлиләр. Шагыйрь үз туган җире киңлекләрен гизә: өч лачын үстергән ананың төпчек улын табып биреп, күз яшьләрен киптерә; гел карадан киенеп, кайгылы йөргән гүзәл кызның батырын кайтарып, хәсрәтләрен алып китә. Авыр сугышлар алып баручы солдатлар сафына басып, аларга көч һәм куәт бирә. Җиңүдән соң, кичәге солдат куллары белән, илнең яңадан чәчәк атачагын күрә. Әйтерсең, ул Берлин төрмәсендә утырмый, ә бәлки биш-ун елга алга китеп, илдәге күтәрелеш пафослары эчендә яши...

Ул да түгел, Муса үзенең еракта калган яшьлек таңнарына сәяхәт итеп килә. Менә кышкы буранлы төн. Ай да, йолдызлар да болыт өермәсе белән капланган. Орск далаларын кичкәндә юл адашып, туңыпкүшегеп, алар казакъ авылының иң кырыйдагы бер кечкенә өенә килеп керәләр. Җиделе лампа, җылы мич. Тизрәк аңа сыеналар. Менә шунда, болыт арасыннан көлгән айдай балкып, өй хуҗасының кызы килеп чыга... Саламга төшкән очкын шикелле, гөлт итеп кабынырга торган Мусаның кайнар күзләре гүзәл казакъ кызының күзләреннән аерылмый.

«Ләйләсеме әллә бу Мәҗнүннең,
Зөһрәсеме әллә Таһирның?» —

дип, таң кала ул...

Менә шул ераклардагы казакъ даласы үзенең чиге күренмәс киңлекләре белән, бураннары һәм айлы төннәре белән, Ләйлә кебек төн гүзәле белән Мусаның таш камерасына килеп керә. Чикләр югала һәм тоткын шагыйрь, рәхәт сулыш алып, беренче яшьлегенең беренче кадерле хисләрен яңадан кабызып, үз туган ягы кочагында онытылып яши башлый. Бу минутта аңардан да бәхетле кем бар икән!..

Ул ашыга, ул курка: бу изге минутлар кинәт кенә югалып китмәгәе!.. Һәм тар гына, бәләкәй генә кәгазь битләренә бармак буедай гына карандаш очыннан энҗе валчыклары төсле вак кына хәрефләр сибелә бара, сибелә бара...

Ә шулай да, иҗат газабы татлы газап булса да, барыбер талчыктыра, алҗыта. Алҗытса да башын күтәрми, һәм күтәрелеп карап, шушы сихри матурлык дөньясыннан аерыласы килми. Ул һаман яза... яза. Һәм яза-яза йокыга тала. Бәхетле килеш, иркендә килеш йокыга китә. Бер генә төн булса да үзенең кайда икәнен онытып тору нинди рәхәт!..

Шулай иҗат ялкыны белән дөрләп яши торгач, аның бу төрмәдәге бер ае узып та китте. Бу вакыт эчендә бик күп эш эшләде ул. Аның әле сугышка кадәр йөргән иҗат йортларында да бу хәтле күп язганы юк иде. Шулар өстенә, әле Волхов фронтында чакта ук язылып, әсирлеккә төшкәч югалган шигырьләрен дә исенә төшерде һәм нәни кәгазьләргә терки барды. Әсирлектә һәм Берлинда чакта язган шигырьләренең кайберләре Албайнплацтагы бүлмәсендә тентү вакытында алынып, соңыннан юкка чыгарылган, кайберләре яшергән урыннарда калган иде, ул аларны да хәтерләп, һәрберенә яңадан канат бирде. Шулай итеп, ай тулганда, шактый гына күләмле бер куен дәфтәре барлыкка килде. Һәм шуның белән яңа бер кайгы туды: кая куярга?.. Дәфтәрне камерада саклау куркыныч иде, чөнки көтмәгәндә дошманның килеп керүе һәм кинәт тентү ясавы мөмкин. Моның иң үкенечлесе синең изге хисләрең һәм иң

кадерле йөрәк серләрен дошманга мәгълүм булачагында иде. Аннары шигырьләр үзләре дә, читлек сөймәгән кош кебек, кәгазьгә язылу белән тизрәк моннан очып китәргә телиләр. Тизрәк коткаруны сорыйлар. Каян табарга соң шундый мөмкинлекне? Ничек очырырга күңел кошларын?..

Иптәшләре белән дә очраша алмый, Алишны да тәрәзәдән генә бер күреп калган иде, әмма ничә прогулкага чыгып, туры китерә алмады. Ул күршедә генә булса кирәк, Муса аңа шакып та караган иде, һич җавап булмады, яңадан прогулкада йөргәннәре дә күренмәде. Муса моның серен байтактан соң гына төшенде: аларны «шахмат» тәртибендә чыгаралар икән. Бер клетка чыга, икенчесе кала. Шулай итеп, ул ике як күршесе белән дә очраша алмый. Немец — хәйләкәр...

Ә дуслары ни хәлдә икән соң аның? Бик боекмыйлар микән, авырмыйлар микән? Алар белән очрашса, дәфтәрен чыгару турында да бер җай табылыр иде, бәлки...

Муса шушы мәсьәлә белән баш ватканда, камерага, өченче итеп, яңа кеше китереп тыктылар. Нинди кош икән бу? Хәзер инде бигрәк тә сак булырга һәм дәфтәрне тизрәк ычкындырырга кирәк. Моңарчы ул көн буе берүзе иде: яза да, теге поляк егете кайтканчы, үзе белгән урынга гына кыстырып та куя. Ә хәзер аның һәрбер селкенүенә кадәр, ике күз, магнитофон шикелле, хәтер тасмасына язып барачак. Шулдыр әле, Мемориаль такта әфәнде уйлап тапкандыр: тукта, ниләр кыланып ята икән майн Либстер дигәндер. Күз җибәрим янына, тыныч кына ятмасын, дип хафалангандыр...

Яңа кертелгән кешегә күзләренең кырые белән генә карап алды ул. Ниндидер чандыр гәүдәле, уртача озын буйлы, кара чәч-сакал баскан нәрсә икән. Үзе яшь күренә, әле утыз тутырырга да байтак бардыр. Бу инде Көньяк Германиядән булса кирәк, шул якларда бит кара немецләр. Арий каны булса да, җитен чәчле, зәңгәр күзле түгелләр. Русча белә микән, белмәгән булып кыланыр микән, дәшеп карарга кирәк... Хәер, үзе эндәшсен. Сер эзләүче чыпчык булса, озак түзеп тора алмас, сайрарга ашыгыр. Андыйларның тизрәк максатка ирешәселәре килә ич.

Әмма биш-алты сәгать узып та китте, ә «чыпчык» сайрарга ашыкмады. Ул, ничектер дусларча елмайган шикелле итеп, Мусага карап-карап кына ала иде. Аннары әрле-бирле йөрергә тотынды, әкрен генә итеп нииндидер матур көйгә сызгырып та алгалады. Ниһаять, кичке ут алганнан соң, Муса үзе түзмәде.

— Исем-фамилиягез ничек? — дип сорады русчалатып.

Кунак, берни дә төшенмәде булса кирәк, җавап урынына тагын елмаеп кына куйды. Әһә, русча белмәмешкә салыша, ярый алайса, немецча сорап карыйк:

— Ви һайссен Зи?

— Андре Тиммерманс, — диде егет, французчарак акцент белән сузып. — Абер ви ист иһр наме?..[1]

— Гумеров, — дип җавап бирде Муса.

— О, русиш? — дип сорады егет сокланган тавыш белән. — Оф, оф! Русиш!

— Әйе, рус кешесе диярга була.

Муса шулай да аңа артык игътибар бирмәскә булды, үз почмагына беректе дә хәсрәт чаткысыдай гына булып янган ут яктысында бик тырышып укыган кыяфәт белән «Филькишер...» газетасына борынын төртте. Материалларның иң кызыкларын сайлап укыгандай, озак туктала-туктала, газета битләрен әйләндерде, шул арада сиздермичә генә егетне дә күзәткәләп алды, ә егет нииндидер үз эше белән мәшгуль иде. Шуннан соң Муса үзенең иртән шигырь язудан калган бер тасма кәгазен кисәсеннән алды да кат-кат бөкләгән газета өстенә салып тезенә куйган ки-

---

[1] Ә үзегезнең фамилиягез ничек була?

леш яза башлады. Элекке шигырьләрен хәтерләп, кәгазьгә төшерергә кирәк иде аңа. Ул шулай байтак кына эшләп утырды.

— Нәрсә язасыз? — дип, аксак немецчасы белән сорады егет, ул уйланып утырганда гына.

Муса аңа күтәрелеп карады: кунак үз урынында иде. Димәкки, теле белән генә кызыксына, күзләре — күзәтчелектә түгел...

— Сөйгән кызларга хат язам, — диде Муса бик гади генә итеп.

Егет авызын зур ачып, кычкырып көлеп җибәрде. Аның бәләкәй йөзен бөтенләй авыз каплагандай булды.

— Сөйгән кызларга хат? Шәп! Нәкъ кызлар белән гыйшык хатлары алыша торган җир инде бу! — Ул әле һаман көлә иде. — Шаян кеше икәнсез. Күптән көлгәнем юк иде, рәхмәт сезгә!

Алар әлеге ватык-җимерек немец телендә тагын берхәтле сөйләшеп алдылар. Андре Бельгия кешесе икән, кырык икенче елны ук кулга алынган. Срогы байтак бар икән әле. Муса да үзенең кайчан алынуын һәм татар икәнлеген әйтте. Әмма икесе дә нинди «гаеп» белән утыруларын сөйләмәделәр. Монысы инде һәркемнең үз сере иде. Камерада ут сүнде. Күрәсең, йокларга вакыт. Ут сүнү белән аларның сүзләре дә киселде. Дөрес, авыз караңгыда да күрә, диләр, ләкин тел җитмәве, сүзнең мәгънәсен караңгыда кул һәм бармаклар белән аңлатырга мөмкин булмавы, аларны сөйләшкән хәтлесе белән чикләнергә мәҗбүр итте. Поляк егете бүген ни өчендер бик соң кайтты. Болар йоклап киткәндә генә надзиратель камерага китереп кертте аны.

Иртәгесен Муса, нишләргә белми аптырап, ишекле-түрле йөренде. Бу яңа кунак иҗат рәхәтеннән мәхрүм итте бит әле аны. Поляк солдаты бүген дә иртүк үз эшенә озатылды, Муса менә хәзер ялгыз калып шигырь дөньясына чумган булыр иде, ләкин юк шул, андый бәхетле көннәр бетте, күрәсең. Әнә бит, үзенең шытырдап торган каты кара сакалын ашыкмый гына кырып утыра. Көн узсын, ди торгандыр инде. Кем икән соң бу? Карак яки кеше суючы бандитка да охшамаган, болай ипле генә сыман күренә... Әллә Мусаның үзедәй үк бер сәяси тоткынмы?..

Әлеге «Филькишер» газетасын бүген ике данә керттеләр. Муса байтак кына вакыт укыган булып утырды да газетаның буш калган киң кырыйларына филдер, мәчедер, арысландыр, туп арбасыдыр, янә тагын бик күп шундый рәсемнәр ясап чыкты. Һәрберенең астына русча исемнәрен латин хәрефләре белән язды. Аннары Андреның кырынып, сөртенеп беткәнен көтте дә:

— Әйдә, «Вас ист дас» шпилен мит [1], — диде ватып-җимереп.

Егет гаҗәпләнебрәк көлеп торды.

— Менә болай, — дип аңлатырга тырышты Муса, бөтен сүз запасын һәм бармакларын эшкә җигеп. Мин яздым русча, син яз үзеңчә. «Вас ист дас?..»

— Я, я, уйныйбыз! — дип көлемсерәде егет, байтактан соң, ниһаять, төшенеп алгач. — Була ул!

Бу уен тора-бара аларга бик кызык сыман булып китте. Тиммерманс үзе дә рәсем ясый башлады һәм «нәрсә бу?» дип, Мусаны тыкырдатырга тотынды. Шулай итеп алар «тел өйрәнү уены» белән көн уздырдылар. Кичен эштән кайткач, бу уенга поляк егете дә кушылды. Муса белән алар полякча иркенрәк сөйләшкәнгә күрә, ул кыен җөмләләрне, абстракт төшенчәләрне аңларга күп ярдәм итә башлады.

Бу уен икенче, өченче һәм дүртенче көннәрне дә дәвам итте. Муса белән Андре бер-беренә шактый ияләшү һәм якынлашуларын сизми дә калдылар. Яшь егет Мусаның сорауларына саран-саран гына булса да җавап та биргәләде. Бельгиянең Тирлемон дигән бәләкәй генә каласыннан икән ул... «Каршылык хәрәкәте» оештырганнар. Шуннан эләккән...

---

[1] «Нәрсә бу?» лы уйныйбыз.

Муса, аның озын нечкә буена җәһәт кенә үрелеп, аркасыннан какты.

— Антифашист? Антифашист? — дип пышылдады ул. — Мин дә бит... Мин дә антифашист. О, без бер фронт кешеләре икәнбез! Һәм ул, немецча, русча, французча сүзләр кыстырып, үзе турында кыска гына сөйләп бирде. Алар, яңа гына очрашкан танышларча кул кысышып, дуслашып киттеләр. Билгесез кеше белән тору кысанлыгы беткәннән соң, Муса тагын үз иҗаты белән мәшгуль булды. Ул инде үзенең шагыйрь икәнен дә яшерми, ә Тиммерманс, прогулкага чыккан чакларда, аңа төрмә киоскасында сатыла торган хат кәгазе алып керә иде. Дөрес, аны бер биттән ары бирмиләр, шулай да көн саен алып кергәч, ярап куя ул. Шуның өстенә, Муса үзе дә ала ич әле. Шул кәгазьләр җыела төшкәч, Муса аларны бер төпкә тегеп, тагын бер бәләкәй дәфтәр ясады. Анда ул «яңалиф» хәрефләре белән яңа шигырьләр язды һәм искеләреннән дә бер егермеләбен күчерде. Кәгазь табылу белән шушы ук дәфтәрләрен яңадан күчереп чыгарга булды. Чөнки ул, шигырьләрен берничә кул аша чыгару дөресрәк булыр, берсе югалса, берсе тапшырылыр, дигән фикергә килгән иде. Тик аларны биреп чыгарыр кеше генә һаман юк иде әле...

Иптәшләре белән шулай якынаешып алгач, Мусаның күңеле шактый ачылып китте хәзер. Авыр уйлар газабына бирелергә вакыты юк иде, хәтта элекке уенчак гадәте, җор сүзлелеге яңадан кайтты. Шаян, шук кәефле шигырьләр язды. Шагыйрьнең язмышын белмәгән кешеләр, аларны бер дә фашист төрмәсендә язылган дип уйламас иде. Ә инде Мусаның нинди хәлдә булганын белгән кешеләр, ул шигырьләрдәге җылы һәм шук юморга, күңел көрлегенә гаҗәпләнеп: «Боларны язганда шагыйрь үлемнең күкрәгенә басып торган, аны мыскыл иткән!» — диячәкләр иде.

Әйе, Муса үлемнән курку хисен җиңгән иде инде. Иртәгә дә, бер айдан соң да яки өч ай узгач та, көн артыннан көн киләсен белгән төсле, үлемнең дә бер килеп аның алдына басачагын яхшы белә иде. Тик кай көнне килүе генә билгесез... Бу хакта ул Андре дустына да һичбер өзгәләнүсез, ачыну һәм ярсынусыз, гади һәм бөек тынычлык белән сөйләп бирде.

— Ихтимал, алай ук булмас әле, — диде Андре, бер дә кирәк булмаса да юатырга теләп. — Бәлки, суд йомшарту юлын да табар, хафаланмыйк әле...

— Юк, — дип елмайды Муса, — мин бер дә хафаланмыйм, дускай. Үләчәгем көн кебек ачык. Чөнки фашистның явыз акылы кичерүне белми. Хәер, без аның белән «качышлы» уйнамадык ич: тоттың—җибәрдең түгел. Без аның белән үлем уены уйнадык. Без аның әсирләрдән укмаштырган легионын таркаттык. Шулай булгач, нигә мине кичерсен ул? Юк, бу мәсьәлә ачык. Вакыты җиткәч, үзе килер әле, үлемне әйтәм... Ә мин ашыкмыйм. Мине мәшгуль иткән нәрсә — бу түгел хәзер. Минә иптәшләремне күптән күргәнем юк, бер авыз сүз әйтә алмыйм. Ни хәлдә икән алар? Кәефләре, саулыклары бик начар түгел микән? Рух көчләре какшамады микән?..

Андре сокланган күзләрен әле һаман аннан ала алмый иде.

— Ә кайда соң алар? — дип сорады ул.

— Аңлавымча, икесе күршемдә генә, — диде Муса. Берсе уң ягымда, берсе сул ягымда булса кирәк. Әмма шуларны да күрә алмыйм. Монда тәртип әллә нинди: камера аша туры китереп чыгаралар һавага. «Шахмат» тәртибе, янәсе. Александерплацта этажы белән иде. Калганнары кайсы камерада икәнне дә ачык белә алганым юк. Ә бер төркеме — Тегельдә булса кирәк...

— Минем дә иптәшләрем бар күршедә... — Андре нәрсәдер уйланып калды, һәм кинәт йөзе яктырып китте. — Идея туды миндә! Беләсеңме, әйдә, стенаны тишеп сөйләшәбез!

Муса, бармакларын уйнатып, көлеп куйды:

— Шушылар беләнме?

— Һемм, — дип сузды Тиммерманс, инде сүрелә төшеп. — Болар белән ерак кереп булмас шул...

III

Элекке яшь, ажгыр надзирательләр, бәйдәге эт шикелле усал ишек сакчылары, капка һәм койма каравыллары соңгы атналарда каядыр юкка чыгып, алар урынына каешын кыйшык бәйләгән, мылтыгын рәтләп асарга да иренгән карт солдатлар пәйда булды. Һавага чыкканда моны мыек астыннан гына күзәткәләгән Муса: «Фюрернең кесә төбе шулай ук такыраеп бара микәнни соң?..» дип уйлый иде. Бу карт солдатларның пәйда булуы тоткыннар өчен әз-мәз җиңеллек тә китерде: атлаган саен бәйләнмиләр, вагын-төяген күрмәмешкәрәк салыналар иде. Бу хәл тоткыннарга җан кертеп җибәрде. Һавага чыккач елыша-елыша гына үз танышларына якынаеп, бер-ике сүз булса да әйтергә өлгерәләр иде. Муса да хәзер, йөри торган юлыннан чыккалап, үз иптәшләрен иркенләбрәк күзәтә ала башлады. Ниһаять, көннәрнең берендә, керер алдыннан гына Гариф Шабаевны күреп алды ул. Йөрүчеләргә шыклана-шыклана аның янына килде, әкрен тавыш белән генә исән-саулык, кайсы камера, кайсы кат, башкаларны күрәме — шуларны сорашты.

— Өченче көн Булатны күргән идем, сәлам әйтергә кушты, — диде Шабай. — Ул Алишны күргән, синең белән очраша алмавына бик пошына икән. Әйтәсе сүзе дә булса кирәк...

> «Яшь кенә көйгә гомер киселә.
> Тетрәп китәмен, төшсә исемә.
> Алмазым кала, Айвазым кала,
> Сөекле дустым — җан назым кала...» —

дигән шигырь укыган...

Бу ашык-пошык сөйләшкән арада алар тирәсендә кешеләр беренсәрән генә калган, надзирательләр дә аларны күрәләр иде инде. Муса тиз генә үзенең әзерләп чыккан ике шигырен төртте. Бармак битедәй генә бөтиләр иде алар — «Юату» һәм «Ана шатлыгы» шигырьләре.

— Яшер. Укыгыз. Башкаларга да озат... Нык булыгыз, дусларым, кайгырмагыз. Батыр ауганда җир селкенер, дигәннәр. Мин аларны ничек тә күрергә тырышырмын... Симайны күрмәдеңме?..

Ул арада надзиратель кычкырып та җибәрде:

— Нихт шпрехен! Ауф Целлен!..[1]

Алар икесе ике кырыйдагы ишектән кереп югалдылар. Камерага кергәч, аңа Тиммерманс Алиштан сәлам тапшырды. Муса гаҗәпләнеп калды: ничек, үзен күргәнме? Юк, күрмәгән. Икенче каттагы бер иптәше белән очрашкан, ул Алиш белән бергә утыручы Мейзонны күргән икән, шул әйткән: Алишев дигән күршем бик борчыла, кәефе әйбәт түгел, күршедәге иптәшен бик күрәсе килә, дигән.

Муса уйга калды. Менә бит ул: стена аркылы гына утыр, ә күреп сөйләшә алма. Каһәр суккан төрмә һәм аның законнары! Нинди йомычкага әйләндерәләр кешене! Нишләргә соң? Чирләгән булып санпунктка барасы мәллә? Хат аша сөйләшеп, шул ук вакытка Алиш та, Булат та килсә?..

Бу фикер барып чыгар төсле тоелды Мусага. Хәзер үк ике хат кисәге язарга кирәк, берсен үзе алып чыгар, берсен — Андре. Ничек тә Алиш белән Фоатка кешеләр аша житкереп булыр...

— Ә миндә тагын бер яңа хәбәр бар, — диде Тиммерманс, аның каршына килеп. — Безгә, теләсәк, эш бирүләре мөмкин икән. Шушында, камера эчендә генә кыштырдап ятырга.

[1] Сөйләшмәскә! Камераларыгызга!

Бу әле үз уена чумган Мусаны бер ягы белән дә кызыктырмады. Хуш, шуннан? Аның нәрсәсе бар?

— Аның берничә «куяны» булырга мөмкин, — дип дәвам итте Андре, елмаеп. — Бердән, әз-мәз гәүдәне кыймылдатып алырга була. Икенчедән, без эш алсак, берәр төрле корал заты да бирергә тиешләр. Ә корал булса, Альп кыялары аша күрше камераларга юл салу да мөмкин булыр, бәлки?..

Муса рәхәтләнеп көлеп куйды.

— Тапкыр булырдай күренәсең, егет, — диде ул, Андрены яратып.— Әйдә, яшь апостол, иярт артыңнан, мөритең булыйм!..

Шуннан соң алар бу эшнең чарасына керештеләр. Андре, надзиратель аркылы төрмә администрациясе белән сөйләшеп, эш сорап алды. Аларга түгәрәкләп киселгән агач капкачлар китерделәр. Муса белән Андре камерада шул капкачларның уртасына ике бармак иллелеге ырмау ясарга тиешләр. Моның өчен кирәкле булган вак-төяк корал да бирделәр. Шулар арасында бәләкәйрәк бер җиңел стамеска да бар иде. Муса иң элек шунысын кулына тотып карады. Аннары Алиш камерасы белән ике арадагы стенаны буйдан-буйга өйрәнеп чыкты. Кай җиреннән генә чокый башлау уңайлы булыр? Стена буйдан-буйга ялангач. Аның чокылган җире надзиратель күзенә күренмәскә тиеш бит...

— Нишлибез, Андре, — диде ул, — маскировка юк ич...

Андре да озак каранып торды.

Шул стенаның ишек катындагы почмакта өч аяклы авыр параша утыра иде. Тиммерманс шуның янына килде, иелеп артын тикшерде.

— Карагыз әле, — диде ул, — моның бер аягы стенаны шактый гына каплап тора икән. Ничек булыр, әгәр шуның артыннан башласак?..

Килеп карагач, Муса да бу урынны әйбәт дип тапты. Дөрес, һавасы бик саф булмас булуын. Әмма нишлисең, мастерскойда андый гына газ исләре булмый калмый инде ул...

Һәм алар эшкә тотындылар. Парашаны әз генә читкәрәк чигереп, идәнгә газета җәелде: стенадан коелган ватыклар шуның өстенә төшәргә тиеш. Муса, сасы парашага башын терәп, идәнгә сузылып ятты һәм әлеге киң өтерге белән сак кына рәвештә стенаны кимерә башлады. Андре ишек төбенә басты. Ишекнең бәләкәй күзе тыш яктан ябулы булса да бик саклык кирәк. Якын-тирәдә аяк тавышы ишетелү белән үк эш туктарга тиеш. Ләкин көйсез урында эшләгән Муса бик тиз арыды, ул кузгалуга Тиммерманс ятты, ул озаграк чокчынырга теләсә дә, түземсез Муса ирек бирмәде, тагын үзе тотынды. Шулай итеп әкрен генә, сак кына хәрәкәтләр белән:

— Кытыр-кытыр... Тук-тук... — китереп, төрмә стенасын кимерә барды алар. Бәхеткә каршы, эшләре уң башланып китте: өтерге очы, берике чоку белән үк, ике кирпеч арасындагы җеккә туры килде. Андагы известьне казгычлау, кирпеч чүкүгә караганда, шактый җиңелрәк булды. Шулай да берничә көнгә сузылды бу эш, чөнки ике арадагы стена ярты метр чамасы калынлыкта булып чыкты.

Ниһаять, көннәрнең берендә Муса үзенең «кытыр-кытыр» ыннан ялга туктап, колагын ярыкка терәгәч, күрше камерадан мендәр аркылы гына кебек, тонык тавышлар килгәндәй булды. Муса, бармак та рәтләп сыймастай шул тар гына ярыктан үзе кереп китәрдәй булып, тагын да стенага сылана төште.

— Әһә, ишетелә, ишетелә! — дип кычкырды ул. — Андре, сизәме борының?

Андре да ятып тыңлап карады. — Әйе, сизә, дускай, — диде. — Кая бир әле...

— Юк инде, бәгырем, сабыр ит. Урыныңа бас.

Тагын күпмедер азапланганнан соң ярыктан тычкан күзедәй генә якты күренде. Озын саплы өтергесен боргалый-боргалый, Муса аны ки-

кайтэ төште. Теге яктагыларның шул тишек авызында гына сөйләшкәне хәзер ачык ишетелә иде инде. Муса өтергесен тартып алды да пышылдап кычкырган күкрәк тавышы белән:

— Алиш! Алиш бәгырем! Мине ишетәсеңме? — диде.

Теге яктан Алиш та ярыкка авызын куеп ук яткан булса кирәк: аның артык нечкәргән күңелдән җылардай булып, өзгәләнеп чыккан тавышы ишетелде.

— Ишетәм! Ишетәм, Муса җаным!..

Һәм икесе дә сүзсез калдылар. Икесенең дә тамак төпләренә кинәт нәрсәдер утыргандай сөйләшә алмас булдылар. Ә йөрәкләре, дөрселдәп тибә-тибә, бер-беренә омтыла иде. Шулай озак кына газап чиккәннән соң, ниһаять, Алиш актык көче белән үзен мәҗбүр итеп:

— Исәнме... хәлләрең ничек?.. — дия алды.

— Үзең ничек, дускаем? — дип сорады Муса да телгә килеп. — Мин бу араларда синең өчен бик хафаланып яшәдем. Менә тыңла әле, сиңа бер әйбер багышлаган идем. «Абдулла Алиш дуска» диелгән...

Һәм шулай төрмә парашасына башын терәп, камера идәненә сузылып күкрәге белән яткан килеш, үзенең иң якын дустына багышлап язган шигырен ниндидер көчле һәм җылы, ягымлы һәм тирән тавыш белән укый башлады ул:

Кайгырма, дус, яшьли үләбез дип.
Без алмадык сатып гомерне,
Үзебезчә яшәп, үзебезчә
Без чиклибез аны түгелме?

Билгеләми гомер озынлыгын
Еллар саны, картлык житүе.
Бәлки менә шушы үлем безгә
Мәңге бетмәс яшәү китерер?

Мин ант иттем җанны кызганмаска,
Саклар өчен халкым, илемне.
Йөзәү булса гомрең, син барсын да
Шушы юлга бирмәс идеңме?

Шатландыра безне: көн дә илнең
Бер-бер яңа уңышын ишетү;
Нинди зур көч: читтә үз-үзеңне
Халкың белән бергә хис итү.

Мин тиремне саклап исән калсам,
Үлем миннән аша сикерсә,
Шул яшәүме булыр, «хаин!» диеп,
Ил битемә минем төкерсә?!

Юк, теләмим мин бу «исәнлекне»,
Йөрәк минем моңа үчекмәс.
Кешеме мин, илем үги иткәч,
Җирдә миңа эчәр су беткәч?!

Юк, кайгырма, дускай, безнең гомер
Ил гомренең тик бер чаткысы,
Без сүнсәк тә, безнең кыюлыктан
Арта бары аның яктысы.

Батырлык һәм илгә турылыкны
Шушы үлем белән белдерик.
Безнең яшьлек шушы хисләр белән
Данлы иде, көчле иде бит!!

Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең
Эзсез сүнә, диеп уйлама!
Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда!

Алиш тагын беркавым эндәшми торды. Аның тыелырга теләп сыкравын, еш кына тирән-тирән тын алуын ишетергә һәм бөтен җаны-тәне белән дулкынланган хәлдә нииндидер авыр газап кичерүен шулар буенча аңларга мөмкин иде. Мусаның аңа тагын нииндидер җылы сүзләр әйтәсе, аркасыннан сыйпап юатасы килде. Ләкин андый сүзләрне ул инде шигырендә әйтеп бетерде кебек. Шуның өстенә ул үзе дә бик дулкынланган иде. Ничек шулай булмасын: күпме вакытлардан соң һәм күпме тырышулардан соң дустының тавышын ишетә ул, рәхәтләнеп сөйләшә ала!..

Ниһаять, Алиш, үзенең чуалган киләбен берхәтле рәткә салыр хәлгә килде булса кирәк, стенаның теге ягыннан хәсрәтле генә тавыш белән җавап бирде:

— Рәхмәт, Муса дускаем! Синең яңарту ялкыны шикелле шигырь көченә сокланып бетә алмыйм. Җилкәсенә чалгы күтәргән үлемнең үзен үтерерлек рух көче дә бар синдә... Әмма шунысы үкенеч, мондый әйбәт шигырьгә мин лаеклы кеше түгел, Муса туганкай...

— Син шундый кунак кызы инде, тыйнаклык белән дан тотасың!

— Кяшки шулай гына булсачы!.. Юк... җинаятем бар минем...

— Тукта, нәрсә сөйлисең син?! — дип кычкырды Муса, коты чыккан тавыш белән. Кинәт аның күңеленнән яшен утыдай куркыныч уйлар чагылып узды, ул аларны хәтта ачык аң белән зиһенләргә дә курыкты. — Нинди җинаять ул?!

Һәм Алиш әлеге каһәр суккан Ишбулдинның матрица урлау вакыйгасен әйтеп бирде. Тыны беткән кеше кебек, тукталып-тукталып сөйләде ул. Моның аңа никадәр авыр икәнлеген аңлау кыен түгел иде.

— Икенчедән, — дип дәвам итте Алиш, — мин моны шул көнне үк сиңа әйтмәдем... Көчем җитмәде... Яшердем... Шулай гына узмасмы, дигәнмендер инде... Ә шуннан соң эшләр сүтелеп китте...

— Кайчан бу, кайсы матрица? — дип сорады чиксез борчылган Муса.

— Август башларында... Курск—Орел хәбәрләре иде, бугай.

Муса шактый вакыт эндәшми торды. Шул чакта булган хәлләрне күздән кичерү белән мәшгуль иде ул: шул үк листовка белән легионда да тоттылар. Моның арасында бәйләнеш бармы? Турыдан-турысы юк кебек. Чөнки анда, сыналмаган Ямалтаевка ашыгып сер ачу аркасында тотылганнар... Ә Муса Җәлил нишли? Чемоданына листовка тутыра да легионга китеп бара... Бу инде немецны артык ачык авыз дип, татарча белми ул дип уйлаудан, ә үз милләт кешеләренә артык тиз ышанудан килә торгандыр. Һәрбер колонизатор, иң әлек, шул халыкның үзеннән чыккан ялчыларга таянып һәм шулар кулы белән халыкны җиңеп, үзенә буйсындыруын марксизмнан хәбәрдар кешеләргә онытмаска кирәк иде, югыйсә. Иван III татарны татар кулы белән җиңде дигән сүзләр тикмәгә генә әйтелмәгәндер... Һәр җирдә шулай. Шәрыкъта гарәпләрне, һиндләрне һәм башка халыкларны да шулай бөкерәйтә бит инглизчаннар...

Бу озак паузадан соң, ниһаять, тирән сулады да:

— Без барыбыз да җиңелрәк уйлаганбыз, Алиш, — диде Муса. — Мине Варшава вокзалында тотып алдылар, чемодан тулы «күчтәнәч» иде... Легиондагылар да җиңел ышану аркасында эләккәннәр: Ямалтаев дигән бәндә саткан... Шулай, туганкай, без, сикереп чыга алмастай сихерле көрчектә, йөз күз астында яшәдек. Гадәттән тыш сак һәм оста көрәшеп, егетләрне тизрәк алып киткәндә генә тотылмаган булыр идек, бәлки... Өлгермәдек... Хәзер инде бер-беребезне гаепләшүдән файда юк... Инде соңгы сулышта дошман безнең вөҗдан һәм намусны таптый алмасын! Җиңдем! дип сөенмәсен. Үлгәндә дә җиңелми үлик!

— Әйе, җиңелми үлик! — дип, кайнар пышылдады Алиш. — Рәхмәт, дускай, син миңа җан керттең. Юкса мин үземне бер дә яратмый башлаган идем... Ә хәзер мин, баш күтәреп кабатлый алам:

Мин ант иттем җанны кызганмаска,
Саклар өчен халкым, илемне!
Йөзәү булса гомрем, мин барын да
Шул мөкатдәс юлга бирермен!..

...Алар хәзер көн саен шулай, җайлы вакытын туры китереп, туйганчы сөйләшә башладылар. «Сак-сок» бәетендәге малайлар шикелле араларына тау үсеп бер-берен күрә алмасалар да, беренең тавышын бере ишетү аларга күп рәхәтлек бирә иде.

Әмма Муса моның белән генә чикләнеп кала алмады. Ул тагын эшкә тотынды. Икенче стена буенда җылылык батареясы бар иде. Ул шуның сырлары арасыннан бер урын сайлап алды да яңадан әлеге өтергесе белән кирпеч кимерергә кереште. Инде Фоат дус белән «күрешергә» кирәк! Эх, иптәшләренең һәммәсенә дә шушы корал көче белән генә юл салу мөмкин булса иде!..

## IV

Фәхри Димски, төрмәдән чыгарылгач, ничектер урам уртасында калгандайрак булды. Солдат буларак легионга озатырга тиешләр иде, ләкин аның белән кызыксынучы булмады. Төрмәдә аунап, резин шланглар белән тетелеп беткән киемнәре дә бик шикле итеп күрсәтә иде аны — яңадан тотып ябулары мөмкин. Шуңа күрә ул «Идел-Урал» комитетын эзләп китте. Хальсштордагы Ноенбургер урамына җәяүләп барып җиткәнче байтак вакыт узды. Ул концерт белән килгән чакларда Берлинда бер генә җимерек йорт та күзгә ташланмый, сугышмый торган бер илнең тыныч каласы диярлек иде. Ә хәзер башкачарак икән: ике-өч квартал узган саен җимерек йортлар күрергә туры килә. Кайберләренең әле генә сүндергәннән соң булы ак төтеннәре дә саркып ята. Фәхри, боларны күреп сөенмәсә дә, сугыш немецның үз өстенә дә ява башлавы турында уйлап барды.

Комитетка килеп кергәч, Фәхри үзенең элекке танышларын нигәдер очрата алмады. Шулай да, ишек төбе киртәләрен шома гына сикереп дигәндәй, Шәфи янына уза алды ул.

Кабинет хуҗасы аны башта танымамышка салынды. Әрсезләнеп беткән легион формасындагы погонсыз солдат кәефенә ярамады аның. «Кем син, энкәш? Нәрсә урлап тотылдың, ник монда кердең, кем кертте, ник кертте?» шикелле сораулар тезеп китте ул. Фәхри монда да үзен нык тотарга булды. Хәзер болар белән аяк терәп сөйләшмичә булмас, күрәсең.

— Ай-яй, хәтерегез саеккан икән, Гаптрахман агай, — диде ул елмайган булып. — Сез кайчандыр Фәхри Димскинең тавышын бик мактый идегез, ә хәзер танымыйсыз да!

— А, бунтаушик Фәхримени әле син? — Шәфи хәтта урыныннан ук чигенеп куйды. — Алай булса, бөтенләй сөйләшер сүз бетте, энкәш, бар, бар!

— Юк, — диде егет, дәрәҗәле генә итеп. — Менә карагыз, бер гаебемне дә тапмадылар. — Һәм ул төрмәдән биргән язуны учы белән шап итеп өстәлгә каплады.

Шәфи, теләр-теләмәс кенә дигәндәй, күзлеген киеп, кәгазьгә борынын төртте.

— Күзәтү астында, дигән бит!

— Ансы, Гаптрахман агай, кем генә күзәтү астында түгел икән? Бәлки, сез дә, мин әйтәм, андый күздән мәхрүм түгелдерсез әле... Кем белгән...

— Әй, әй, теленә салынма, энкәш! — диде Шәфи, бармагы белән янап. — Нәрсә кирәк соң сина?

— Нәрсә, дип... Мин җырчы кеше, артист. Үз һөнәрем буенча эшләрмен, капеллага кайтарыгыз, легионга...

— Һи-һи, үтүт инде капеллагыз. Җилгә очты ул фетнә оясы. Аларның хәзер төрмәдән калганы Франциядә җир казый.

— Алайса, миңа Франциягә ярамый инде, поднадзор бит, — диде Фәхри. — Бер гөнаһсыз башны тагын төрмәгә тыгулары бар. Сез лутчы мине Даргибельме, Узедоммы тирәсендә җырчы итеп урнаштырыгыз, Шәфи агай. Мин бик рәхмәт әйтер идем...

Шәфи башын кашый башлады. Анда булмый. Үзедом да, Даргибель дә буш хәзер... Бетте легионның шаулап торган чаклары. Габдрахман абзагызның кәеф-сафа корырга вакыты юк, Унгляубе әфәнде дә буш түгел, яшелчә сезоны бит. Үзенең Аннкламдагы салат заводына легион солдатларыннан кәбестә кистерә...

Ул, әлбәттә, Фәхригә боларны әйтмәде. Ул аны кая тыгарга белми иде. Ә бит бу өтекнең тавышы әйбәт, каядыр ерак җибәрмәскә иде. Мәҗлес-фәлән җыйган чакларда кул астында гына шундый җырчы малайлар булса, эчеңне тишәрмени?

Шәфи трубканы алып фон Мендегә шалтыратты. Халык җырларын бик әйбәт башкара, фольклор! — дип мактады. Аннары трубкасын элде дә:

— Булды, бар. Университет артында Остминистериум, шунда профессор фон Менде. Ул хәзер шәрыкъ телләрендә радио тапшыру башлыгы. Артист итеп алыр үзеңне... Әмма, кара аны!

— Карамаган кая инде ул, Гаптрахман әфәнде! — дип өзгәләнгән булды Фәхри, ишеккә атлый-атлый.— Нахактан алла сакласын...

Радиога урнашып алганнан соң, аныниндидер бер магазин бинасына китереп керттеләр. Монда, Ленинградтан Кавказга барышлый әсир төшкән рус артистлары тора икән. Ә бина элекке бай бер яһүднең универмагы булган, имеш. Димски шунда үзенә бер почмак тапты. Атна-ун көн эшләп, кулына даими пропуск әләгү белән Фәхри Шиловны эзләп китәргә ашыкты. Ләкин сәяхәте уң булып чыкмады. Франкфуртка билет алып, иртәнге поездга утырган гына иде, беренче станция арасында ук документлар тикшерү башланды. Фәхрине кире бордылар, аның пропускысы Берлин эчендә йөрү өчен генә икән. Ул моны үзе дә белмәгән иде әле. Әмма ничек кенә булса да, Франкфуртка барып килергә кирәк иде бит. Һәүбәттәге якшәмбедә ул тагын юлга чыкты, поездларда кеше күплегеннән файдаланып, полиция күзеннән читтә калырга теләде, ләкин тагын барып чыкмады, өч станция киткәннән соң тагын борып кайтардылар. Унбиш көн буе, нинди хәйлә табарга белмичә, аптырап йөрде дә тагын юлга чыкты. Бу юлы инде төнлә бармакчы булды ул. Кичке унда Көнчыгыш вокзалга килеп перронга чыккан гына иде, нәкъ шушы районда һава тревогасы башланды. Кешеләрнең күбесе тоннельләргә тулды. Өстәге составлар, юлчы төягәннәре дә, бушлары да, читкә тартыла башлады. Димски Франкфурт поездының соңгы вагонының соңгы баскычына чак кына эләгә алды. Аннары караңгыда вагонның туалет бүлмәсен карманып тапты һәм шунда кереп бикләнде. Аның бәхетенә каршы, поезд бомба өермәсеннән үз вакытында ычкына алды. Якын-тирәдәге көчле гөрселдәүләрдән вагоннарның сикереп-тартылып китүләрен тойган саен һәлакәт көтеп барды ул. Әмма андый бәла булмады, туалет ишеген дә шакымадылар. Вагондагыларның җаннары уч төбендә генә иде, күрәсең...

Шулай итеп, Фәхри Франкфуртның икенче вокзалына килеп төште. Муса өйрәткән сыра заводын эзләп тапты. Шул тирәдәге озын-озын такта баракларны да күрде. Фәхри шуларның берсенә кагылды. Барак эчендәге катлы-катлы сәндәрәләр буш, тик алардан иске-москы асылынып һәм вак салам коелган сыман булып тора иде. Ишек төбендә кулын ак чүпрәк белән урап муенына аскан бер урта яшьләрдәге хатын гына, нидер эшләп, табуретта утыра. Фәхри аңа йомшак кына тавыш белән исәнлек-саулык теләде дә үз йомышын сорады.

— Ой,родненький, не пытай про яho [1],— диде хатын ниндидер катнаш тел белән. Һәм шунда ук як-ягына каранып алды.— Аны инде бер атнадан бирле эзлиләр... Безне дә куркытып бетерделәр... Ә Шиловның юкка чыгуына инде ун көн бардыр. Эзлә син даладагы җилне!..

Фәхри кабат нәрсә әйтергә белмичә, офтанып чыгып китте. Тагын бер баракка кереп карады. Андагылар бөтенләй сөйләшергә дә теләмәделәр. Фәхри аларның шикле карашы астында баракпан чыгып сызды. Бераздан соң аның артыннан бер кыз күренде. Битләре, нәрсә беләндер янганмы яки пешкәнме шикелле, ямьсез кызыл булып, бүртмәчләнеп тора иде.

— Сез кем буласыз соң? — дип сорады ул, әкрен генә. Фәхри ничек дип җавап бирергә белмәде: төп серен ача алмый бит инде ул. Шулай да радио артисты икәнен әйтте.

— Радио? Берлинда?.. Бервакытны анда... Симаев та... ой! — Кинәт ниндидер хәтәр нәрсә исенә төшкән кебек, куркулы тавыш чыгарып, кыз күзләрен йомды. Аның керфекләре юклыгын һәм каш урыннары да шешенке кызгылт кара гына булып калганлыгын Фәхри хәзер генә күреп алды. Кыз яңадан күзләрен ачты.— Сез... белми идегезме аны?

Фәхри тагын аптырап калды: әйтергәме, юкмы... Хәер, хәзер инде яшерүнең хаҗәте булмас. Симай барыбер утыра бит. Аннан соң бу һәрхәлдә дошман түгел инде, күренеп тора...

— Әйе, белә идем әзрәк...— диде Фәхри, кызның кызганыч йөзеннән һаман күзләрен алмыйча.

— Аның иптәше бар иде... Алиш... Абдулла... Ул кая?..

Егет аны да белгәнен әйткәч, кыз тагын «оһ!» дип, йөрәге кычкырткандай бер тавыш чыгарды да үксеп елап җибәрде. Ниндидер читен кеше иде бу. Бөтен рухы, психикасы җимерек, ахры...

— Мин — Фая исемле,— диде ул, елау аралаш.— Алиш минем танышым, дустым, хәсрәттәшем иде. Шундый һәйбәт кеше иде ул, акыллы иптәш иде. Шундый нечкә күңелле ата иде, үзенең ике улын сагынып сөйләгәндә күзләремә яшь килә иде...

Бу сүзләрдән соң Фәхри дә ачыла төшеп, үзенең төрмәдән чыгуын, Муса тапшырган йомыш белән килүен әйтте. Ә кыз исә, һаман елыйелый, үз фаҗигаләрен кыска гына сөйләп бирде.

— Шуннан соң озак та үтмәстән безне монда күчерделәр. Алишны да, дядя Мусаны да күрмичә калдым,— диде.— Ә дядя Шиловны эзләмәгез... Тапмассыз. Ул моннан качты. Ләкин, куркам, кулда булуы бик ихтимал. Юкса, инде шул вакыттан бирле бер күренер иде...

Бараклар арасындагы почмакта артык озак тору мөмкин түгел. Фәхринең Берлин пропускысыннан башка һич нәрсәсе юк бит. Ул китәргә ашыкты. Кызның да вакыты юклыгы күренә иде, тик аның бер генә үтенече бар: ничек кенә булса да Алишка үзенең иң кайнар сәламен, изге теләкләрен ирештерүне сорый. Фәхри моны эшләргә вәгъдә бирде.

— Эх, бар идең Берлинга, күр идең свидание сорап! — диде кыз көрсенеп.

— Ансы мөмкин түгел, хыял итмәгез,— дип елмайды Фәхри.— Без бит «гаепле» кешеләр...

— Мөмкин түгелен үзем дә яхшы беләм. Моннан ук җибәрмиләр. Без «гаепле» генә түгел, без коллар бит, коллар! — Фая Фәхригә кулын сузды.— Сезне монда җибәргән өчен язмышка рәхмәт әйтәм. Абдулланы күргәндәй булдым... Рәхмәт...

Алар кайнар итеп кул кысышып, исәнлектә, илдә күрешү теләшеп аерылыштылар. Фәхри, озын аяклары белән биш атлыйсын бер атлап, вокзалга юнәлде.

---

[1] Ой, туганкаем, аның хакында сорама.

...Ул Берлинга кайтып төшүгә, үзләре торган универмагның кайбер стена кисәкләре генә ыржаеп калган һәм әле дә янгын ысы чыгып ята иде. Күрәсең, узган төндә вокзал тирәләрендә генә туй итмәгән икән үлем...

Инде кая барырга?.. Ул радио коридорларында һәм Шәфи комитеты диваннарында кунып йөрде. Әмма, җырчының тавышы белән файдалансалар да, торыр почмак табып бирүче булмады. Эзләнә һәм уйлана торгач, Әлемчан Илдриси әфәнделәргә барып чыкты ул. Кайчандыр бу кеше дә Фәхринең тавышын яратып сөйләгән һәм Кылычбай белән икесен чәйгә дә чакырган иде бит. Шул чакта ул Мусаны да анда очратты һәм әфәнденең карашы аңа да начар түгел кебек иде. Чөнки Илдриси әфәнде, үзе әйтүенчә, бик зыялы кеше һәм туган якларыннан килгән сәнгать ияләренә, шагыйрь вә әдипләргә бик хөрмәт белән карый икән... Шуның өстенә аның җәмәгате Шәмсел ханым да һаман элекке хезмәтендә, радио өчен пропаганда материаллары хәзерли бит. Ул да Фәхригә болай яман караган сыман түгел. Бәлки берәр почмак күрсәтерләр...

Һәм Димски ялгышмады. Бәләкәй генә ярым караңгы чолан сымак бер урын тәкъдим иттеләр аңа. Тик бер шарт белән: озакламый медицина докторы буласы Илдерхан исемле улларына татарча җыр өйрәтергә. Доктор кеше һәр яктан мәгълүматлы булырга тиеш, янәсе...

Фәхри шуларда тора башлады һәм әкренләп аларның уй-фикерләрен дә төшенеп алды. Алар Мусаны кызганып сөйлиләр иде. Шәмсел ханымның уенча: ул шундый әйбәт, әдәпле, инсафлы егет, эчкерсез бер гөнаһсыз җан. Ул мескенне большевиклар гына, котыртыпмы-көчләпме, юлдан яздырганнар. Үзе тагын шундый әйбәт шагыйрь. Аның бердәнбер улының исеме белән «Илдар» дигән опера да язган...

Фәхри бу сүзләрне ишеткәч, Мусаның яхшы кеше икәнен тагын да куәтләбрәк сөйләде һәм иплән кенә бер фикер кыстырып карады: шушындый мөгътәбәр кешеләр сорап караса, Мусаны үлемнән коткармаслар иде микән? Менә бу булыр иде изгелек!

— Һай, ансы мөмкин түгел! — дип кычкырып җибәрде Әлемчан әфәнде. — Гестапо дигәннәре — бик хәтәр җир. Алла сакласын, коммунис артыннан йөрисең дип, үзеңне тыгып куюлары бар!..

Шәмсел ханым да, кухняда бармаклары утка пешкән шикелле, кинәт өстәлдәге кулын тартып алды. Ходай үзе күрсәтмәсен! Бер генә тәүлек булса да ул инде үзе утырып чыккан кеше,— белә! И мескен Муса-а, шунда үләр микәнни инде... Бер нишләп булмый шул...

Фәхри, болардан кул селкеп, бер кечкенә үтенеч буенча уллары белән сөйләшеп карады. Анысы ул хәтле үк куркак түгел икән, Мусага ризык тапшыру мәсьәләсен хуп күрде һәм, «ферлеслих»[1] кеше буларак, илтеп бирүне үз өстенә алды. Шуннан соң Фәхри үз күңеле өнәгән таныш-белешләреннән талоннар табып, Муса белән Алишның икесенә бер тапшыру оештырды. Бармак битедәй генә кәгазь кисәгенә: «Түфли ямый торган без[2] табылмады, каядыр югалган — дигән сүзләрне татарча язып, нечкә генә итеп бөтерде дә ипи йомшагы эченә тыкты. Һични сизелерлек түгел иде... Берничә сәгатьтән соң Илдар, «Тапшыруыгызны алдым, рәхмәт. Муса» дигән русча язу алып кайтты. Шуннан бүтәнне язарга ярамаганын бик яхшы белсә дә, Фәхри бу сүзләр белән генә канәгатьләнмәде, эче пошып калгандай булды. Ичмаса, бер генә булса да ишарәле сүз көткән иде ул...

Моннан соң Фәхри үзенең Ямалтаев белән «исәп-хисабы» турында уйлый башлады. Муса алдында бирелгән изге ант үтәлергә тиеш! Ул иң элек Мәмүтнең Краков ягында взвод командиры булуын сораштыр-

[1] Ышанычлы (благонадежный).
[2] Шиловны күрә алмавын, качкан булуын аңлатү.

рып белде. Аннары радиодагы тагын бер-ике җырчыны оештырып, легионның Польшада калган бүлекчәләреннән әйләнергә ниятләде. Шәфи Алмазга кереп, моның әһәмиятен аңлатырга тотынды. Маклер башта каршы торып маташса да, Димски аның милли хисләрен бик каты кытыклап җибәргәч, түзмәде, Һадиевны боларга «комисар» итеп чыгарып җибәрде...

Билгеләнгән маршрутны тиз-тиз узып, Краковка килделәр, ротаны җыеп концерт бирделәр, әмма Ямалтаев туры килмәде. Ул үз взводы белән егерме чакрымдагы кечкенә бер станцияне сакларга җибәрелгән иде. Анда ябык зона дип кертмәделәр. Бу аның Мәмүткә ачуын тагын да ярсытып җибәрде. Тау-таш арасына качкан ерткычны сагалаган аучы шикелле, җайлы вакытны көтәргә, барыбер туры китереп, ул бүрене атып егарга булды. Фәхринең күңелен биләгән беренче уй — хәзер шул гына иде....

## V

Бельгия егетенең җан биздергеч куркак та күренмәве, артык батыр да булып кыланмавы Мусаны үзенә тартты. Аның һәрбер хәрәкәте гади иде: сүз ачсаң, рәхәтләнеп сөйләшеп була; гел үзе турында сөйләп, мактанып теңкәңә тими, артык уф орып та сине җәфаламый, көләргә-еларга һәрвакыт җаен таба. Кешегә, үз манарасыннан торып, тәкәббер карау белән дә чирләми. Менә шул табигый гадилек аларны дус итте. Әйтерсең, алар бөтенләй дөньяның ике читендә яшәгән ике халыкның бер-берен белмәгән ике улы түгел, ә бер халыкның, бер атаның бала чактан ук бергә уйнап үскән ике улы. Утыралар, сөйләшәләр, якыннарын сагынышалар. Муса үзенең Чулпаны белән Әминәсен сагынып сөйләсә, Андре үзенең ялгыз калган әнкәсен сагына. «Ә сөйгән кызың юк идемени?» — дип сорагач, оялчан гына елмаеп куя. Булган икән булуын... Андый кыз да булган дөньяда! Тик алар яңарак кына танышкан булганнар... «Сөям!» дип әйтешергә дә өлгермәгәннәр. Немец жандармы Андрены төнлә, кыз яныннан кайтканда, тотып алып киткән... Сагына егет, ник сагынмасын. Тик менә кыз гына ничектер... Белә микән Андреның рәшәткә эченә ни өчен эләккәнен?..

Икенче бер көнне Татарстан белән Бельгия турындагы тарихи, географик һәм этнографик хикәяләр, Казан белән Брюссель калаларының матурлыгы сөйләнә. Һәркемнең үз иле үзенә газиз, һәркем үз илен матуррак итеп тасвирларга тырыша. Шуннан инде сүз үзеннән-үзе шул матур илләргә тизрәк кайту ягына таба борылып китә. Андре тизрәк сугышның бетүе һәм бу таш капкыннан ычкыну теләкләре белән хыяллана башлый. Муса да моның белән дәртләнеп киткәндәй була. Тик ул үзен киләчәк заманга куеп түгел, үткән заманга куеп, туган-үскән җирләренә кайта алмас кеше булып сөйләргә тотына.

— Ник син алай төшенкелеккә биреләсең? — дип борчыла Андре.— Бәлки әле бөтенләй көтелмәгән бәхет аяк астында гына ятадыр. Белмәссең, сезнекеләр тиз генә килеп җитәрләр дә безне коткарып та өлгерерләр. Бәлки союзниклар диңгездән һәм һавадан берьюлы десант төшерер һәм күз ачып йомганчы Берлинга кереп, безне йолкып та алыр?..

Муса йомшак ирония белән генә көлемсери. Малай чактагы иллюзияләр исенә төшә. Андреның әле әйткән сүзләре дә шул балачак хыялларын хәтерләтә. Ләкин ул Тиммерманска җитди җавап бирә:

— Юк, дустым, бу төшенкелек түгел,— ди.— Бу — фактның күзенә, үлемнең үзенә карап сөйләү генә... Әйе, синең теләкләрең изге. Әйе, безнекеләр болай киләләр һәм кызу киләләр. Ләкин арада әле мең чакрым юл бар. Ә сугыш юлының һәр карышын кан һәм үлем аша атларга кирәк. Алар нихәтле ашыксалар да әле тиз генә Берлинда була

алмаячаклар. Әйе, союзниклар да, ихтимал, кыймылдар. Әмма монысы тагын да ераграк фараз. Ә гестапо безне, син әйткән бәхетле көн килгәнче, әлбәттә, үтереп өлгерәчәк. Ул мондый вәгъдәсен төгәл үти белә... Менә нилектән миңа үземне үткән заманда калдырып сөйләргә туры килә. Нишлисең: сугыш, солдат, үлем — алар бергә йөри... Дөньяда бөек идеаллар бар, Андре. Шуларның берсе: үз илең, үз халкың азатлыгы өчен чигенми көрәшү һәм иң кадерле җаның — газизеңне дә аямау... Мин үзем дә, иптәшләрем дә — үкенмибез. Алдан ук белеп чыктык бу мәйданга...

Көнбатыш Европада үскән Андре өчен мондый сүзләр бик үк аңлашылып бетми. Шулай да ул үз камерадашын нәрсә көткәнен яхшы сизенә. Һәм шул бәләкәй генә гәүдәле кешенең олы ныклыгына, фидакарьлегенә сокланып, уйга кала иде: шундыйлар да була микәнни соң?..

Әмма Мусаның Андредан һәм бүтәннәрдән башка тагын бер дусты бар иде әле. Күзгә күренми, кулга тотылмый, ә бары тик күңел түрендә генә утыра торган дус иде ул. Үзен үлем көткәнен бик ачык белсә дә, шул дусты аны тынычландырып килде: ул әле тиз килмәс кебек тоелды. Калган көннәре һәм сәгатьләре бик санаулы булса да, алар әле тиз генә бетмәс, һаман дәвам итәр кебек күренде. Шигырь язганда шул ук дусты аның уйларын һәм кулларын үзенчә юнәлтте. Дар агачы көткән шагыйрь, яшәү хыял итеп:

Сөйгән кызым кебек елмаер да,
Үбәр төсле үрелеп ирнемнән.
Һәм чакырып ирек бәйрәменә
Ул җитәкләр төсле җиңемнән...

диде. Андре дустының католик рухание биргән догалык китабын алып, аның буш битләренә үзенең «бүләген» язып калдырганда да, шул дусты кушуы буенча:

Кайтса иде гөлләр арасында
Гөрләп үткән көләч көннәрем.
Дускай, сиңа бүләк итәр идем
Илкәемнең иркә гөлләрен...

дип башлады ул. Шулай үзенең соңгы сәгатьләрен минутлап санамыйча яшәгәндә, яңа ел килеп җитте. Аларны таш читлеккә китереп тыккан шомлы кырык өченче елның соңгы киче килде. Яңа ел каршыларга аларның бер нәрсәләре дә юк иде. Кулларында хрусталь кәсәләр чыңламады, алар эченә салынган шәрабләр күз алларында кояш нурыдай җемелдәп уйнамады. Дөньяда мондый бәхетләр барлыгы турында алар тик хәтерли генә алдылар. Андре үзенең бик күптәннән бирле саклап килгән иң кадерле сыен хөрмәтле кунак өчен хәзерләгән табынга куйган шикелле, каяндыр ерак кесәсеннән бик пөхтәләп төрелгән бер сигарет чыгарып, Муса алдына куйды.

— Бу безнең шампански була инде алайса? — дип көлемсерәде Муса.— Бу да ярый. Ә закускасы миннән...

Төрмә йокламый иде бүген. Камераларда нindidер басынкы гүелдәү беленеп тора. Шуңар күрә, кулларында сәгать булмаса да, борынгы ратуша куранты ишетелмәсә дә, тышта ачы буран уйнаса да, яңа ел килгәнне барыбер белделәр. Тәрәзә башларындагы ачык фрамугалардан суык җил өрсә дә ябмадылар. «Котлы булсын яңа ел!», «Ирек алып килсен!», «Җиңү китерсен!» дип, ачы ялкын тулы тавыш белән ашыгып әйтелгән өзек-өзек сүзләр рус, татар, француз, хәтта немец телләрендә яңгырап алдылар. Татарчасын Шабай кычкырды булса кирәк, тавышы аныкына охшаган иде... Андре, сигаретын кабызып, Мусага сузды. Җәлилнең тәмәке тартканы һәм аны юану чарасы дип уйлаганы да юк иде. Аскы иренен шаян сәлпәйтә төшеп көлемсерәп, сигаретны кулына

алды һәм шул ук шаян төс белән житезләнеп суырып бакты. Авызы тулы әчкелт төтен богызлау башындагы бәләкәй генә тын тишегенә килеп тыгылды. Муса, тончыгып, кыхык-кыхык йөткерә башлады. Ул ара да булмады, авыз эченә ниндидер җылымса, тозлы сыман сеңләгәйме, төкерекме тулды. Ул аны. тиз генә парашага барып, төкереп ташлады һәм сискәнеп китте: төкергән нәрсәсе кара-кызыл кан иде. Ачка шешенгән лагерьлар, төрмә һәм кыйнаулар, бөтен газаплар яшен тизлегендә күз алдыннан кичте... Әмма ул, һични булмагандай, яңадан Андре каршына килде дә:

— Ай-яй каты икән шампанскиең! Безнең «кырыклы» да болай булмый,— дип көлгән булды. Шуннан соң Андре суырды. Кулларын биреп, яңа ел белән котлаштылар. Аннары кочаклашып, ирләрчә яңакларыннан үбештеләр. Бик җитди чырайлы иде алар икесе дә. Йөзләрендәге елмаю кисәге, көзге өрәңге яфрагында ничектер ялгызы гына эләгеп калган чык бөртеге шикелле, зәгыйфь кенә, сүрән генә тибрәнә иде. Муса вәгъдә иткән «закуска»сын укыды. Андрега багышлаган иде ул аны. Бу шигырендә дә баштанаяк тагын икенче дустының куәтле тавышы яңгырады

Хәмер, шәраб безгә булмас инде,
Яшебезнең кайнар тамчысын
Бокалларга салып күтәрербез,
Шуның белән күңел ачылсын...

. . . . . . . . . . . . . . .

Бу яңа ел безгә татлы ирек
Һәм бәхетле яшәү китерсен.
Ул салдырсын кулдан богауларны
Һәм күзләрдән яшьне киптерсен...

. . . . . . . . . . . . . . .

Шушы елда, дустым, җитәкләшеп
Кайтсак иде туган йортларга.
Балаларны, хатын, туганнарны
Данлы җиңү белән котларга!..

Гаҗәп. Муса татарча укыса да, Андре аның тәрҗемәсен сорамады: «Ә мин шул килеш тә аңладым бит!» — диде һәм шигырьнең кыскача эчтәлеген үзе әйтеп бирде. Күрәсең, йөрәкләр бик көчле булып бер төсле типкәндә, уйлар да сүзсез аңлашыла торгандыр...

Аннары Муса почмакта торган параша катына килеп ятты һәм аның артындагы тычкан баласы да сыймастай тар ярык аркылы Алишны котлады. Шушы шигырен укып, аның күңелендә дә шул ук күзгә күренмәс дустының матур утларын кабызды. Тик бу утларны ул Фоатка гына җиткерә алмады. Чөнки ул як стена әле һаман тишелеп бетмәгән иде. Каты кирпечне атналар буена чокый торгач, өтерге башта үтмәсләнде, аннары кителде, аннары сынып чыкты. Хәзер инде Муса бөтенләй коралсыз калган һәм яңаны сорап алуы да ансат кына була торган эш түгел иде...

Муса үзенең актык сукмагындагы актык адымнарына кадәр күңел түрендәге шул якын дусты белән бергә барды. Соңгы сулышта да алар аерылышмадылар. Аның бу якын дусты яшәү һәм ирекне, сөю һәм матурлыкны, юк, бөтен дөньяны ярата торган якты һәм бөек өмет иде!..

## VI

Гыйнварның уннарында булса кирәк «ярык телефон»нан Алиш тавышы килде. Муса параша артына колагын куеп ятты. Алиш прогулкада Габбас Шәрипов дигән легион егете белән танышуын, эше каралып беткәч, гаеп таба алмыйча чыгарачакларын (әгәр алдамасалар!) һәм моннан Тегель төрмәсенә күчерәчәкләрен хәбәр итте. Нишлибез, дәфтәрләрне шуның белән чыгарсак ничек булыр икән? — дип сорады ул аннары.

Муса бу хәбәргә сөенеп куйды. Габбасны белә иде ул. Сталинград ягыныкы, лейтенант булган, оешманың ышанычлы кешесе, взвод командиры буласы егет...

— Бик әйбәт булыр бу! — диде ул һәм, идәннән торып, гарәп хәрефе белән язылган беренче дәфтәрнең биленнән нечкә генә җеп кисәге белән бәйләде дә ярыкка тыкты. Аннары стамеска сабы белән теге якка этәрде. Алиш аны кыштырдатып тартып алды.

Шагыйрь күңеленең беренче кошы оясыннан кузгалды... Аңа ничектер монсу һәм хафалы булып китте. Исән-сау чыгармы төрмә коймаларыннан? Барып җитә алырмы туган якларга?.. Ә бит анда аның бөтен йөрәге, җаны һәм буйсынмас рухы. Газап, хәсрәт һәм тигезсез тартышлар белән үтелгән авыр юлларның кан тамар йомгагы... Хәерле юл сиңа, очар кош!..

...Шәрипов авыру иде. Төрмәләрдәге ач ризык һәм тукмак белән туйдырулар аны тәмам йончытып, киселдереп ташлады. Тыны кысылу, купмас ютәл белән газаплану, тәннәре суык тиргә бату һәм саташып йоклаулардан үзенең нинди хәлдә икәнен аянып аңлый иде ул. Тегельгә күчерелгәч, атна-ун көн буена прогулкага да чыга алмады. Көч-хәл белән төрмә амбулаториясенә сөйрәлеп барды. Андагы врачмы, фельдшерме кисәге аның күкрәк һәм аркасын аннан-моннан гына тыңлаган булды да бер сүз әйтмәде, тик язып утыручы ак халатлы ханымга җиңелчә генә кул селкеп куйды. Ул моны авыруга сиздерми генә эшләргә теләгән иде кебек, ләкин Шәрипов эчтән елтыраган очлы күзләре белән эләктереп калды. Аның болай да боек күңеле, кырау суккан чәчәк төсле, бөтенләй коелып төште. Халатлы ханым, медик кушуы буенча, аңа ютәл йомшарта торган микстура язып бирде дә камерасына кайтырга кушты. Коридордагы чират көтүчеләр арасына чыккач, Габбас мөмкин кадәр әкренрәк атлап, күзләре белән һәркемне җентекләп барды: кем дә булса очрамасмы, легионнан алынганнарны әле һаман монда диганнәр иде бит... Эзләнүе бушка китмәде, иң арттагы кешеләр арасында артист Габдулланы күрде ул. Текәлебрәк карамасаң, аны хәзер танырлык та түгел икән: йөзләре һәм күз кабаклары шешенгән, битләренә каратут болытлар төшкән, чырае сап-сары булган. Аның бавыры һәм бөере шешкәнлеге белгеч булмаган кешегә дә күренеп тора иде. Шәрипов, нәүбәт көтүче сымак, аның янына утырды. Исәнме, дип пышылдады. Сөйләшү тыелган иде, тыелган булса да сөйләшергә кирәк иде. Баттал аны башта бер-ике минут танымыйча торды, чөнки Шәрипов та бик нык үзгәргән һәм күрешмәгәннәренә дә күптән иде. Габбас шаян сүз әйтергә үзендә көч тапты:

— Бакцы, бәбәге мутный цәй булган — адәм танымыйдыр! — диде.

Баттал шуннан соң гына төшенеп алды: — Ай, кәбәм, синмени, Әппәс маем! — дип, аның кулын кысты. Сөйләшер сүзләр тәүлек буена да бетәрлек түгел иде, ләкин алар иркенләп сөйләшә алмадылар. Габбас үз куенындагы ниндидер яшерен җөйләр арасыннан башкаларга сиздерми генә нәрсәдер чыгарды да Батталның учына салды. Муса белән Алиштан сәлам әйтте. «Мин алар яныннан, диде, үзең танышкач, башкаларга да житештер...» Шулай пышылдады да хушлашып китеп барды — хәле авыр иде.

Баттал, ул киткәч, читкәрәк тайпылып, учын ачты. Анда амбулаториядән бирелә торган порошоклар хәтле генә итеп төргән ике кәгазь кисәге иде, тиз генә эчке кесәсенә яшерде. Тик, врачка күренеп, камерасына кайткач кына ул кәгазьләрне сүтеп карады: Муса шигырьләре иде. Соңыннан бу шигырьләр күчерелеп, башка кулларга да барып кергәч, «Муса да монда икән!» дигән сүз таралды. Һәркемнең аны күрәсе килде. Ә Гайнан Кормаш исә аны һәр прогулка саен, ялт-йолт каранып, эзләп йөрүчән булды. Җайлы вакытлар туры килгәндә, камераларга бирелә торган газетадан рупор ясап, «Муса абый, син кайсы

камерада?.. Тавыш бир!» дип кычкыра торган булды. Әмма Муса да, Алиш та бу төрмәдә озак вакытлар күренмәде...

Шулай январь ае да узып китте, февральнең җепшек буранлы һәм бездәге апрель башларына охшаган кояшлы, тамчылы көннәре башланды. Унынчы февральдә дә шундый кояшлы, матур көн иде. Камераларның иртән ачылган форточкаларыннан хәтта җылымса җил кергәндәй булды. «Яз исе килә!» дип исни-исни, кешеләр йөзләре белән шул кече тәрәзәләргә сузылды. Шул көнне Тегельдә утырган татар егетләре язмышында бер үзгәреш булып алды: аларның барысын бергә астагы бер киң бүлмәгә җыйдылар да, «кара козгын»га төяп, каядыр алып киттеләр. Егетләр ике яктагы эскәмиягә тезелгән, ишек төбендә ике автоматчы. «Һичбер сүз сөйләшмәскә!» дип алдан ук куркытып куйдылар. Теге чакта Варшавадан килгәндәге шикелле, тагын һәркемне эчке бер шом биләп алды. Дошман кулындагы тоткынның үлемнән башка нәрсә көтүе мөмкин? «Инде монысы актык юлыбыздыр... Хушыгыз, туганнар, бәхил булыгыз...» ди төсле иде боек күзләре. Әмма бу да соңгы юл булмаган икән әле. Аларны гестапоның төп йортына алып килеп, шулай ук зур бер бүлмәгә керттеләр. Монда зур чиннардагы өч немец утыра иде. Егетләр беренче сорауларда ук аңлап алдылар: «аерым өчлек» утырышы икән бу. Формаль кагыйдәләр буенча «эш» белән таныштылар да хөкем чыгардылар:

I. Баш җинаятьче Һумерoф — Муса Җәлилнең боерыкларын турыдан-туры үтәп, «Идел-Урал» легионын таркату, баш күтәрү эшен алып барган һәм кулга алу вакытында яшерен листовкалар табылган Гайнан Курмашоф, Зиннәт Хәсәноф, Габдулла Батталоф, Фоат Сәйфелмөлекофларны, баш җинаятьче Һумероф белән берлектә, аерым процесста карарга;

II. Берлиннан листовкалар ташыган Солтанай Фәритофны концентрацион лагерьга, каторга хезмәтенә җибәрергә;

III. Җинаятьләре хәзергә ачык исбат ителмәгән Габбас Шәрипофны һәм Хисмәт Рушатофны надзор астында легионга кайтарырга.

Немецча укылган бу карарның тәрҗемәсен аңлатып та тормадылар, тоткыннарның кулына да бирмәделәр: азиатларга ничек тә ярый. Кирәк булса, немецча өйрәнсеннәр!..

Егетләрне кире җыеп алып киттеләр.

Александерплац төрмәсендә калган Кылычбай Киекбаевны да шул ук «өчлек» карап, Гумеровның адъютанты булып поляк партизаннары белән элемтәдә йөргәне өчен, Бухенвальд лагерена, гомерлек каторгага ясадылар.

Көннәр үлемдәй авыр билгесезлек эчендә яңадан шулай ага бирделәр. Ә кояш һаман ягымлырак карый башлады. Габбасның күңеле аз гына күтәрелеп киткәндәй булса да, хәле җиңеләймәде. Һаман да шул купмый торган ютәл интектерә иде аны. Февраль ахырларында тагын аска чакырдылар. Төрмә кәнсәләрендә ул Рушатов һәм Фәритев белән очрашты. Өчесенең дә юл кәгазьләрен рәтләделәр дә конвой белән озатып җибәрделәр. Бу юлы поездга утыртып алып киттеләр. Кая илтүләрен алар тагын белмәделәр. Берничә сәгатьтән соң бер станциядә Фәритевне төшереп калдырдылар. Ул, хушлашып, күзләреннән яшен сөртә-сөртә аерылды.

— Исән кайта алсагыз, туган җир туфрагын минем өчен дә үбегез! — диде.

Шәрипов белән Рушатов юлда бик аз сөйләштеләр. Бердән, алар бөтенләй диярлек таныш түгел иде. Капелла җитәкчесе Рушатовны Габбас читтән күреп кенә белә, ә Рушатов — Габбасны бөтенләй белми иде. Икенчедән, хәлләре дә сүз белән мавыгырлык түгел: Габбас авыру булган кебек, Рушатов та тәмам йончыган, ачлык һәм кыйнаулар хәлдән тайдырган, аның хәтта аягына басып торырлык та егәре юк

иде. Аннары, элек яшерен эш алып барганда бик үк яшерenә белмәсәләр дә, хәзер төрмә аларны һәр адымда бик сак булырга өйрәткән иде. Менә шушы сәбәпләр Шәриповка ачылып китәргә, кесәсендә Муса белән Алиш дәфтәре ятканын Рушатовка әйтергә мөмкинлек бирмәде...

Шул ук февраль ахырларына таба Мусаны төрмә башлыгына чакырттылар. Ишек ачуга ук киңлеге һәм шыксызлыгы күзгә бәрелгән һәм кара күн тышлы авыр креслолар, шундый ук кара өстәл, шкафлар белән җиһазланган кабинетка килеп керде ул.

Өстәл артында утырган төрмә башлыгының бер кырыенда Геденктафель, икенче кырыенда җирән зондерфюрер Унгляубе урнашкан иде. Муса берхәтле сагаебрак калды: моңарчы бу кеше бер дә күренмәгән иде бит... Шәфи дә, «комитет»ның бүтән бер адәме дә күренмәде, кул селтәгәннәр иде... Хәзер ни йомышлары бар икән?..

— Утырыгыз, Муса әфәнде, биттешөн! — диде Унгляубе, төче тавыш белән генә сузып.— Кәефләрегез ничек?..— Ул русчаны ярыйсы белә иде.

— Фюрернекеннән яхшырак...— дип ычкындырды Муса көлеп.

— Ничек инде ул? — дип сорады төрмә башлыгы, куркынган төс белән.

— Соң аны һәр тарафтан куалар. Ул мескен хәзер ау боҗрасына эләккән бүре шикелле. Ә мине берәү дә кумый. Камерада тик ятам рәхәтләнеп!

— Гросс концерт! — дип кычкырып җибәрде Мемориаль такта әфәнде.

— Сабыр итегез,— диде Унгляубе, кулын күтәреп. Аннары Мусага елмайды: — Сез әле һаман шутник икәнсез, Муса әфәнде. Ярый, ярый, бик яхшы. Төрмәдә утыру шикелле авыр һәм күңелсез чакларда да шулай шаяра белү, әлбәттә, мактаулы хәл. Алайса, сезнең кәефләр начар түгел икән...— Унгляубе юан бармак очлары белән өстәл поставын дыпылдатып куйды.— Ә без сезнең авыр хәлегезне җиңеләйтү теләге белән килгән идек...

Муса үзенең күптәнге танышы хәйләкәр Унгляубегә текәлеп карады. «Аңламыйм әле, нинди хәйләләрегез бар?» ди иде кебек аның күзләре. Һәм зондерфюрер моны төшенеп алды. Үзенең бик җитди һәм изге миссия белән килгәнлеген әйтте. Муса һәм аның иптәшләренең эше тикшерелеп беткән. Германия каршындагы җинаятьләре бик зур икән һәм алар, һичшиксез, тулысынча исбат ителгән. Бу эш Дрезденда, икенче Имперский судта каралачак. Империя законнары буенча, алар чит ил шпионнары, сугыш диверсантлары буларак хөкем ителәчәкләр. Аларның һәммәсен дә үлем җәзасы көтә...

— Әмма Розенберг әфәнде, зур гуманист философ буларак, бик җәлли сезне...— диде Унгляубе, киң тын алып.— Талантлы шагыйрь, ди. Киләчәктә зур шөһрәт иясе булачак кеше, ди. Мин үзем дә шул ук фикердә. Шәфи әфәнде дә сезне әйбәт яктан искә ала... Шуңа күрә безнең сезне коткарасыбыз килә. Һиммлер һәм фюрер әфәнделәр алдына үтенеч белән кереп, сезгә яшәү һәм ирек бүләк итүләрен сорамакчы булабыз. Ул чагында сез сау-сәламәт килеш тагын иске хезмәтегездә калачаксыз. Без, гуманизм белән сугарылган немецлар, сезгә ышанабыз!

— Ниятегез, чыннан да, изге икән,— диде Муса, җитди генә.— Рәхмәт... Үлмәскә мин риза... Сорагыз... Барып чыкса, мин бик шат булачакмын...

— Менә бу перекрясно! — диде немец, әлеге әйбәт русчасы белән. — Без әле риза булмассыз дип курыккан идек...

— Гаҗәп икән, — дип көлде Муса. — Үлемнән котылырга кем риза булмас икән?..

— Белмәссең сезне. Фанатик коммунистлар бит сез...

— Ә коммунистлар — яшәүне иң нык сөючеләр!

— Монсы да бик матур! Алайса, Муса әфәнде, бик кечкенә генә бер формаль эш бар.— Унгляубе, елан кабыгы төсле портфеленнән бер бит саргылт кәгазь чыгарып, Муса алдына салды. Аның уртасына башта немецча, аннары русча кыска гына текст машинкада сугылган иде:

«Моңарчы эшләгән эшләремнең ялгыш булуын аңлап, мин, шагыйрь Муса Җәлил, чын күңелдән тәүбә итәм». (Имза.)

Нинди кыска, нинди гөнаһсыз сүзләр! Бер төрле йөкләмә-фәлән дә юк, гафу үтенергә дә кушмыйлар... Муса бу текстка тагын бер мәртәбә күз йөгертеп чыкты. Шушы өч авыз сүз сине үлемнән коткара, сиңа гомер бүләк итә! Син тагын якты кояш астында, иректә, рәхәтләнеп яши бир!.. Нинди яхшы кешеләр болар: шушы өч авыз сүзне әйтү белән үк мине коткармакчы булалар. Алдар дип тә курыкмыйлар, ышаналар... Кызыктыргыч, ах, кызыктыргыч!..

Мусаның авыз почмакларында әз генә көлемсерәү чалымнары сизелде. Моңарчы аңа төбәлеп, аның йөзендәге һәрбер үзгәрешне күзәтеп утырган һәм оста психолог саналган доктор Унгляубе, чынлап та, әле генә Мусаның башыннан узган шул сәер уйларны куәтләгән шикелле, юаткыч сүзләр белән аңлатырга тотынды:

— Күрәсез, бу кәгазь кисәге коры бер формальность кына,— диде ул, үзенең яхшылык теләү тавышы белән.— Анда бер төрле йөкләмә дә, үзегез изге санаган идеяләрдән ваз кичтерү дә, сезнең горурлыкка тукына торган гафу үтенүләр дә — берсе дә юк. Ул бары тик «тоткынның үзеннән бер тавыш» кына. Юкса, безгә әйтүләре бар: «Туктагыз әле, әфәнделәр, сез аның өчен үтенәсез үтенүен дә, ә соң тоткын үзе телиме?» дип. Менә шунда инде без бу кәгазь кисәген күрсәтәчәкбез: менә, рәхим итегез, шагыйрьнең үз имзасы!

Унгляубе сөйләнгән арада Муса әлеге чуалчык хисләреннән айнып өлгергән иде инде. Аның, кинәт кабынып китеп, бу саргылт кәгазьне немецның шундый ук сары йөзенә бәрәсе, аны эт итеп тиргисе килде. Ләкин бу минутта — тынычлыкта иде көч. Һәм шул гали тынычлык белән бу дошманның җирән битлеген ертырга теләде ул.

— Шушындый ук кәгазь минем белән утыручы башкаларга да тәкъдим ителәме? — дип сорады Муса.

Кинәт куелган бу сорауга психолог Унгляубе отышлы җавапны тиз генә таба алмады: ык-мык килеп торды да аскы йөзен ача торган сүзләрне әйтеп ташлады.

— Алар — нәрсә соң?.. Без шагыйрь язмышын кайгыртабыз. «Һәр бөҗәк яшәүгә лаеклы» дигән фәлсәфәне сугыш дәвере күтәрә алмый...

Мусаның баш очыннан суык су койгандай булды: аның җандай якын күргән, бергә янган, бергә көрәшкән иптәшләре үлеп, ул бер үзе исән калырга тиешмени? Алар гомере бәрабәренә Муса үзенә яшәү сатып аламы? Менә ничек! Моңарчы изге санаган эшләреңне ялгыш дип таны, имеш! Дошманың каршында тәүбә ит! Ә тәүбә итүчене тезләндерәләр!..

Муса үзен шундый хәлдә итеп күз алдына китерде. Аның бөтен тәне яңадан чиркәнеп, гәүдәсе тетрәнеп китте. Каяндыр җан төбеннән: «Һич!..» дигән тавыш килде. Тагын ярсып китүдән үзен көчкә тыеп, немецка карады.

— Юк, минем дусларым — бөҗәкләр түгел. Аларның һәркайсы алтын хәрефләр белән языла торган асыл кешеләр! Ә тирә-ягында дуслары шаулап тормагач, шуның өстенә бу дөньяны кошлар да, җәнлек һәм бөҗәкләр дә бизәмәгәч, шагыйрьнең берүзе яшәвеннән нинди кызык булсын, әфәндем?.. Аның бит бик борыңгы изге мәгънәсе бар. Чын шагыйрь — тугрылык һәм гаделлек, азатлык һәм тигезлек якчысы булган. Җәберләнгәннәрне яклап сарайларга, патшаларга каршы тавыш күтәргән. Шул борынгы мәгънә коммунистның хәзерге мәгънәсе белән

килеп тоташа... Күрәсез, алар икесе дә бер! Ә шулай булгач... ертыгыз сез бу сары кәгазьләрне. Юридик фәннәр докторының нечкә хәйләле кулы белән төзелгән булса да, ак җепләре ярылып ята. Чын шагыйрь, чын коммунист сатылмый! Үзенең гадел эшеннән тәүбә дә итми, җиргә дә тезләнми!

— Туктагыз әле, майн һерр! — диде Унгляубе, сүз сораган шикелле кулын күтәреп.— Без сезнең үз файдагыз өчен...

— Юк, кирәкми,— дип кырт кисте Муса.— Тезләнеп яшәгәнче, аягүрә үл! — дигәннәр. Тере кешеләр өрәктән курыкмыйлар!..

Унгляубенең тулы итләч йөзе бүртенеп чыкты. Ике чигәсендә кызыл төерләр сикергәләп куйды. Аның шул минутта ук торып, бу бәләкәй гәүдәле арык мәхлукъның шыр сөяк яңагына чалт итеп сугып җибәрәсе һәм идәнгә салып таптыйсы килде, тик ояты җитмәде, чөнки әле генә яхшылык фәрештәсе булып кыланды бит ул... Шулай да, тешләрен шыкырдатып, урыныннан торды һәм үтергеч сүзләр тапкандай ачу белән:

— Иң томана фанатик азиат сез! — диде.— Сезнең барыгызны да бер бауга тезеп асарга кирәк! — Һәм, тимер дагалы үкчәләре белән шак-шок атлап, кабинетның аргы тәрәзәсенә китеп барды.

— Менә моның ысы аңлашыла ичмаса! — диде Муса, мыскыллы тавыш белән.— «Песиле-күселе» уйнауның кирәге дә калмады.

Унгляубе эндәшмәде. Ул инде гамьсез бер кыяфәт белән кулларын галәфи кесәләренә тыгып, урамга карап тора иде. Хәзер аның урынына «курай ботлы» тикшерүче эшкә тотынды. Мусаны «зур концерт»ка җибәргән чакларында сорау беркетмәләре тәмамланып бетми кала иде, яшел папкасыннан чыгарып, шуларны тәгәлләде, аннары тикшерү һәм гаепләү нәтиҗәләре белән таныштырды, шуның өчен кул куйдырды.

— Менә монда, күгәрченкәем, бу урынга,— дип такмаклый-такмаклый тагын сузды.— Менә шулай... Хәзер инде суд ясар өчен бөтен эш әзер. Озакламый сез гадел хөкем тыңларсыз... Германиянең һәр эшендә тулы тәртип һәм гадел закон булыр. Нәкъ музыкадагы тигез ритмик һәм матур мелодик агыш шикелле... Әйе, әйе, мин үзем дә сәнгать кешесе! Шул тигез агыш эченә бер генә ят тавыш килеп керсен, бер генә ялгыш нота яңгырасын — шунда ук бөтен симфония җимерелә, ямьсез диссонанс башлана! Сезне дә, күгәрченкәем, шундый ук музыкаль ритмлы тәртип белән хөкем итәчәкләр. Һәрбер нотасына кадәр гадел рәвештә тәгәллек сакланып, җиренә җиткереләчәк. Мәсәлән, суд сезне гильотинага хөкем итә икән, сезнең башны гади балта белән чабарга Германиядә беркемнең дә хакы юк, хәтта атып үтерергә дә хакы юк. Әгәр дә мәгәр кем дә кем үз белдеге белән суд хөкемен боза калса, тулы диссонанс туачак. Һәм көйгә ямьсез тавышлар кушылып, өзелеп калачак!..

«Мемориаль такта», ниһаять, кәгазьләрен җыеп, яңадан яшел папкасына кыстырды. Аннары, бәләкәй генә башындагы ялтыравык чәчен сыпырып, озын нечкә муенын кукрайтып куйды.— Менә, һәммәсе дә тәгәлләнде, сөеклем, инде сез бик рәхәтләнеп камерагызга кайтып китә аласыз...

Мусаның тәмам күңеле болганып, башы әйләнеп, косасы килде. Бу бүлмәдән чыгып китәргә мөмкинлек минутын актыккы көче белән көтеп алды ул. Унгляубене тыңлау ул кадәр авыр булмаган икән, ә менә бу хәшәрәтнең һәрбер төче сүзендә әллә нинди җирәнеч лайла бар кебек, һәм ул синең битләреңә, хәтта йөрәгеңә сылана шикелле.

Надзиратель аны камерага бикләүгә,

— Сволочьлар! — дип сүгенеп куйды Муса.— Ах, кабахәт җаннар!— дип өстәде, ачынган тавыш белән.

Моңарчы анын болай кинәт кабынып китүен күрмәгән Андре ап-

тырабрак калды. Көлемсерәргә теләде, ләкин Мусаның йөзенә карау белән, шунда ук житди төскә кереп, аның янына килде.

— Нәрсә булды, дускай? — дип сорады.

— Сөйләп авыз пычратырлык та түгел! Тәүбә итәргә кушалар. Өч кенә авыз сүз язылган сары кәгазь. Шуңа кул куй һәм мәңгелек яшәү сиңа! Яшә! Җирдә шуышып, фриц үкчәсендәге нәжесне ялап, мәңге яшә!.. Тукта, Андре,— диде Муса, кулын югары күтәреп.— Җавап килде! Хәзер әйтеп бирәм.— Һәм үз почмагына утырып, кечкенә бер кәгазь почмагы өстенә иелде. Бармак башыдай гына карандаш кисәге аны тиз-тиз чуарлый башлады.

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә.
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә!..

. . . . . . . . .

Шунда ук Андрега укып күрсәтте, тәрҗемә итеп бирде. Саф күңелле яшь егетнең күз төпләрендә яшь бөртекләре күренде. Аның бу ерак ил кешесенә соклануы, ихтирамы тагын да артты. «Мин дә шундый була алыр идем микән?..» дип уйлый иде ул. Ә Муса аның биек җилкәсенә кулын салды да күзләренә туры карап:

— Беләсеңме, Андре дускай,— диде.— Минем сиңа бер үтенечем бар. Безнең язмыш инде билгеле. Ул хакта сөйләп тормыйк...— Чабу эченнән уч төбедәй бәләкәй, соры катыргы тышлы бер дәфтәр чыгарды.— Син менә шушыны саклап, моннан исән-сау чыккач, сугыш беткәч, кайсы гына илдә булсаң да, безнең совет илчелегенә кертеп тапшыр... Монда минем йөрәгем, иманым, идеалым, сафлыгым... Моны укып чыккан кешеләр мине үзләре белеп хөкем итәрләр. Аманәтем сиңа шул. Кыен булса да, җиренә житкер...

Тиммерман аны кочаклап алды.

— Тәндә җаным бар чагында моны саклау һәм син әйткән җиргә тапшыру — минем изге бурычым! — диде ул. — Тыныч бул, дустым... Әмма мин башкачарак уйлыйм әле: без икебез дә исән котылырбыз һәм дәфтәрне мин синең үзеңә тапшырырмын!..

Муса бик моңсу гына елмаеп куйды. «Нинди хыялый син, саф күңелле Бельгия егете!..» ди иде аның Андрега төбәлгән күзләре.

## ӨЧЕНЧЕ БАШЛАМ

### I

Судның нәрсә әйтәчәге Мусалар өчен алдан ук билгеле иде. Чөнки аның хөкеме, карак кунычындагы хәнҗәр шикелле, инде күптән үк гестапо почмакларында әзерләнеп куелган. «Үен» башлану белән каракның шул хәнҗәрне ялтыратачагы алдан ук мәгълүм. Шуңа күрә Муса да, иптәшләре дә ул көнне бөтенләй көтмәделәр һәм аңа бер өмет тә багламадылар. Шулай да ул көн килеп житте...

Мартның жете кояшы камераның тимер челтәрле тәрәзәләре аркылы балкып күренә иде. Ул нурлар синең камераңа керә алмаса, каршы стеналарга, андагы тәрәзә пыялаларына төшеп, уйнаклап, күзләрне чагылдыра. Кайдадыр кошлар да сайрашкан тавыш ишетелеп китә. Тик алар үзләре генә күренми. Күңел җилкенеп тышка омтыла. Анда, бездәге апрель ахырлары шикелле, җылыдыр, рәхәттер кебек тоела. Мусаның хәзер тәрәзә яныннан китәсе дә килми. Бере артыннан бере агылган шигырьләр шул ашалып беткән кирпеч тәрәзә төбендә, кояшка гашыйкларча табынган хәлдә туалар. Көн дә кертелә торган «Фолькишер...» газетасының кырыйлары, нәкъ элекке кызлар хаты кебек, кыйгач язылган юллар белән чуарланып бетә. Тик ул шигырьләрне акка

күчереп, дәфтәр итеп теркәргә генә кәгазь юк. Бу тар тасмалардан һични эшләп булмый. Ул икенче дәфтәр өчен дә Андреның актык бит кәгазьләрен гозерләп алган иде инде, киоскыда да юк, ичмаса, хәзер. Дәфтәр битләре бик тиз тулып, тагын әллә нихәтле шигырьләре сыймый калгач, катыргы тышның ахырына үзенең зарын язып куйды: «Бу төптә —33 шигырь. Әсирлектә һәм тоткынлыкта 1942.IX.—1943. XI арасында язганнарым 125 шигырь һәм поэма. Ләкин кайда языйм? Үзем белән бергә үләләр...»

Бүген дә Муса, рәхәтен үзе татый алмаган яз кояшына карап утырган килеш, шул хакта уйланды: кая куярга, кая теркәргә инде боларны?.. Вак кына язып тутырылган газета кырыйларын буйдан-буйга ертып ала да ул, тасма чорнаган шикелле, куш бармакка чорнап, чалбар кесәсенә тутыра. Бердән-бер яшерер урын шул. Андый тасмаларны чабу почмакларына сыйдырып булмый бит. Хәзер инде ике кесәсе дә бүлтәеп чыкты. Ләкин ул юка, начар кәгазьләр анда йөри торгач таушалып, тиз арада чүбекләнеп бетәләр, карандаш язуы таный алмаслык хәлгә килә. Каян гына кәгазь табарга соң? Туйганчы ризык түгел, туйганчы кәгазь!..

Шул чакта камера йозагы шалтырады, ишектә надзиратель күренде.

— Һумеров Мусаа! — дип кычкырды ул. — Аска, әйберләрең белән!..

«Кая, нәрсәгә?» — дип сорыйсы юк иде, һәм монда аңлатып та маташмыйлар. «Әйберләрең белән» — дигәч, үзеннән-үзе билгеле: каядыр башка җиргә, димәкки. Муса, надзиратель чыккач, газета кырыйларын ашык-пошык ертып бөкләштерде дә кесәсенә салды. Барлы-юклы әләмә-сәләмәсен бер чүпрәккә төйнәп кулына тотты. Кинәт кенә аерылышасы булу Андрены бөтенләй каушатып калдырды. Ул Мусага булышып маташса да, анда сугыла, монда бәрелә, куллары калтырый, нәрсә китереп бирергә белми иде. Муса хәсрәтле генә елмаеп аның каршына басты. Әле кайчан гына бу сөйкемле егет бөтенләй таныш түгел, хәтта шикле кеше сыман күренгән иде. Ә хәзер алар бертугандай дуслар. Менә аерылу минутлары да килеп җитте. Күрешерләрме алар яңадан? Тоткын язмышы кайларга куар аларны? Кайда туфраклары калыр?..

Икесе дә бер сүз дәшмәделәр, икесе дә берьюлы кочаклашып алдылар, икесенең дә күз төпләре чыланган иде, икесенең дә шул чыланган күзләре: «Мин бик теләр идем синең белән тагын күрешергә!..» дияләр төсле иде.

— Хуш, бәхил бул, Андре! — диде Муса, ишектән чыгышлый.

— Озакламый яңадан күрешик, Муса! — дип калды Андре, күзләрен мөлдерәтеп.

Күрше камерада да шул ук хәл кабатланды. Надзиратель аска чакырганнан соң Алиш үзенең камерадашы Эмиль Мейзон каршына килеп басты.

— Беләсеңме, кадерле дус,— минем сиңа зур бер үтенечем бар...— диде ул һәм күкрәк кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарды. Тышына адресы русча язылган иде.— Бу кәгазь бик кечкенә. Соң нишлисең, язасы сүзләрем томнарга сыймаслык булса да, мин аларны шушы бер бит эчендә әйтеп бирергә тырыштым... Син, ireккә чыккач, моны минем туган илемә зинһар салып җибәрә күр! Зур үтенечем шушы, дустым!..

Эмиль Мейзон йомшак мөгамәләле, әдәп һәм ихлас күңел белән сөйләшә торган укымышлы кеше иде. Алишның бу сүзләреннән соң күңеле тагын да йомшарып китте.

— Баш өсте, сөеклем,— диде ул.— Ирекккә чыгуымның беренче көнендә үк мин моны үтәрмен, бу минем изге бурычым! Алай гына да түгел, әгәр җәмәгатегездән җавап килсә, мин аңа безнең монда бергә үткәргән көннәрнең ачы хикәясен сөйли торган озын-озын хатлар язар-

мын... Хәер, дустым, юк, мин ул хатларны язасым килми! Мин синең үзеңне исән кайтарасым килә! Судьяларның күңеленә алла миһербан салып, сезнең барыгызны да коткарсыннар. Һәм син ике малаеңны да кочагыңа кысып, ә гүзәл Руккия ханымны каршыңа утыртып, безнең монда күргәннәрне үзең сөйләп бирерсең! Нинди бәхетле минутлар, ә!

Алар икесе дә салмак кына елмаешып куйдылар. (Бер-береңне сүз белән юаткан булу да ярап куя бит кайчакта!) Аннары Алиш, аның кулларын кысып, артына борылмыйча, чыгып китте.

Алиш, бу көннең бер килеп җитәсен ачык белгәнгә күрә, ул хатны күптән үк язып куйган иде инде. Ләкин алдан биреп куясы итмәде, аерылганда бирелгән амәнәт тизрәк тапшырылучан була, дип уйлады ул. Ә йөз бит урынына бер генә битлек хатта мондый сүзләр язылган иде:

«Кадерле тормыш дусым, сөекле әнкәм, газиз балаларым, туганнарым һәм дусларым минем! Сезгә үземнең, ихтимал, актыккысы булган ялкынлы сәламнәремне җибәрәм.

Мин, Абдулла Бари улы Алишев, А. Алиш, 1001 укчы полкның кызылармеецы, Брянск янында камалышта калып, 41 нче елның 12 октябрендә пленга эләктем. Төрле лагерьларда сөргердән булып йөри торгач, ахырда Чехословакиягә җибәрелдем, андагы заводларның берсендә шлифовальщик булып эшләдем. 1942 ел ахырында Берлин якынындагы лагерьда шагыйрьләрдән Муса Җәлилне һәм Р. Саттарны очраттым («Кызыл яшьләр» газетасыннан). 1943 ел августында, легионер дип аталган татар хәрби әсирләре арасында листовка таратуда гаепләнеп, кулга алындым. Минем белән түбәндәге кешеләр кулга алынды:

1. **Муса Җәлил** — шагыйрь, Казаннан.
2. **Гариф Шабаев** — финанс хезмәткәре, Ташкенттан.
3. **Сәйфелмөлеков** — сәүдә наркомы урынбасары, Үзбәкстан.
4. **Фоат Булатов** — инженер, Казаннан.
5. **Әхмәт Симаев** — журналист, Мәскәүдән.
6. **Тагын** 20—25 ләп кеше, легионнан.

Без ярты ел Берлин төрмәсендә утырдык. Суд. 7.II.44. Дрездендә булырга тиеш...

Туасың, күрәшәсең, китәсең... Күрәсең, шундыйдыр инде безнең язмыш! Без соңгы сулышыбызгача үз халкыбызга турылыклы булып калабыз. Аһ, нинди яшисе килә! Сезне күреп, баштан кичкәннәрнең барын да сөйләп бирәсем килә, газизләрем!

Р. Саттар 43 елның июнендә качып китте. Аның язмышы билгеле түгел... Күп кенә язылган һәм уйланган нәрсәләр үзебез белән китеп югала инде...

Һәммәгезне дә кысып кочаклап үбәм. Бигрәк тә Алмазым белән Айвазымны. Аларга белем бирергә тырышыгыз. Мәңгелеккә хушыгыз. Сезнең тугры улыгыз, ир һәм дустыгыз: А. Алиш. 28.I.44».

Инде һәммәсе дә күп тапкырлар уйланган, күп мәртәбә хис ителгән, йөрәк итләрен әчеттереп, тамырдагы кайнар каннарны өшетеп, бавырландырып узган иде. Шуңар күрә ул, бу хатны язганда, хисләргә бирелергә теләмәде. Кирәкми. Кешенең дөнья һәм якыннары белән саубуллашкандагы соңгы сүзе тыныч һәм акыллы булырга тиеш. Нигә кешеләрне яшь белән ярсытырга?.. Кирәкми... Телеграф теледәй кыска җөмләләр мөмкин кадәр күбрәкне аңлатырга тырышсыннар. Дөнья хәтле зур һәм җаваплы эше, үзен үлемсез иткән көрәше турында да, бөтен хисләренең сулышына басып, бары тик өч кенә сүз әйтте ул: «Туасың, көрәшәсең, китәсең...» Ә бу өч сүз эчендә калын бер роман язарлык фаҗига ята. Кешеләр акылсыз түгел, аңлый белерләр...

Тик бер генә урында хисләргә бирелде ул: «Аһ, нинди яшисе килә!» дип кычкырды. Бу — ирексездән ычкынган йөрәк тавышы. Нишлисең, яшисе бик килә шул! Кем туйган якты дөньядан?!

Хатны Эмильгә тапшырып чыгып киткәндә, аны янадан урап алган шушы уйлар белән баскычтан атлады ул. Кая барганы билгеле. Алдан ук хәл итеп куелганны, ни өчендер икенче бер шәһәргә алып барып, суд дигән кәмит аркылы раслаячаклар да, бар да бетәчәк... Аһ, нинди яшисе килә!..

II

Аларны этап белән китереп, Дрезден төрмәсенә, тагын да аерым камераларга бикләделәр: бер-берен күрмәсеннәр, сөйләшмәсеннәр. Кансызлык һәм кешелексезлек закон кагыйдәләре белән беркетелгән.

Суд, Алиш язганча, жиденче февральдә булмады. Нининдер жеп очлары килеп житмәү сәбәпле аны әллә ничә тапкыр кичектерделәр. Дрезденгә килгәч тә әле атнадан артык төрмәдә яттылар. Тора-бара бу процесска нининдер дипломатик һәм халыкара политик төс бирергә маташып, суд утырышларына Төркия һәм башка ил журналистларын да чакырган булдылар. Мәскәү шпионнарын, диверсант һәм агентларын хөкем итәләр, янәсе, күрегез.

Кызгылт-көрән кирпечтән шыксыз итеп өелгән империя судының салкын һәм ярым караңгы залына берникадәр кеше җыелган. Сул кырыйда гаепләнүчеләр бүлемтеге. Анда Муса һәм аның иптәшләре әллә ничә сакчы белән уратылган. Уң кырыйда адвокатура урыны — ул буш. Немецлар гадел суды мондый куркыныч җинаятьчеләргә яклаучылар биреп тормый, ә үзләре алар, әлбәттә, яллый алмыйлар. Түрдә үзенең «гадел хөкем» эмблемасын кигән судья, як-ягында киңәшчеләре. Алардан уңдарак, почмакта,— империя прокуроры, алдагы рәттә — берничә журналист. Суд үзенең традицион сорауларын ала, аннары үзенең бөтен хәтәр кыяфәте белән прокурор трибунага баса. Ул бик дәһшәтле итеп башлаган гаепләү речендә Муса белән Алишны язучы маскасы астында Мәскәүдән яшерен җибәрелгән шпион-пропагандистлар итеп, немец гаскәрләре арасында идеологик таркату алып баручылар итеп, Әхмәт Симаевны десант белән ташланган диверсант, немец гаскәри эшелоннарын шартлатучы, хәрби объектларны җимерүче итеп һәм ахырда фюрерне үтерергә йөрүче итеп күрсәтте. Калганнар шушы өчнең турыдан-туры башкаручылары булып күренде, барына да үлем җәзасы таләп итте.

Әмма процесс мондый шау-шулы һәм сенсацияле нәтиҗәне бирә алмады. Салкын һәм шыксыз суд залындагы гаепләнүчеләр эскәмиясенә өч көн буе бер рәттән тезелеп, бер-беренең җан җылысын, дуслык җылысын тоеп утырган һәм шул бердәмлектән зур бер эчке көч-куәт тапкан егетләр, үзләренең горур һәм кыска җаваплары белән андый уйдырмаларны һәр адымда юкка чыгара бардылар. Аларның тәвәккәл йөзләрендә һәм тавышларында курку яки әз генә калтырану билгесе дә сизелми иде. Ниһаять, соңгы сүз белән Муса чыкты. Иптәшләре берьюлы аңа төбәлделәр. Аның өскә калкып һәм күкрәгеп җәебрәк тunion-туры баскан бәләкәй гәүдәсе ничектер олы булып күренә; ябыгып-саргаеп калган йөзе тирән бер эчке киеренкелек белән янган шикелле; аяк һәм борын очлары, һөҗүмгә ташланачак дала шонкарыныкы кебек, аеруча үткенәеп тора; эчкә баткан хәсрәтле күзләренә көйдергеч нәфрәт тулы көчле бер ут кабынган төсле. Ул, һаман саен ялкынлана барып, шаңгырап торган зур залга үз сүзләрен яудыра иде:

— ...Сез безне йөз төрле гөнаһларда гаепләмәкче буласыз. Юк, әфәнделәр, болар һәммәсе дә көлке әкиятләр генә! Без бары тик намус һәм вөҗдан кушуы буенча яшәгән кешеләр. Чын гөнаһлар, җан тетрәткеч олы җинаятьләр башкаларда! Кем, беренче буларак факел булгап, дөньяга ут төртте? Кем, безнең ил кешеләре тыныч хезмәттән соң татлы ялда ятканда, җәйнең сайрар кошлары таң җырлары түгә баш-

лаганда, безнең баш очында туплар гөрселдәтергә тотынды? Кем таптады безнең тыныч җирләрне? Кем асты-кисте, яндырды, җимерде, көйдерде?.. Мин сандугачлар сайравын, күгәрченнәр гөрләвен, яшь күңелләрнең гыйшык җырларын ярата торган шагыйрь идем. Кем мине, шул бәхетләрдән мәхрүм итеп, солдат булырга мәҗбүр итте? Әмма мин, бик үкенәм, бәхетсез солдат булдым: камалышта яраланып, сезнең кулга эләктем. Күпме ачлыкларга, бетләр талавына, тифкә түздем! Ниһаять, ул гына җитмәде, мине көчләп китереп, легион солдаты иттеләр. «Идел-Урал» легионы, «Төркстан», «Кавказ», әрмән, грузин, әзербәйҗан, казакъ легионы... Болар һәммәсе дә меңнәрчә-меңнәрчә әсирләрне көчләп, ирексезләп укмаштырылган нәрсәләр! Бу бит, ананың улына корал биреп, аны ниндидер әшәке агулар белән исертеп, үз анасын атып үтерергә мәҗбүр итү дигән сүз! Бу нинди законга сыя? Бу нинди халыкара хокукларга сыя? Бу нинди мораль кодексларга, гадәткә, вөҗданга, намуска, кешелек җәмгыятенең элементар тәртипләренә сыя? Менә кайда ул җан тетрәткеч җинаять! Мин шуннан соң түзмәдем, шагыйрь буларак түзә алмадым! Идел-Урал буйларында туып үскән, бер тугандай бергә яшәгән татар, башкорт, мари, чуваш, удмурт, мукшы егетләрен үз туган илебезгә атмаска, үз әнкәбезне рәнҗетмәскә, үзканыбызны үзебез коймаска өнди башладым. Шигырьләр язып укыдым, листовкалар итеп тараттым. Җинаятькә каршы көрәшү җинаятьмени ул?.. Менә минем һәм дусларымның гаебе шул! Алар гаделсезлекне күтәрә алмаучы, үз туган илләрен чиксез сөюче, тау хәтле алтын бәрабәренә дә җан сатмаучы, изге күңелле, гуманист рухлы соклангыч егетләр!.. Юк, гаеп бездә түгел, гаеп — сездә, әфәнделәр! Без гаеплибез сезне!.. Ишетегез, без гаеплибез!..

Прокурор әфәнде безгә үлем таләп итә. Әмма безнең үлем белән генә дөреслекне үтереп булмый, ул үлмәячәк! Инде бөтен дөнья күтәрелә җинаятьчеләргә каршы! Ишетәсезме, еракта туп тавышлары күкри: хаклык, нәфрәт һәм үч давылы шулай кайный анда! Тиздән-тиздән килеп җитәр ул һәм соңгы җавапны сорар!..

Килер ул көн, халык хөкем итәр,
Карар булыр кискен һәм кыска.
Каным белән язган соңгы җырым,
Бул гаепләү акты фашистка!..

Судьяның кыңгырау шалтырата-шалтырата куллары талып бетте, төссез пыяла күзләре, маңгаена сикергәндәй акаеп, кипкән яңакларында өрек төшләредәй төерләр уйнады. Прокурор, аягүрә басып, кулларын бутый-бутый, туктатуны таләп итте. Муса һаман туктамады: йөрәгенә җыелган ачы нәфрәтне түгеп калырга ашыкты ул. Алдарак утырган Шәфи Алмаз, Унгляубе һәм Усман мулла, сикереп торып, Мусаның авызын үзләре дөңгечләрдәй булып утырдылар. Ниһаять, ике ягына ике конвоир килеп басып, Мусаны көчләп утырттылар.

Бүтән гаепләнүчеләргә дә соңгы сүз тәкъдим иткән булдылар: закончә булсын, янәсе. Ләкин берәү дә сөйләмәде, барыбызның да сүзе шундый ук, диделәр.

Суд киңәшмәгә чыгып китте, залда тәнәфес игълан иттеләр, тоткыннарга да тәмәке тартып һәм башка йомышларын үтәп керергә мөмкинлек булды.

— Хәтта шушы агу чәчкәне өчен генә дә тубык сөякләреннән асып куярга кирәк бу азиатны! — диде империя судының как яңаклы рәисе.— Эздән чыккан дошманнар болар. Рәхим-шәфкать булмаска тиеш!..

Фикерләр, әлбәттә, аерылмады...

Суд килүен хәбәр итеп, залны аякка бастырдылар. Үлем тынлыгында үлем хөкеме игълан ителде. Башларын югары күтәреп баскан татар егетләре, үз сафларына ниндидер тимер ныклык сеңдергәндәй, култык-

лашып алганнар иде. Кинәт алар бөтен залны яңгыратып бер аваздан кычкырып җибәрделәр:

— Яшәсен туган ил!

— Яшәсен җиңү!

— Яшәсен тормыш!..

Тагын залда ыгы-зыгы купты. Суд утырышының ябылуы ашык-пошык игълан ителде. Тоткыннарның артында гына торган сакчылар, төрле яктан ташланып, автомат көпшәләре белән төрткәли-төрткәли һәм авыз эчләреннән мырлап сүгенә-сүгенә, аларны залдан алып чыктылар да яңадан Дрезден төрмәсенең ялгыз тартмаларына илтеп тыктылар...

Төн иде, йоклар вакыт иде. Ләкин аерым яшерелгән егетләрнең берсе дә йокы барлыгы турында хәтерләмәде. Һәркайсы үзенең иң газиз, иң кадерле уйлары һәм хатирәләре белән мәшгуль иде. Гайнан Кормаш үзенең ерак Актүбәдәге карт әнкәсе белән сөйләште. Аңа багышлап шигырь язды. Алиш үзенең Алмазын һәм Айвазын сагынды. Аларны әкияттәге ике батыр малай итеп күз алдына китерде. Муса үз Чулпанының: «Әтием, кайт инде син!..» — дигән сүзләрен ишетте. Әхмәт Симай Саниясеннән, коткара алмавы өчен, гафу үтенде. Аннары, моңарчы бөтенләй онытылып йөргән тагын бер кешедән гафу үтенде: «Кайчандыр минем юлдаш булган кеше, син дә кичер мине... Кызчыгымны тәрбияләп үстерү сиңа кала инде... Минем сиңа һичбер үпкәм юк, яхшыдан башка сүзем юк... Син миңа ачуланма инде: нишлим соң, дөньяда бөтен җаның-тәнең белән сөю дигән нәрсә бар икән. Мин шуны татыдым һәм акыл көчем белән сакларга тиешле әдәп-инсаф кагыйдәләрен тотудан гаҗиз калдым. Мөмкин булса, аңла: бу — азгынлык та, бозыклык та, хыянәт тә түгел. Бу — бөек, саф мәхәббәт иде!..»

Аннары ул тар тимер койкага килеп, йөзтүбән капланды, күзләре йомылмады — яңадан Сания аның каршына килеп басты. Әхмәт, аңа кулларын сузарга теләгәндәй, торып утырды. Сания, әлбәттә, юк иде. Таш әрҗә буйлап йөренә башлады. Нәрсәдер исенә төште һәм сәләмәләнеп беткән гимнастеркасының култык эче төбеннән, озак казынып, ерак яшерелгән иң кадерле коралын чыгарды: бармак башыдай гына карандаш кисәге иде ул. Стенадан кытыршы булмаган урын эзләп, югарыга үренде һәм болай дип язып куйды. «Монда Әхмәт Симаев утырды, журналист, Мәскәүле. Россиядән без унбер кеше. Барыбыз да Германиянең икенче империя суды тарафыннан үлемгә хөкем ителдек. Бу язуны укыган һәм ватаныбызга исән кайткан кешедән безнең язмыш турында туганнарыбызга һәм якыннарыбызга хәбәр итүен сорыйм. 24 март, 1944 ел»...

## III

Судтан соң аларның барысын да Берлиндагы Тегель төрмәсенә китерделәр. Хәзер инде ялгыз камераларда тотуның кирәге юк иде, күрәсең: чөнки суд булган, сүз берләшеп бертөрле җавап бирерләр дип куркыр урын калмаган. Шуның өчен аларны берничә камерага бүлеп, бергә яптылар. Өсләренә юан җепле тупас киндер сыман буй-буй нәрсәдән тегелгән кием кидерелде. Инде үлем хәтле үлемгә хөкем ителгәч, һәртөрле вак-төяк җәзалар, чикләүләр бетәргә тиеш иде кебек. Ләкин алай булмады, аларның кулларын куш китереп, наручник кидерделәр. Мусаның судтагы речена немец прокурорының кан тамырлары шартлар хәлгә җиткән иде, шуның үчен кайтармакчы булды, күрәсең. Һәммәсен дә богауда тотарга боерды...

Дрезденнән соң башланып киткән беренче көннәр искиткеч авыр булды. Аларның һәрберсе, тау ишелеп, таш баскан кешедәй, тавышсыз калды. Моңарчы нинди генә кыен шартларда да елмаю көче, шаян сүз көче таба белгән Мусаның да башы түбән иелде. Әле кайчан

гына Алиш белән, Фоат белән бер рәхәтләнеп сөйләшер өчен, төн-көн кимерә-кимерә, камераның калын кирпеч стенасын тишкән иде бит ул. Ә хәзер Алиш та, Фоат та аның янында, аларның өчесен дә бер камерага яптылар, әмма сөйләшер сүзләре юк шикелле. Көннәре өнсез, елмаюсыз узып китә. Нәрсә булды соң?.. Бу яңа хәлнең мәгънәсен ничек аңлыйсы? Алар бит үзләрен үлем көткәнне элек тә белә иделәр. Әйе, белә иделәр... Әмма ул үлем дигән нәрсә, кайдадыр еракта, билгесезлек артында сыман күренә иде әле. Ә хәзер исә үлемне аларның каршына китереп бастырдылар, хәтта суд белән раслап та куйдылар. Инде ниндидер «югары санкция»не генә көтәргә калды. Бүгенме — иртәгәме үлем сиңа үзенең шыр-сөяк кулларын сузар... Җитмәсә тагын, өсләренә бу алачаны кидерделәр. Димәкки, хәзер алар кәфендәге кешеләр. Һәм ул кәфен синең тиздән үләргә тиешлегеңне һәр минут, һәр сулыш саен белдереп тора... Шулай итеп, моңарчы үткән көннәр белән хәзергесе арасына кискен бер сызык сызылды. Башка бер дәвер килде, гомерләренең актык кишәрлеге башланды...

Муса богаулы куллары белән озак кына башын тотып утырды. Фикерләре, әйтерсең, чияләнеп беткән җеп йомгагы... Ничә генә уйласа да, аны һаман бер нәрсә куркытты: бу каһәр суккан хәл гел шулай дәвам итсә, хәзер үк тере мәет булып сузылып ятарга да, муеныңа балта төшкәнне көтәргә генә кала. Ә бу инде — үлмәс борын җан чыгу булачак... Күрәсең, кешеләрне ияртеп бару — ирекле чакта, көрәшергә мөмкин чакта гына башкарыла торган кызыклы вазифа түгелдер. Менә шушындый вакытта да фаҗиганең авырлыгы астында изерәп төшмәү кирәк була торгандыр... Әмма шуны ничек эшләргә соң?..

Иртәгесен Муса, иптәшләреннән алда торып, кыштырдана башлады. Йокламый яткан Алиш белән Фоат аның йөзендә ниндидер көлемсерәү чалымнары күрделәр. Әйтерсең, ул сөйгән кызын уйлый һәм озакламый аның белән күрешергә барачак. Шуңа хәзерләнгән кебек, наручнигын чылтыратып зарядка ясаган булды, аннары өстендәге алачасын башы белән кайтарып кран астына керде, «пых-пых» итә-итә, суп-суык су белән билдән арык юынып маташты. Аның тәне шыр-сөяк иде. Арасыннан үпкәләре күренердәй кабырга сырларын, очлаеп чыккан җилкә башларын, кубып төшәр сыман торган калак сөякләрен тик сары тире генә каплап тора кебек иде. Өстәвенә кыхык-кыхык йөткерә иде әле ул. Аның шулай дуамал кылануын берничек тә аңлау мөмкин түгел иде. Ә Муса һаман үз хантамасында булды: «сөлге» дигән киндер чүпрәге белән битләрен сөртте дә күкрәк һәм кабырга сырларын кызарткачы ышкып азапланды. Нечкәреп калган итсез беләкләрен уйнаткалап куйды.

— Һәх, шәп булды әле бу, җинеләеп китте кеше! — дигән булып, җилкәләрен кукрайтып алды.— Сизәсезме, егетләр, яз килде бит, яз! Шуңар ахры, суны сагынып китте кеше...

Аңа җавап бирүче булмады. Ләкин ул, җавап сүзе көтмәгән дә кебек, тузып беткән эчке күлмәген муены аркылы төшерде дә алачасына барып тотынды.

— Менә хәзер инде «әҗәлник» дигән бу һәйбәт кәчтүмне киеп җибәрсәң дә ярый...— диде.— Шәп бит, ә, егетләр?

Фоат белән Алиш, ниһаять, кычкырып көлмичә булдыра алмадылар.

— Э-э-х-х, Муса,— дип куйды, торып баскан Фоат,— көлдерергә тырышасың син безне, дускай...

— Көлеп булса, яхшырак инде,— диде Алиш.— Җан саулыгы бирә диләр аны... Әйдә, без дә керик кран астына, көлке алып чыкмабызмы.

— Шуны әйтәм әле, егетләр,— диде Муса, аларның сүзенә игътибар итмичә.— Безне бу «үлемгә хөкем итү» дигәннәре ярап куйды бит, ә...

— Ах, алла! — дип ыңгыраشты Фоат.— Сине, дустым, бүген төнлә пәри-җен алыштырмадымы? Нәрсә сөйлисең син!

— Юк, чынлап әйтәм,— диде Муса, һич көлмәстән.— Үзегез уйлап карагыз: моңарчы без бер-беребезне күреп сөйләшергә зар-интизар булып тора идек. Ничәмә айлар буена сагынышттык. Ә хәзер, бу четерекле мәсьәләне әкәнчәтелни хәл иткәч, безне төрле читлекләргә яшереп торуның һич кирәге калмады. Кил, зинһар, сөйләш рәхәтләнеп. Яшә кочаклашып! Бер михнәтнең бер рәхәте була, дип тикмәгә әйтмәгәннәр, күрәсең. Менә бит үлемнең файдасы ничек тия!..

Алиш елый-елый көләргә мәҗбүр булды. Ул тәмам тетрәнде.

— Инде, үз үлемебезне көлеп сөйләүдән башка һич мәзәгебез калмадымы? — дип уфылдады ул.— Шул гынамы?..

— Кайгырма, Абдулла. Үлгәндә көләргә вакыт булмас, ә хәзер көлеп калыйк. Үлемнән көлик. Үлемнән көлик! Уйлап кына кара: без, бергә янган, бергә көрәш башлаган дуслар, актыккы көннәребезне бергә үткәрәбез. Язмышның безгә биргән соңгы һәм иң кадерле бәхете түгелмени бу?..

Үлем ташы баса башлаган көнелләрен шулай бер селкеп, каккалап алудан соң аларга, чынлап та, ничектер җиңелрәк булып киткән сыман тоелды. Телләре ачылды, сүз табылды, моңарчы сөйләнмәгән әллә нихәтле истәлекләрен көн буе сөйләшеп утырдылар.

— Баштарак тикшерүче мине чыгарып җибәрмәкче булган иде, шуңа бик үкендем мин,— диде Фоат.

— Төрмәдән чыгуыңа үкендеңме? — дип көлеп җибәрде Алиш.

— Үкенмәссең! Сезне күрмә, сәбәбен әйтмә — чык та кит. «Сатты бу чукынган!» дип уйласагыз, мин нишләр идем?..

— Ә мин шул каһәр суккан матрица белән изаландым,— диде Алиш.— Берегез дә бәхилләмәс дип курыктым...

— Минем газап та синеке төслерәк,— дип офтанды Муса.— Үзең җитәкче булып, шул листовкалар белән малайларча тотыл, имеш!..

Һәм алар, тагын күп ялгышларын эзләп, булмаган хаталарын да табып, көенешеп алдылар. Тора-бара күңелләре бушанып калгандай булды, йөзләре ачылып китте. Шулай итеп, үлем шәүләсен әз генә булса да артка сөрделәр. Хәзер инде алар һәрберсе бер кыймылдау белән мәшгуль иде. Көннәр узганнан соң аларның наручникларын да салдырып алдылар. Ул шундый куаныч китерде: әйтерсең, алар яртылаш иреккә чыктылар. Муса яңадан газета читләре чуарларга тотынды: ул шигырь язмыйча тора алмый иде. Фоат, инженер кеше буларак, камераның «хуҗалык һәм азык-төлек» эшләрен үз өстенә алды. Төрмә ягынннан тама торган ач паекны ул бик рациональ файдалана белүчән булып чыкты. Җитмәсә тагын, һавага чыккан арада вак-төяк тимер чыбык, бакыр пластинка кисәкләре юнәтеп, чокыр чите ямаргамы, таракан дагаларгамы маташып йөри, көн буе үз почмагында «чәк-чәк» килеп азаплана иде. Алиш, наручниктан котылган кулларын рәхәтләнеп артка куеп, ишекле-түрле йөргәли, ул үзенең язасы килгән әкиятләре турында уйлана иде. Эх, күпме алар, менә шушы төрмә, тоткынлык тудырган чын әкиятләр! Әмма монда әкият язарга теләү үзе бер әкият кенә инде ул... Муса, шигырь язып, дөрес эшли. Алишка да шигырь язу кирәк. Аны газета читенә дә сыйдырып була. Ул инде теге вакытта чыгарган дәфтәренә дә байтак кына шигырь теркәгән иде. Һәм алар, йөрәктә булганны рыясыз әйтеп биргәннәр. Өркыясы, уллары, әнкәсе, туган авылы: шул иң газизләре турында җырлады ул. Шуларны сагынды.

## IV

«Каен басмаларга басып, кайгымны суга салдым...» — дип җырлаган халык. Муса һәм иптәшләренең кара кайгысы алай суга агызып җибәрерлек кенә түгел. Ул аларның баш очына кыл белән генә әлеп

куелган һәм айлар буена: «менә төшәм — менә төшәм!» дип торган бик олы фашист балтасы иде. Шулай була торып та, минут саен аңа карап тетрәнергә, куркып калтыранырга күнмәделәр алар. Баш очларында ыржаеп ялтырап торган үткен балтаны күңел пәрдәләре белән каплап, юрамалый башка нәрсәләр белән мавыгырга, күңел ачарга тотындылар. Муса белән Алиш, матур хыяллар, теләкләр, төшләр дөньясында яшәп, яңа туган шигырьләрне, май кичәнең бик кызыктыргыч җылы кояшы тәрәзә пыялаларына ялкын сипкәндә, өчәү бергәләп укый торган булып киттеләр. Бу үзе бер җан рәхәте бирә иде.

Шундый кичләрнең берендә Алиш бик кызыклы яңа шигырь укыды. Хәтта күпне ишеткән Муса да әсәрләнеп, җылы елмаеп утырды. Үзенең сөекле тормыш иптәше Өркыяга багышлап язылган ул шигырь болай иде:

Исергәнмен эчеп мәхәббәтнең
Йөрәкләргә шифа шәрабын.
Мин аңымны җуеп югалганмын,
Томан иде минем һәр ягым.
Кигезгән ул миңа тормыш камытын,
Камчылаган кирәк чагында.
Нинди генә җәфа күрсәм дә мин,
Чыдаганмын аның хакына.
Син идең ул минем мәхәббәтем,
Күктә янар якты йолдызым.
Мин табындым сиңа, бары сиңа!
Оныттым мин хәтта җир йөзен.
Син балкыдың күктән: һәр көндезне
Уйнап үткән кояш шикелле.
Бер боек хис сиңа күз кадаса,
Яшь йөрәгем минем сикерде.
Ышаныч белән суздың кулларыңны.
Алар йомшак, җылы иделәр.
Ах, ул куллар! Минем тормышыма
Чиксез бәхет алып килделәр.
Бер көн кояш качкан иде бугай:
Болыт баскан иде күк йөзен.
Мин юксынып сине эзләсәм дә,
Син бүлмәдә минем юк идең.
Нинди зәһәр суык булса да кыш,
Яз киләчәк барыбер артыннан.
Шуңа күрә йөрәк борчылмады
Миңа булган ялгыш салкыннан.
Каш җыерып миңа карасаң да,
Ачуланып миңа баксаң да,
Тормыш йөге белән телгәләнгән
Йөрәгемә утлар яксаң да;
Дулкынланып йөргән чакларымда
Уйларымны кире каксаң да,
Язганнарым чүпкә исәпләп син,
Авыр сүзләр миңа атсаң да,
Мин һәрвакыт синең белән булдым,
Карамыйча һичкем сүзенә.
Үткән юлга күзең салу белән,
Син аңларсың моны үзең дә.
Белмәгәнмен кадрең. Саран булдым
Иркәләүгә, җылы сүзләргә.
Ул — төш булган икән безнең тормыш!
Калды хәзер сагынып сөйләргә.
Мин ул төшне кабат күрерменме,
Кочагыңда синең онтылып?
Мин башкача сөяр идем инде —
Бар булганым белән йотылып!
Мин татыдым, бәгырем... Ә син ничек?
«Аерылгач та әле белерсең»,
Дигән сүзләремне хәтерлимсең?
Юкса һаман тиргәп йөримсең?
Мин ул төшне кабат күрерменме.
Әллә, сак-сок кебек, һаман да

Бер ялгызым миңгерәп йөрерменме,
Каушалмыйча, моңсу яланда?..

— Браво! — диде Муса.— Бик җылы итеп, бик ихлас күңелдән язылган. Иң кадерле, иң яшерен серләреңне, авырткан җирләреңне әйтеп биргәнсең...

— Җылысын җылы-ы,— дип куйды Фоат Булатов.— Әмма Өркыя апаң, бу шигыреңне укыгач, чәчеңне йолыкмас микән?

— Бер бөртеген калдырмый йолкып бетерсә дә, һични әйтмәс идем,— дип җавап бирде Алиш.— Тик чәч йолку өчен бер кечкенә генә тоткарлык бар: башлар анда кайтмаячак. Шулай булгач, чәчсез калам дип куркыр урын да юк!..

— Шулай да катырак әйткәнсең. Ничек инде ул: «Язганнарым чүпкә санасаң да...»?

— Бар иде шул андый чаклар да,— дип көлде Алиш.— Икебез дә яшь булганбыз. Ул мине бик тиз генә Жюль Верн итәсе килә иде, яки, иң кимендә — Лев Толстой! Ә мин үземнең чыпчык борынындай хикәя һәм әкиятләремне дә дәүгә саный идем. Бала күңелен яулардай кечкенә генә яхшы әйбер дә зур әһәмияткә лаек дип карый идем. Аннары ул чакларда иҗат кыюлыгы да җитеп бетмәде, малай: «Тегеләй яз да болай яз» дип акыл бик күп бирәләр иде. Яшь язучы буларак, Галимҗан Ибраһимовтан өйрәнергә тырыштым, ярата идем шуның иҗатын! Әмма соңыннан үзенә хат язган өчен теңкәгә тиеп беттеләр...

— Сугыштан соң алай булмас инде,— диде Муса.— Дөньяны бик яхшы таныдык хәзер, акыл керде, күзләр ачылды! Ибраһимов барыбызның да остазы иде, барыбыз да өйрәндек аңардан. Кинәт кенә аның дошманга әйләнүенә күңелнең һич кенә дә ышанасы килми... Сугыштан соң без аны үзебез кузгатып, әдәбият түренә кайтарырбыз! Гомумән, киңрәк күңел белән, сабыррак акыл белән һәм ышаныч белән эш итәр кешеләр. Шулай булгач, Өркыя да ачуланмас, Әминә дә үпкәләмәс, иҗатта да колач җәеп эшләрбез. Теләгәнчә матур итеп, көчле итеп язарбыз!..

— Әйе, әйе, билгеле, шулай итәрбез! — дип мыскыллады Фоат шаяртып.— Тик аның өчен бәләкәй генә могҗиза кирәк: әйтик, шушы төн эчендә Гитлерның бөтен дивизияләре тараташ булып катса...

— Ә, беләм, беләм нәрсә әйтәсеңне,— диде Муса.— Анысы исәпкә керми. Без булмасак, бездән соңгылар шулай эшләр!..

Бу шигырьнең бәхәс кузгатуы Алишка әллә ни тәэсир итмәде.

— Юк, Фоат бераз купайта ул,— диде.— Өркыя үпкәләмәс тә, рәнҗемәс тә. Минем нәрсә әйтергә теләвемне аңлар: чыпчык күзедәй генә чәчәк күрсәң дә, таптап китмә, аппагым!.. Шул бит ул.

Әмма шигырьнең Мусада әйбәт тойгы калдыруы Алишны канатландырып җибәрде. Җылы сүз, мактау сүзе. Күзләреңә синең йомшак кына, нечкә генә зәңгәр ефәк урыйлар һәм, син, бишектәге бала шикелле, саф күңел, садә күңел булып каласың да куанычыңнан каядыр үрләргә, кулларыңны өскә суза-суза көлемсерәргә тотынасың... Алиш моны берничә көн шулай кичереп йөрде. Аннары килеп, алдагы «әдәби кичә»дә тагын бер яңа сатирик шигырен укыды. «Кайбер сызмалар» дип атала иде ул:

Язмыш җиле мине, яфрак кебек,
Кыш иленнән сөйрәп китерде.
Европаның урта бер җирендә
Үзенең ачы суын эчерде.
Тормыш тәҗрибәсен аз күргәнмен,
Белмәгәнмен бик күп эшләрне.
Күзләрем дә ачык күрәлмәгән,
Танымаган кайбер кешеләрне...
Өйрәндем мин хәзер күп гадәтләр,
Беләм инде хәзер нишләсен.

Иртүк торып, берни ашамыйча,
Ач карынга кофе эчәсен...
Икмәкне дә кисә беләм инде,
Үтәсеннән Берлин күренә!
Чыпчык борыны кадәр маргаринны
Пәке шуңа сылап өлгерә...
Өстә нинди матур кием хәзер!
Бөркет җәйгән үзенең канатын:
«Чукыйм, — дигән төсле, — йөрәгеңне!..»
Ят кешегә мине санаптыр...
Ә билемдә нинди гүзәл хәнҗәр,
Кара, ничек матур ялтырый!
Шул хәнҗәрне күргәч, ни сәбәптер,
Җөмлә тәнем бердән калтырый.
Бервакытны әнә шундый хәнҗәр,
Онытыптыр кайда тагыласын,
Төшкән иде минем мескен башка,
Алда тагы... ходай сакласын.
Тышкы яктан бөтен җирең җитте,
Үтеп чыкты язмыш киртәсен.
Тиз алыштыр, егет, йөрәгеңне,
Һаман иске йөрәк йөртәсең!..

Монысы Булатовның бик кәефенә килде.

— Шәп язылган! — дип, бот чабып көлде ул.— Ач карынга кофе, үтәсеннән Берлин күренә торган ипи телеме, чыпчык борыны хәтле маргарин, «йөрәгеңне чукыйм!» дип тора торган каракошлы фашист кием! — болар бит әле без «иректә» чакта шулай иде. Моны укыган кешеләр безнең ничек «рәхәт» яшәгәнне белерләр! Эх, егетләр, менә төрмәдә күргәннәрне дә бөтен фаҗигасе белән тасвирлап калдырасы иде бит!..

Шуннан соң Муса үзе язган поэмадан өзекләр укыды. Анда нәкъ Фоат әйткән хәлләр сөйләнә, шушы изге көрәштә үзләрен аямаган егетләр гәүдәләнә иде...

Алиш та, Фоат та сокланудан таңга калдылар. Нинди дә булса рәхмәт сүзе көчсез иде.

— Булмый болай булгач, егетләр! Туктагыз, мин дә сезгә шигырь укыйм,— диде Булат, һәм үзенең «чәк-чәк» килә торган почмагыннан нәрсәдер җәлт кенә эләктереп койка өстенә менде, аяк бөкләп утырып, баштан арык төрмәнең иске одеалын бөркәнде дә ниндидер музыка коралында селкенә-селкенә уйный башлады. Һәйбәт иде бу! Әкрен булса да матур чыга иде тавышы.

— Һа! Кубыз! Кубыз бит бу! — дип кычкырып җибәрде Алиш.

— Ах, хәйләкәр «Таз малай!» — дип көлде Муса һәм башына бөркәнгән одеалын тартып алды.— Кара син, нәрсә «мәчтирит» итеп яткан икән! Нигә аны качып уйныйсың?

— Тегеләр ишетмәсен дигән идем, йолкып алулары мөмкин.

— Курыкма! Алай гына бирмәбез,— диде Алиш.

Һәм алар, кубызчы каршына басып, Булат уйнаган сагышлы көйгә кушылдылар:

Безнең илләр кай якта дип
Кыр казыннан сорадым.
Кыр казлары гаңгылдашкач,
Бер утырып җыладым.
  Кыр казы Идел читендә,
  Бик ямансу, дуслар, чит илдә...

## V

Бу кичтән соң бер ун көн узгач, бөтен төрмә буйлап яңа бер хәбәр таралды:

— Союзниклар төньяк Франциягә десант төшергән!

— Инде Нормандиядә зур гына плацдарм да яулап өлгергәннәр!

— Каты сугышлар бара икән!

Җәй иде, июньнең беренче яртысы иде, тәрәзәләр бар да диярлек ачык иде. Ачмыйча мөмкин түгел, юкса пыяланы барыбер кырып төшерәләр. Аркылы салынган зур төрмә бинасының йөзләгән камераларындагы тонык гүелдәү шул ачык тәрәзәләр аша тышка бөркелә, һәр тоткынга ишетелә һәм аларның күңелләрендә әллә нинди яшерен өметләр уята башлады. Һәркем шул хакта гына уйлый: дөрес микән соң бу хәбәр? Көн дә бирелә торган немец газеталары бу турыда ләм-мим бер сүз әйтми. Чын булса, авызларына су кабып тора алмаслар иде бит?.. Алиш белән Булатовның күзләрендә яңа чаткылар уйный башлады. Муса да уйга калды: мондый көчле сугыш барган чакта дөнья вакыйгаларының кинәт кенә кая таба борыласын аңлап бетерүе дә кыен. Әгәр дөрес булса, әгәр, чынлап та, моңарчы тик ятулары һәм икенче фронт ачу турындагы вәгъдәләрен үтәмәүләре белән җелеккә тигән союзниклар шулай форсированный һөҗүм белән килә калсалар?.. Дошманның безне үтерергә өлгерә алмый калуы да ихтимал түгелме?..

Шул көннәрдән башлап һава һөҗүмнәре дә бермә-бер көчәеп китте. Берлин җире хәзер биеп йөргән поднос төсле тибрәнә, чайкала иде. Хәтта өске катлардагы тоткыннарны да төрмә базларына куа башладылар хәзер. Мондый вакытларда бик күп кешеләр белән очрашырга мөмкин була. Муса хәзер һәр көнне диярлек барлык иптәшләрен күрә, сөйләшә ала, хәлләрен сорый һәм яңа әйберләрен укырга бирә иде. Шул һөҗүмнәрнең берсе вакытында Әхмәт Симай аны капитан Русанов белән дә таныштырды. Бу горур тавышлы, сынмас холыклы мәһабәт егет беренче сөйләшүләрендә үк Мусага ошап калды. Икенче тапкыр алар күптәнге дуслар шикелле күрештеләр. Төрмә шартлары өчен шактый иркенләп сөйләшергә мөмкинлек булды. Русанов та аны күптән белгән дусты кебек кабул итте. Рушатовның һәм Кормашның аның хакында сөйләгәннәрен әйтте. «Молодец, үзең йомры, җиңел гәүдәле кыр бөркете кебек икәнсең!» — дип аркасыннан какты. Алар, фани дөнья хәлләренең бик тайгак булуы турында көлешеп, адреслар алмаштылар.

— Без барыбер котылабыз, нык булыгыз, егетләр,— диде Русанов.— Менә икенче фронт тагын бераз какшата төшсен әле боларны. Шушындый һөҗүмнәрнең төнгесе вакытында массовый качу оештырырбыз! Барыбер котылабыз! — дип, олы йодрыгы белән таш стенага сукты. Бу козгын оясы җимерелә хәзер!..

Йөгән күреп үсмәгән яшь атныкыдай ярсу йөрәге күкрәк читлегенә сыймый иде төсле аның. Ашкына, талпына, урсалана иде ул. Камерадамы, бомба базындамы — куркып тормый: «Широка страна моя родная!..» — дип сузып җибәрә.

— О, ферфлюгте, Русаноф! — дип, немец надзирателе килеп җитә, нәрсәләрдер такылдый-такылдый да китеп бара, ә капитан аның артыннан шул ук күкрәк тавышы белән:

— Капут! — дип кала. Кемгә капут, Русановның үзенәме, надзирательгәме, әллә... (соңгы вакытларда тоткыннар арасында «Фюрер капут!» дип кычкырулар да ишетелгәли башлады, алла үзе сакласын!), анысын немец артык төпченмәскә тели. Алар белән этләшмәвең яхшырак...

Икенче фронтның һәм һава һөҗүмнәренең шактый уңышлары турында бөтен дөнья матбугаты шауларга тотынгач, союзникларның самолетлары йөзләрчә мең листовкалар яудыра башлагач, немец газеталары һәм радиосы да, хакыйкатьнең канат-койрыкларын йолкып кына булса да, икърар итәргә мәҗбүр булды. «Чамасыз күп корбаннар бирү һәм техникасын югалту бәрабәренә дошман Нормандия ярларына десант төшерүгә ирешә...»

Төрмә тормышының бу көннәрә, су астындагы ярсу агым төсле, үзенең эчке гүелдәве, яңадан уянган өмет һәм теләкләре белән бик тиз узып

китте. Июньнең соңгы атнасы кергәндә, совет гаскәрләренең бөтен фронт буйлап искиткеч зур һәм куәтле һөҗүм белән, немецның барлык оборона ныгытмаларын ватып-җимереп, Берлинга таба ургылып килү хәбәрләре дә мәгълүм булды. Хәзер инде бөтенләй чаяланып киткән җәлилчеләр тиздән котылу хыяллары белән яна башладылар. Немецның рәсми сводкалары бер-ике томанлы җөмләдән башка бернәрсә дә әйтмәскә тырыша. Әмма төрмәгә каяндыр, нинди юллар беләндер, бөтенләй икенче төрле киң информация килеп керә. Егетләр һәр прогулкадан яңа хәбәр ишетеп керәләр: «Безнең танклар Минск шоссесе буйлап немецларның сөякләрен сытып узганнар. Туйга барган кебек, люкларын ачып, өченче тизлек белән җилдерәләр икән. Инде Орша, Борисов, Минск, Молодечна һәм тагын бик күп шәһәрләрне алганнар. Инде көнбатыш Белоруссияне узып, Польша җирләренә килеп кергәннәр. Ул плен, ул техника! Һич кенә дә сөйләп бетерерлек түгел икән!..»

Алиш камерада үз-үзенә көлеп утыра. Ни өчен икәнен бераү дә белми...

— Ник көләсең, дивана? — ди Фоат Булатов. — Әллә артык порция маргарин эләктердеңме?

— Эскәнҗә, — ди Алиш, һаман көлеп. — Эскәнҗә...

— Ансы нәрсә тагы? — дип гаҗәпләнә Фоат. — Мин ишетмәгән яңа сүз.

— Мин үзем дә белми идем аны, — диде Алиш. — Ә Казанда бер телче гел шул сүзне кыстырып сөйли иде. «Эскәнҗәгә эләксәң»... дип башлап китә. Сүзлекләрдән карадым, әмма мәгънәсен ул чакта бик аңлап бетермәгән идем, менә хәзер шул сүз искә килеп төште дә, фюрерне кызганып куйдым.

— Тапкансың икән кызганыр нәрсә!

— Юк, алай димә, кызганмаслык та түгел. Фюрер мескеннең каршысына ажгырып арысланнар килә. Чалбар төбен бүреләр талый, уң кулына Италия, Югославия тауларындагы киекләр ябырылган, баш очыннан каракошлар чукый. Кая керер тишеге юк бичараның! Менә нинди сүз икән ул «эскәнҗә»!

— Син, малай, философка әйләнеп барасың түгелме?.. — дип көлде Муса. — Шагыйрь дә булдың, һөнәрең һаман арта...

— Гитлер төрмәсендә күбрәк ятсаң, тау тишегендә гомер иткән борынгы хәкимнәрдән дә акыллырак булырсың!..

Көннәр шулай шау-шулы яңалыклар, өметле көтүләр белән уза бирде. Үлем хөкеме турында уйламый да башладылар һәм аны кайчан җиренә җиткерәчәкләре турында төрмә администрациясе тарафыннан да хәбәр ишетелми иде. Муса язды да язды. Дистәләрчә шигырьләреннән тыш, «Тоткыннар» исемле поэмасын да эшләп бетерде. Анда ул үзләренең көрәш һәм соңгы көннәрен сөйләп биргән иде. Акка күчерү өчен кәгазь кайгысы тагын килеп чыкты. Аңа капитан Русанов ярдәмгә килде. Немецлар аңа иркенрәк шартлар тудырган булып, аның белән уйнауларын һаман дәвам итәләр иде әле. Ул шуннан файдаланып Мусага кәгазь табып бирде. Русанов биргән кәгазьдән кечкенә генә кесә дәфтәре ясап, яңа язылган бөтен әйберен шунда теркәде. Шулай итеп, өченче дәфтәр дөньяга килде. Инде бу күңел кошын, йөрәк тавышын тагын ничек итеп киң дөньяга очырырга?.. Ә капитан Русанов акыллы сүз әйтә: «Үзегезнең дошман тылында ниләр эшләгәнегезне, тоткында ниләр күрүегезне ачыграк аңлатырга тырышыгыз, ди. Безгә тиз генә ышанмаячаклар, ди. Менә мин инде хәзер, шушы пленга эләгүдән башка бер гаебем булмаса да, яңадан особист була алмаячакмын...» — ди. Чынлап та, аларның һәркайсын илле иләктән уздырачаклар. Кешеләргә артык дәрәҗәдә күпертелгән ышанмаучылык, кирәкмәгән шик белән карау ничектер ленинча түгел кебек тоела. Кеше чын коммунист булса, иң элек үз вөҗданы, үз намусы алдында җаваплы ич. Ә инде нинди генә

авыр хәлләрдә дә үз намусына тап төшермәсә, ил һәм партия каршында да йөзе ак булырга тиеш анын!.. Шулкадәр авыр сугышны җилкәсендә күтәргән һәм соклангыч җиңү белән (ә моның шулай булачагы инде күренеп тора!) тәмамлаган совет кешесенә ныклап ышану, аның батырлыгы һәм тугрылыгына кер кундырмау, ихтимал, сугыштан соң изге бер принципка әйләнер? Әгәр шулай булса, яшәү бөтенләй күңелле булып китәр иде!..

Бу авыр уйлар Мусаны гына түгел, Алиш белән Фоатны да һәм башка егетләрне дә борчый. Алиш хәтта, тагын да тирәнгәрәк китеп, шушы дошман кулында һәлак булуын уңайлырак саный; исемем пакь булыр, балаларымның йөзе ак булыр, дип уйлый ул... Чөнки аны бит әле «ишан нәселе» дип йөртәләр иде.

Әмма хәзер аның бу күңелсез уйлары да артка чигенде, хәзер алар сугыш дәрте белән солдатча кызып киттеләр. Камерага Геббельснең «Филькишер...» газетасын кертсәләр, фронт хәбәрләрен җентеклиләр, һава алырга чыксалар да, иң элек фронт яңалыгын белергә тырышалар, әз генә алга китеш хәбәре дә аларга әллә ни хәтле шатлык бирә.

Шулай итеп, июль аеның да өч атнасы узып китте. Бу вакыт эчендә безнең гаскәрләрнең бөтен Белоруссия, Украинаны тазартып, Вильнюс, Каунас, Гродно, Брест калаларын һәм бөтен Литваны азат итеп, Польша чикләренә килеп басулары, кайбер урыннарда Көнчыгыш Пруссиягә якынаю хәбәрләре, икенче фронтның да шактый көчәюе безнең егетләрне бөтенләй канатландырып җибәрде. Бүгенме-иртәгәме үләргә тиеш кешеләр каршына кинәт кенә котылу, яшәү бәхетен тулы тустыганнар белән эчү куанычы килеп баскан иде. Бу изге минутлар шундый якын булып тоелды, гүяки тәүлекнең һәр яңа сәгате ул авыкны алып килер дә, бу каһәрле төрмәләр ишелеп төшәр һәм алар, шул җимерекләр арасыннан, җырлый-җырлый, урамга чыгарлар!..

Әмма тоткын язмышы аның хыялы буенча гына бармый, аның көтелмәгән үз капризлары да була икән. Шул көннәрнең берендә Тегель төрмәсенә дистәләп-дистәләп немец китереп тутыра башладылар. Алар арасында хәрбиләр дә, цивильныйлар да бар. Мусалар камерасына да икене китереп яптылар, алар беренче төнне идәндә йокладылар, чөнки өч кешелек тартмага яңа койкалар куяр урын юк иде. Шул уңай белән Булатов бер мактанып калды ичмаса:

— Карагызчы нинди почет безгә! — дип көлде ул. — Немец йоклый идәндә, без йоклыйбыз менә дигән чуен койкада!.. Әллә, мәйтәм, дөньяның асты өскә килгәнме соң?..

Мондый сорау белән төрмәнең бөтен иске тоткыннары баш ватты. Ләкин дөньяның асты өскә килеп җитмәгән икән шул. Бер өер немец хәрбиләре, Адольф абзагызның урындык астына хикмәтле «йомырка»лар салып, күккә — ходай янына күтәртергә уйлаганнар, шуның белән фатерландны хурлыклы җиңелүдән коткармакчы булганнар. Әмма барып чыкмаган. Гитлерның үзе түгел, «күләгәсе»нең ыштан төбе генә ертылып калган. Хәйләкәр икән, каһәр: нәкъ үзе төсле үк берничә күләгә тоткан. Ә теге пешмәгән полковниклар шуны да аера белмәгәннәр!

Бу хәбәрне безнең егетләргә яңа немецлар сөйләп бирде. Моны ишеткәч, бигрәк тә Әхмәт Симай сөенеп алды.

— Менә, күрдегезме, егетләр, — диде ул, — минем идея дөрес булган бит, ә сез тыймаган булсагыз, теге чакта ук эшен бетерә идем мин аның!..

— Дөрес булмаган шул! — дип көлде Фоат аннан. — Дөрес булса, менә бу как балык эфисәрләр монда тутырылмас иде!..

Шулай да мәгънәле иде бу хәл! Димәк, бу шомлы ояның үз эчендә дә чуалыш, таркалыш башланган. Күрәсең, пиратлар карабы озакламый диңгез төбенә сәфәр итәргә җыена... Эх, күрәсе иде шул көннәрне, тизрәк күрәсе!.. •

Тик ул көннәр алай тиз генә килеп житмәде. Иске тоткыннарның бер өлешен Шпандау төрмәсенә күчерәчәкләре мәгълүм булды. Җәлилчеләр дә шулар арасында иде. Бу хәбәрне ишетү белән Муса капитан Русановны күрергә теләде. Ул аңа үзенең өченче дәфтәрен тапшырмакчы иде. Чөнки аның котылып чыгуы бик ихтимал: ул Германиядә әшерен эш алып бармаган, үлемгә хөкем ителүе дә яңадан каралырга тиеш икән. Шуның өстенә аның тышкы дөнья белән дә элемтәсе юк түгел, һич югында ышанычлы кеше табар...

Әмма Муса ике көнгә дүрт тапкыр прогулкага чыгып та Русановны очрата алмады. Өченче көнне Әхмәт Симаевны күреп, дәфтәрен аңа бирде, ничек кенә булса да капитанга тапшыруын үтенде. Симай иртәнге прогулкадан керү белән, кинәт кенә «эче авыртып», төрмә амбулаториясенә китте. Анда да Русановны таба алмады, чират көтеп утыручы Михаил Колесников дигән егеттән сорашты. Бу Архангельск егете, элек немец теле укытучысы, нерв авыруы белән җәфаланып, еш кына амбулаториядә булгалый, Әхмәт белән дә күптән үк шушы әсәмияләрдә танышкан иде. Симаев Мусаның дәфтәрен иплэп кенә аңа төртте.

— Безне тиздән Шпандауга озатачаклар, — диде. — Син инде, туганкай, бу дәфтәрне ничек тә капитанга тапшыра күр, зинһар югалта күрмә. Мусаның монда язганнары бу. Безнең хәлләр шушы дәфтәрдә... Поэзиянең җәүһәре монда... Шуны исеңнән чыгарма!..

— Вәгазьләмә, — дип көлде Колесников, — бер сүз белән әйтсәң дә аңлаган булыр идем. Әлбәттә, тапшырырмын!..

Икенче көнне Колесников, Мусалар камерасы яныннан узганда, ишеккә беркетелгән яңа кәгазьгә күз төшерде. Анда бөтенләй башка фамилияләр күрде ул. Симайлар ишегендә дә шул ук яңалык иде...

## ДҮРТЕНЧЕ БАШЛАМ

### I

Андре Тиммерман белән Эмиль Мэйзонны да Шпандауга күчерделәр — Гитлерга багышланган шартлау җиле аларга да килеп тиде, күрәсең. Тоткыннар монда чамадан тыш шыплап тутырылган: бөтен җирдә ыгы-зыгы килү, өстәмә урыннар кору, бушату-күчерүләр бара. Кыскасы, элекке немецча төгәл тәртипләр тәмам югалган иде хәзер.

Монда күчүләренә өч-дүрт көн узганнан соң гына Андрены иртәнге прогулкага чыгардылар. Тар гына ишек алдында әллә нихәтле кеше бер-бер артлы басып йөриләр. Бу бәләкәй генә түгәрәкне Андре бернич тапкыр әйләнде инде, унбиш минут узып та бара, тиздән аларны кире кертеп бикләрләр. Тагын бер тапкыр әйләнә аламы — юкмы?..

Ул шулай тын гына атлап йөргәндә, ниндидер сызгырган сыман тавыш ишетте: «Всст... вссст...» Кемдер аңа сызгыра, игътибарын җәлеп итәргә тели шикелле. Ул ялт-йолт кына тирә-ягына каранып алды, тик бернәрсә дә күрмәде. Ә тавыш каяндыр якыннан гына, беренче каттан гына килгән төсле. Кем сызгыруы булыр соң бу?..

Андре шул көйгә, бернәрсә дә белмичә, һичкемне күрмичә кереп китте. Көн буе уйланып, күңеле белән әзләнеп камерада таптанды. Бельгиядән берәр таныш якташы микән, әллә болай гына, берәр нәрсә сорарга теләгән билгесез кеше генә булдымы?.. Әллә бу сигнал бөтенләй аңа булмагандыр, тик шулай тоелгандыр гына...

Ул, тыныч булырга теләп, йокыга ятты. Ни булса да иртәгә ачыкланыр. Яңадан да шул ук сызгыру ишетелсә, тәгаен аңа булачак һәм ул аны ничек тә табарга тырышыр. Ә кабатланмаса — аңа түгел... «Ә кабатланмаса?..» дип, күзләрен ачты Андре. Бәлки ул кешенең актык сызгыруы булгандыр? Бик кирәкле актык сүзен әйтергә теләгәндер? Бәлки аны төнләме, таңдамы... О, юк, булмас!..

Андреның йокысы качты. Аның колак төбендә: «Вссsucc.. вссст!..» дигән сәер аваз озак вакыт буена яңгырап торды. «SOS! SOS!»[1] дигән шикелле ишетелә иде ул.

Иртәгесен, прогулка сәгатен көчкә көтеп алып, Тиммерман плацка чыкты. Ул анда кемнеңдер ярдәмгә мохтаҗлыгына үз-үзен тәмам ышандырган һәм шул ярдәмне, мөмкин булу-булмавына карамастан, тизрәк күрсәтергә ашыга иде. Нәкъ кичәге турыга килеп җиткү белән, тагын шул сәер аваз кабатланды. Андре тиз-тиз генә тирә-ягына күз йөгертте. Төрмәнең беренче кат тәрәзәләре тар гына булып эчкә таба ачылган иде. Шул кысык ярыкларны ашыга-ашыга күзләре белән капшаганда, кинәт кенә Мусаның чал башын һәм йөзенең бер өлешен күреп калды. Я, хода! Менә кем авазы икән бу! Ә Тиммерманның бу хакта башына да килмәгән иде. Аерылышуларына ничәмә айлар узды, бөтенләй икенче калага җибәрелгән дустың яңадан Берлин төрмәсендә булыр дип кем уйлар?

Андре куанычыннан шул сулышта ук тәбәнәк тәрәзә каршына йөгереп килмәкче булды, ләкин агымнан аерылу мөмкин түгел иде. Мусага текәлгән күзләрен, «Сәлам!» дигән шикелле, әз генә елмайтты да түгәрәк буйлап китеп барды. Сөенә-сөенә әйләнеп, яңадан бу турыга килеп җиткәч, кинәт кенә бөгелде һәм ботинка бавын бәйләп маташа башлады. Әмма күпме генә вакыт бу? Җитмәсә Мусаның йөзен дә күрә алмый, тик пышылдап әйткән сүзләрен генә ишетә. Ә ул сүзләр — шул бөкрәйгән җирендә егылып үләрлек: «Суд булды... Озакламый баш киселәчәк...»

Андреның тез буыннары көтмәгәндә хәлсезләнеп киткәндәй булды. Шул урында җиргә чүгеп калмас өчен, ул үзен көчләп аякка бастырды, билен тотты һәм әлеге тәрәзәгә тагын бер карады да, агым койрыгына ияреп, кыйналгандай авыр адымнар белән китеп барды. Әлбәттә, бу очрашу аның җанын талап кына калды, ул ничек кенә булса да Муса белән яңадан күрешергә һәм иркенләбрәк сөйләшергә теләде. Уйлый торгач, җае табылыр сыман күренде: Мусалар утырган култыкның кайсы көнне душ керәчәген иптәшләре аша белешеп алды. Яңа немецлар килеп тулган төрмәдәге хәзерге тәртипсезлек һәм элекке усал надзирательләр урынына карт солдатлар йокымсырап утыруы аның бу хәйләсенә мөмкинлек бирде. Шул көнне, үзләрен саклаучы карт надзирательгә күптән юынмаганлыгын әйтеп һәм аны сигарет белән сыйлап, душка китеп барды. Анда өрәктәй ябык шәрә кешеләр мыжлап тора иде. Ун минут эчендә юынып чыгарга кирәк. Шулай да, ялт-йолт эзләнеп йөри торгач, сыек пар эченнән Мусаны табып алды ул.

— Я, нихәл соң, нихәл? — дип сорады Андре, түземсезләнеп.

— Шәп, — диде Муса, берни дә булмагандай көлемсерәп. — Башларны култык астына кыстырып кайттык. Барыбызны да үлемгә хөкем иттеләр...

Андре ни дә булса әйтергә сүз таба алмыйча торды. Әллә ниләр әйтер, бу айлар эчендә булган әллә нихәтле яңа хәбәрләр сөйләр һәм үзе дә күп итеп сораштырыр кебек иде бит ул. Булмады. Бу бәләкәй генә кешенең шундый олы тынычлыгы, хәтта шаян сүз табуы тагын тетрәтте аны. Шәп көлә бит! Башны култык астына... ди! Гүяки сүз аның хакында түгел, ә ниндидер кәҗә бәтие турында бара. Кылана дип уйларлык та түгел: ничәмә айлар бер камерада бергә утырган Андре яхшы белә: бар табигате шул! Нинди кеше соң бу? Аның кебек шулай тыныч һәм көлемсерәп үлемне каршылаган берәр батыр тагын бар иде микән дөньяда? Нигә Андре белми аны, нигә ишеткәне юк?..

Ун минут узды да китте, туйганчы сөйләшә алмадылар. Тагын очрашырга, һавага чыгуны ничектер бергә туры китерергә булдылар. Кие-

[1] Дингезчеләр билгесе: «Коткарыгыз! Батабыз!» дигәнне аңлата.

неп беткәч Муса аңа, пинжәк чабуыннан чыгарып, кечкенә бер кәгазь «бөти» сузды. Эмиль Мэйзон аша Алишка тапшыруын үтенде. Бу аның монда килгәч язган яңа шигыре иде... Душтан чыгу белән сакчылар ике төркемне ике тарафка алып киттеләр. Андре һаман шул уйларында булды. Әйе, уйланырлык та иде шул. Чөнки Андре дөньяда Чапай, Мулланур, Салават, Лазо шикелле олы батырлар барлыгын да, Зоя, Газинур, Матросов шикелле яшь лачыннар барлыгын да, «Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә, дәшми калмам Газраилне күргәндә дә» дип, табутыннан кул болгап барган Тукай булуын да белми иде. Күрәсең, Муса үзенең көнбатыш дустына да гүзәл исемнәр турында сөйләп өлгерми калгандыр...

... Аны, Фоат белән икесен, беренче каттагы камерага китереп яптылар. Алиш бу юлы алар белән туры килмәде. Камерада бер генә кеше бар иде. Өстендәге кителенә караганда, Италия солдаты булырга охшый. Билендә каешы, җилкәсендә погоннары юк, ялан баш. Төсе нәүмиз генә күренә. Мусалар инде төрмә йолаларына, андагы әрсезлеккә өйрәнеп беткәннәр иде, озак тартынып тормадылар, бу кешегә немецчалатып сүз куша башладылар. Алар шикелле үк немецча сөйләшә торган булып чыкты. Исеме Реньеро, ә фамилиясен тиз генә әйтеп булырлык түгел икән: Лангфредини, диде бугай. Сүз ялганып киткәч, яңа күршенең хәсрәтле язмышы да мәгълүм булды: солдат икән, Муссолини армиясендә хезмәт иткән. Союзниклар Италиягә төшкәч, немец гаскәрләре белән бергә аралашып сугышканнар. Һаман чигенүләр, җиңелүләр башлангач, Италия солдатлары арасында ризасызлык көчәйгән. Бер көнне Лангфредини дә әз генә кызмача баштан Гитлерны сүгеп ташлаган. «Үзен тотып асарга кирәк аның!» — дип ычкындырган булса кирәк. Шунда ук алып киткәннәр дә япканнар. Полевой суд аны үлемгә хөкем иткән.

Шулай итеп, Мусалар кыска гына сүздән дә күп нәрсә белеп алдылар. Димәкки, бу егет тә үлем көтә. Кем белсен, ихтимал, аларны бергә асарлар... Бу хәл таныш булмаган Италия егете белән ике татар егете арасын бик якынайтып җибәрде. Үз хәлләрен дә кыска гына сөйләп бирделәр.

— О, сез актык юлымның актык дуслары икәнсез! — диде Лангфредини, кул бирде. — Хуш килдегез, әйдә, бергәләп җиңелрәк булыр...

Бу егет аларга шактый тыныч сыман күренде. Үзенең тиздән киселәчәк гомере өчен артык борчылмый кебек иде ул. Муса белән Фоат сокланышып та алдылар хәтта, мактап куйдылар аны.

Италия егете китаплар да укый икән, артык борчылмавын шуннан ук белергә мөмкин. Муса аның урындыгында яткан китапны кулына тотып карады. Данте! «Илаһи комедия». Нинди сокландыргыч әсәр! Беренче тапкыр ул аның белән МГУ студенты чакта танышкан иде һәм шуннан соң аерылмас булып китте. Бу изге китапның битләрен ачып, рәсемнәрен карагач, күптәнге бер теләге исенә төште: шул студентлык елларыннан ук «Илаһи комедия»не татарчага тәрҗемә итә башларга кызыгып йөргән иде ул. Бу аның һичкемгә әйтмәгән яшерен теләге иде. Поэзиядә кирәгенчә тәҗрибә туплаганнан соң, бер дә ашыкмыйча гына, озак елларга сузылуыннан курыкмыйча гына, эшләргә иде аның нияте. Ләкин тотына алмады, үз иҗатын үстерү һәм татар операсын гизрәк барлыкка китерү кирәклеге аның бөтен вакытын йотты. Аннары инде... сугыш юллары менә монда китереп, стенага терәде... Тирән суилап куйды Муса. Нигәдер йөрәге чәнчешеп китте. Шундый чакта бер генә йотым салкын су яхшы була торган иде, юк икән шул, графин кертеп куймаганнар, хәерсезләр.

Ул, соңгы иләмсез уйдан тизрәк котыласы килеп, сүзне яңадан «Илаһи комедия»гә борды һәм: «Монда итальянча китаплар да бирәләрмени?» — дип сорады.

— Минем камерага бер католик рухание кереп йөри, патер Курытко, — диде Лангфредини. — Шуңардан сорап алган идем. Болай әйбәт сыман кеше күренә...

Патерның шундый фамилиядә булуы Мусаны сәерсендереп куйды: ничектер, немецны түгел, полякнымы яки украинлынымы хәтерләтә иде ул. Әллә юри патер булып, сер алырга йөрүче дини шпионмы, дип тә уйлап куйды Муса. Андыйларның да булуы ихтимал ич бу илдә...

Икенче көнне сәгать уннарда, кулына китаплар тотып, католик мулласы үзе килеп керде. Бу яңа кешеләр белән дә исәнләште, хәл-әхвәлләрен сорашты. Тавышында нindидер аталарча йомшаклык сизелеп калды. Аннары ике католик бергәләп нindидер догалар пышылдый-пышылдый, гыйбадәт кылдылар. Бу ретуал беткәннән соң, патер Курытко солдатны йомшак тавыш белән үгетли башлады:

— Син артык хафаланма, балакаем, гыйбадәтләреңне калдырма, ходага сыгынуыңны онытма, — диде. — Ул синең теләкләреңне ишетер... Мин синең өчен зур үтенеч язып югары прокурорга тапшырдым. Синең ул эшең хәмер һәм шайтан ярсытуы белән генә килеп чыкканлыгын, моның өчен бик үкенүеңне үз телем белән дә әйттем. Ихтимал, бөек хода аларның күңеленә миһербан салыр. Тел төпләреннән шулайрак аңлашылды...

Солдат аңа рәхмәтләр әйтеп кулын үпте. Шуннан соң рухани китәргә җыенды. Муса аңа сүз кушты:

— Патер әфәнде, юкмы сезнең мин укырдай бирәр китабыгыз?

— Белмим шул, балакай, миндә күбрәк дини китаплар гына... Ә сез католик түгелсез... Менә, әгәр укый белсәгез, Гетенең «Фауст»ы бар... Күрше камерада бер тоткын укыган иде.

— Бик яхшы, — диде Муса. — Мин үзем дә нәкъ Гете яки Шиллерне сорамакчы идем...

Патер чыгып киткәч, Муса тәрәзә каршына урнашты да «Фауст»ны укырга тотынды. Тар тәрәзә ишек алдына караганлыктан, камера шактый караңгы, ничектер, ерактан әз генә якты сарка торган җир асты куышын хәтерләтә иде. Тышта югыйсә августның аяз көне, әллә кайда, биш катлы төрмә башындагы зәңгәр күктә, нурлы кояш барлыгы да сизелә, тик нихәтле генә үрелеп карама, күкнең кул яулыгыдай кисәге дә, кояшның күзгә ватыгыдай бәләкәй кыйпылчыгы да күренми. Бары шунсы гына җайлы: ишек алдына һава алырга чыккан кешеләрне күреп торасың. Аларның уй һәм хәсрәтләрен йөзләреннән укыйсың. Әгәр шушы беренче катта булмаса, ул үзенең Андре дустын да очратмаган булыр иде. Алиш та теге төрмәдә бергә утырган Эмиль дустын шулай очраткан. Эмиль хәтта аның белән бер коридорда утыра икән. Алар һәркөнне диярлек прогулкада очрашалар, ә күрешмәгән көннәрдә Алиш аңа, бәләкәй генә кәгазь букчага тыгып, үзенә тигән ике сигаретны җибәреп тора икән.

«Ан Мэйзон Эмиль.

Целле — 122, абтайлунг — 9.

Фон Алишев. Целле — 130».

Алишның үз кулы белән ясалган нәни генә конверттагы шундый адрес буенча йөри торган бу «почта» дуслыкның күңел тибрәткеч бер билгесе иде...

«Фауст» эченә ныклабрак чумгач, Муса, икенче бер дөньяга күчкәндәй, әйләнә-тирәсен онытып җибәрде, тәрәзә артындагы хәрәкәт тә күренми, кешеләрнең аяк тавышы да, әкрен генә быдырдашуы да ишетелми кебек. Бу сокландыргыч әсәрне ул беренче тапкыр укыганда да таңга калган иде. Немец фольклорында әйтелгәнчә, «җен гыйльменә» бирелгән, «шайтанга иманын саткан» доктор Фауст турында күпме автор, күпме китаплар язмаган. Тик алар һәммәсе дә үлеп беткәннәр. Ә бөек шагыйрь тарафыннан иҗат ителгән мәңге эзләнүче, җирдә яшәүнең чын

мәгънәсе һәм гакыллы хикмәте нәрсәдә икәнен аңларга теләүче, бөтен табигатьнең, бөтен галәм йортының барлык серләрен ачарга омтылучы, шул максатына ирешү өчен хәтта иблискә җанын сатудан да курыкмаучы алхимик Фауст образы үлемсез гомер белән яшәп килә. Чөнки ул никадәр генә күкләргә омтылмасын, ахыр гомеренәчә барыбер җир кешесе булып кала. Һәм җир кешеләренең язмышын, бәхетен кайгырту — аны мәгълүм фәлсәфи нәтиҗәгә китерә:

«Тик шул лаек икән яшәү һәм иреккә,
Кем һәр көнне алар өчен чыга яуга!..»*

Көмештәй ап-ак чәчле Фауст тарафыннан әйтелгән бу сүзләр кайчандыр Мусага яшәү программасы булып яңгыраган иде. Менә, вакытсыз киселә торган гомеренең соңгы көннәрендә шул юлларны тагын укыды ул, тагын шул ук көч белән яңгырады һәм тагын яуга чакырды. Тик ана хәзер көрәш мәйданы юк инде. Ярсып ташланырга теләсә дә — мөмкин түгел...

Шуңа ачынып утыра торгач, күңел күзе гомер юлына борылды: гүяки ул да, үзенә күрә бәләкәй генә бер Фауст буларак, үткәннәренә йомгак ясый. Һәм Муса үзенең яшьлек көннәреннән ризасыз булыр сәхифәләр, вөҗдан газабы кичерер урыннар тапмады. Ул революцияне аңлый башлаган үсмер яшеннән үк, үз кулыннан килгәнчә, көрәшкә ташланды. Үз бәхете өчен генә түгел, башкаларны яктыга алып чыгу өчен дә көрәште. Күпме татар, казакъ, башкорт егетләрен һәм кызларын, комсомолга тартып, ирекле яшәү юлларын күрсәтеп бирде, күпмеләрнең кулларыннан җитәкләп дигәндәй уку йортларына кертте, күпмеләргә башка төрле ярдәм итте. Шул ук вакытта һаман балкып барган шигърият көче белән бу яшьләрнең моңын, кайгысын, бәхетен җырлады, үз халкының иреккә омтылышын күрсәтте. Әсирлеккә эләккәч тә, намусы һәм вөҗданы кушуы буенча мөмкин булмаган юлларны табып, үз җанын кылыч йөзенә куеп, тагын яуга ыргылды. Һәм ул, үзенең тугры дуслары белән бергәләп, байтак кына халык егетләрен мәкерле дошман җәтмәсеннән котылу бәхетенә ирештерде. Әмма никадәр үкенеч! Дошманны төп башына утыртып калдыра алмадылар, юл бик иртә киселде, максат тәгәлләнмәде...

Аның кулында хәзер бармак буе карандаш һәм уч төбедәй кәгазь кисәкләре генә бар. Моңарчы үзе дә белмәгән эчке бер куәт белән актык сүзләрен кайнар җыр итеп тезә ул. Тик барып кына җитсен, халкы кулына тапшырылсын гына иде!.. Алар үлсә, мин дә онтылырмын, яшәсәләр — мин дә яшәрмен...

Муса калын китапны әкрен генә ябып куйды. Ничектер шул да мәгънәле булып тоелды: мәңге эзләнүче, мәңге ашкынучы гомернең соңгы сәхифәләрен ябу шикелле күренде бу, һәм уй-фикерләре кинәт кенә үзләренең шул актык минутларына килеп тоташты. Аларның тоткын ителүенә инде бер ел тулып узды: тикшерүләр дә беткән, хөкем дә чыгарылган. Ниндидер формаль тәгәллекнеме, әллә бау чираты көтү көннәреме генә калган. Озак тотмаслар... Ничек булырга тиеш ул актык минут?..

Бүреләр бүлеп алгач, куй көтүе һичкая кача алмыйча, почмаккамы, урталыккамы тыгызланып өелә дә, куркудан тәмам коты чыгып, ярты үлек хәленә килә, бүре өеренең берәм-берәм буып ташлаганын көтә... Аларга да шулай мескен булып, җил белән авар хәлдә торыргамы?.. Ничектер югары итәсе иде бит ул актык минутны! Шул вәхшидән өстен кеше булып үләсе иде!..

Мусага бик моңсу булып китте. Аның кузгалган күңеле, юаныч таба алмыйча, һаман борсалана иде. Ул тәрәзә төбенең бер почмагына урнашты да күзләрен өскә юнәлтеп күк яктысын күрергә теләде. Шул ук уйларының дәвамы буларак әкрен генә җырлап җибәрде:

... Гомерем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып...

Булатов үз почмагыннан аның янына килеп басты, күзләренә карады һәм, җилкәсенә кулын салып:

Ник моңая болай батыр егет,
Нигә төшкән акбүз атыннан?
Кылыч болгап, дошман яуларына
Ник ташланмый юллар чатыннан?.. —

дигән булды, шаян тавыш белән.

Муса аңа сүрән генә елмаеп куйды. Кемне укыды ул, Фәтхи Бурнашнымы, әллә үзе чыгарганмы?..

— Юк, — диде Муса, — әллә ни моңаю да түгел шунда... Нигәдер күңел сызып китте...

— Кирәкми, малай, бирешмик әле шул каһәр суккан кайгыга! — диде Фоат, тагын да күтәренкерәк булырга тырышып. — Әнә, син күккә кара, анда кояш яктысы бар, аннан озакламый киек казлар юлы сузылып калыр... — Һәм ул, шушы сүзләренең дәрте белән, үзе дә югары караган иде, тик анда киек казлар юлы урнына ниндидер озын торба башыннан чыккан кара төтеннең салмак кына сузылып агылганы күренде... Һәм Фоат моның нәрсә икәнен кинәт кенә төшенеп алды да йөрәге жу-у итеп китте. Мусага бер сүз дә әйтмичә, артка чигенде, караңгы баскан чырае белән үз почмагына барып утырды. Шушы төрмәнең аргы читендәге крематорий морҗасыннан сузылган төтен иде бу...

Үз уйларыннан һаман арына алмаган Муса аны күрмәде, Булатовның кинәт яныннан китүенә дә артык игътибар итми калды һәм шулай моңнар эчендә утыра торгач, тагын әкрен генә җырлап җибәрде:

И мөкатдәс моңлы сазым, уйнадың син ник бик аз.
Син сынасың, мин сүнәмен, аерылабыз, ахрысы...

Каршындагы кайсыдыр камерадан тавыш килде:

— Эй, земляк, спасибо за песню! Вспомнил волжские берега... Откуда сам-то?..

— Казаннан! — дип кычкырды Муса. — Син кем соң?..

— Старик... Бакшанов... — дигән җавап килде.

Муса, сикереп төшеп, идәнгә басты, аркылы тимерләрне ике кулы белән сындырып ыргытырдай ябышып, тәрәзәгә үрелде: кайсы камерадан эндәшә икән? Beләсе иде, Бакшановның Толстойча йөзен күрәсе иде! Фоат та аның янына килеп басты. Ләкин алар һични күрә алмадылар. Муса, мөлдерәмә күзләре белән Фоатка карап, башын чайкады:

— Димәкки, ул да...

## II

Камерага тагын бер кеше кергәләп йөри иде әле. Ул ничектер үзен бик гади тота, ачык чырайлы, русчаны да бик табигый итеп сөйли. Шуңа күрәдерме камерадагылар аның белән бик тиз танышып киттеләр. Ул монда тылмач булып эшли икән, исеме — Пауль.

— Безнеңчә Павел була инде, — дип куйды Фоат, — ә отчествогыз бармы?

— Юк шул. Немецларда булмый ул...

Кергән саен Лангфредини белән итальянча, болар белән русча сөйләште. Үзенең яшьтән үк телләр белән мавыгуын, беренче сугыш вакытында ук хәрби әсирләр лагеренда тылмач булып эшләвен, унлап тел белүен әйтте. Бу сугышта да тылмач булган, тик каты яраланып кайткач кына тылда эшли башлаган. Аның сүзләре ничектер немец тәкәбберлеге белән куркәләнмәгән, ачу китергеч мактанчык та түгел иде. Шуның өстенә, бу шактый олы яшьләрдәге кеше, малайлар шикелле, иңбашында фотоаппарат йөртә. Әзме-күпме танышып алгач та: «Айн

момент», «Минуточку» — ларны кабатлый-кабатлый, рәсемгә төшерә башлады. Шулай итеп ул Лангфрединине дә, Муса белән Фоатны да пленкага «чылт»латып алды. Икенче керүендә өч бармак иллеседәй генә дүрткел кәгазьгә сугылган һәвәскәр фотоны үзләренә өләшеп чыгып китте. Ниндидер кызыклы кеше иде ул, эчкерсез сыман күренә иде. Муса аның белән шактый озак-озак сөйләшкәләп утырды. Үз хәлләрен дә кыскача аңлатып биргәч, Пауль бик гаҗәпләнеп, алар өчен кайгырышкан төсле булып куйды.

— Сез бит руслар түгел, кемнәр буласыз? — дип сорады. Муса татар икәнлекләрен әйткәч, бөтен дөньясын онытып, тел турында сораштырырга тотынды. Үзенең төрекчә әз-мәз сукалавын әйтеп, татарча өйрәтүне үтенде. Тегесе ничек тә монысы ничек?

— Эх, Пауль, майн һерр! — дип елмайды Муса. — Монда гына бездән нәрсә өйрәнә алырсыз икән соң сез? Мәктәбе бер дә подходящий түгел ич!..

Шулай да Пауль үз теләген кабатлады. Муса аңа татарның өч төрле әлифбасын язып бирде, аерым сүзләр өйрәтте. Пауль шуларны язып ала һәм икенче көнне ятлап килә торган булды. Бүген дә, алар прогулкадан әйләнеп керүгә, ишектә Пауль күренде һәм, үзенчә гади елмаеп, Мусага сабак тыңлатырга тотынды. Шулай аралары шактый якыная төшкәч, Муса аңа бер хат бирде. Вак кына гарәп хәрефләре белән дәфтәр битенең ике ягы да тулганчы диярлек язылган иде ул. Муса аны Паульнең үз күз алдында төреп, бәрәңге валчыгы белән генә ике төшеннән ябыштырды да:

— Үтенечем шул, — диде, — әгәр булдыра алсагыз, моны саклагыз. Бу хат билгесез дуска. Безнекеләр барыбер Берлинда булачагы хәзер көн кебек ачык инде. Шаять, моңа сез үзегез дә шөбһәләнмисездер? Менә ул чакта берәр татар солдатын яки командирын очратырсыз. Һичшиксез очратырсыз. Төсләреннән танымасагыз, сөйләшкәннәрен тыңлап белерсез, сезнең татарча сүзләр белүегез моңа ярдәм итәр. Хатны шуңа тапшырыгыз. Ә ул укып карар да тиешле юлына озатыр.

Пауль хатны алып кесәсенә тыкты. Италия солдатына таба бер карап куйды: тишмәс микән?..

— Мондый эш закон каршында ярап бетми инде бетүен, — диде Пауль, ярым пышылдап. — Әмма сезнең соңгы үтенечне кире кага алмыйм. Исән булсам, тапшырырмын. Мин пацифист кеше, хәрби дәртләрдән ерак. Минем дөньям — телләр. Шулай булгач, мин сезне дошман күрә алмыйм, сез минем өчен ирексез әсирләр генә...

— Ә сез минем өчен Германиянең хәзер сирәк очрый торган әйбәт бер кешесе, — дип көлемсерәде Муса. — Мин сезгә ышанам...

Кичке прогулкада Муса Андрены эзләп йөрде. Алар һавага чыккач очрашырга булганнар иде, ләкин һаман туры килешә алмадылар. Душта күрешүләренә дүрт-биш кенә көн булса да, ул аны сагынып китте, нишләптер бик күрәсе килде, сөйләшәсе күп кенә сүзләре бар кебек тоелды. Әмма эчендә аның әле үзе дә ачык икърар итәсе килмәгән бер теләк ята иде: соңгы тапкыр күрешеп калу... Ничәмә айлар бергә хәсрәт уртаклашкан иптәш бит, күрешми калмаска иде... Алиш очрады, аңардан сораштырды.

— Тукта, Эмиль монда, аннан сорап карыйк, — диде ул һәм, озак та үтмәстән, Эмиль Мәйзонны эзләп алып килде.

— Андре монда юк шул инде, — дип җавап бирде Эмиль. — Теге тинтәккә һөҗүм ясауларының бик күпләргә «файдасы» тиде: һич катнашы булмаган кешеләр яңа сроклар алдылар. Андрега да тагын биш ел каторга ябыштырып, үткән төнне Луккау лагерена озаттылар.

Мусага кинәт кенә бик яманcу булып китте. Ничектер күңел дөньясының бер почмагы кителгән төсле тоелды. Болай да терсәк борырдай җай булмаган тар ишек алды тагын да кысанрак булып күренде. Нинди-

дер таш баз төбенә охшый ул, биек стеналар өстендәге саф һава бу чокырга төшеп тә житә алмый торгандыр... Шулай итеп, ул үзенең бельгияле дусты белән күрешә дә алмый калды алайса. Кызу тотканнар... Нигәдер ашыгалар болар. Яңа корбаннарга урын кирәктер, күрәсең...

Ул инде актык түгәрәген әйләнә, надзирательләр сәгатьләренә караналар, тиздән команда кычкырырлар. Шул чагында аның беләгеннән кемдер килеп тотты. Муса ялт борылуга, каршысында озын гына буйлы, ябык кына кара чырайлы, көрпә сибелгән чәчле, өскә калкып калган зур күзле бер жеше аңа текәлеп карый иде. Икесе дә бер үк сулышта:

— Муса!

— Тулиян?! — дип, куанычны көчләп тыйган эчке тавыш белән кычкырып пышылдаштылар һәм кочаклашып алдылар.

Каһәр генә төшсен, немец кычкырып та жибәрде:

— Ауф Целлен! [1]

Төркемнең иң койрыгында калып, сүзләрне урталай өзә-өзә генә сөйләшеп, ишеккә таба атладылар.

— Син дә мондамени?..

— Инде бер атна...

— Моннан кая?..

Әрмән егете уң кулын муен астына аркылы куйды:

— Ампутациягә... Ә сез?..

Муса үз башын култык астына кыстырып күрсәтте:

— Чират көтәбез. Балта бушамый, диләр...

— Хәлләрегез ничек?

— Ал да гөл инде, Тулиян дускай...

Ул арада ишек төбенә килеп тә життеләр. Аерылышырга кирәк булды.

— Бүгенгә хуш, — диде Муса. — Иртәгә шушы урында көт. Иркенләбрәк сөйләшербез.

— Яхшы. Хуш...

— До завтра! — Икесе ике коридор белән китеп барды.

Муса Андре белән күрешә алмый калуына бик үкенгән иде һәм кәефе дә әйбәт түгел иде. Әмма шул ук вакытта икенче бер күптәнге иптәшен көтмәгәндә очрату һәм иртәгә аның белән иркенләп сөйләшәчәк булу аны куандырып жибәрде. Тик аның язмышы да, үзләренеке шикелле үк, кыл өстендә торуы гына көендереп куйды. Монда гел шулай инде: әз генә бер куанычың булырга өлгерми, шунда ук хәсрәт килеп баса. Шатлык — беравык. Хәсрәт — мәңгелек...

Ул камерага кергәндә Фоат кубыз уйнап утыра, ә Лангфредини аны бик кызыксынып карап тора иде. Кубыз күптән үк инде башка камераларда йөргәнлектән, Италия егетенең әле аны рәтләп күргәне дә юк иде, шуңа күрә бик гажәпләнеп, хәтта үзе дә чирткәләп карады. Шуннан соң Фоат аңа кубызның бик борынгы беренче уен коралы булуы, ә хәзер инде югалып баруы турында «лекция» укый башлады.

Озакламастан католик рухание килеп керде.

— Табигатьнең Бөек яратучысына гыйбадәт кылыйк, углым, — диде ул, исәнләшкәннән соң. — Жирдәге кузыларына тагын да күбрәк куанычлар индерсен!.. — Һәм алар, Лангфредини почмагына шәм яндырып, үз эшләренә тотындылар.

Картның әле генә әйткән сүзеннән Фоат пырхылдап жибәрә язды. — Яудырып кына тора инде ул куанычны, — дип пышылдады. Бигрәк тә, безнең төрмәләр өстенә, дөньяның яртысын басып алган фронтлар өстенә... Күрәләтә торып күзгә төтен жибәрә бит, чукынган...

[1] Камераларга!

Муса аңа бармак янады: шаулама, янәсе, үз белгәннәрен кылансыннар...

Гыйбадәт беткәннән соң Курытко әфәнде, ишетерлек итеп, немецча сөйли башлады:

— Ялгышып бәлагә дучар булган углым, Реньеро! Ярлыкаучы бөек Иисус синең күз яшьләреңне ишеткән булырга тиеш, ул җир түрәләренең күңеленә миһербан салды: алар синең үтенечеңне карап, үлем җәзасын уникe ел каторга хезмәте белән алыштырдылар. Син исән калачаксың. Син аны, тугры кузы булсаң, биш елда да тутырып чыга аласың!..

Лангфредини аңа башка сүзләрен дәвам итәргә мөмкинлек тә бирмәде: сикереп торды да руханине, нык куллары белән кочаклап, күкрәгенә кысты һәм яңакларыннан үбәргә теләде. Ләкин изге кеше белән болай солдатча тупас кылану ярамаячагын шул ук минутта аңлап алды булса кирәк, кинәт кенә идәнгә тезләнде һәм, Курытконың итәген, кулларын үбә-үбә, күз яшьләре белән рәхмәт укырга тотынды:

— О, Бөек хода тарафыннан җибәрелгән атам минем! Мең рәхмәтләр яусын сезгә! Җирдәге бөтен теләкләрегез кабул булсын, бәхет шатлык һәм байлык — сезгә үзләре ишек ачып торсыннар!..

Шулай да Фоат түзмәде:

— Фюрерне ялгыш сүккән бу егет... — дип пышылдады.

— Телеңне тый! — дип йодрык күрсәтте Муса. — Үлем яки яшәү — уен түгел. Ул бит бөтенләй икенче дөнья кешесе...

Почмакта гыйбадәт беткәннән соң да, әкрен тавыш белән озак кына итальянча сөйләшеп утырды тегеләр. Тик аннары гына Курытко әфәнде урыныннан кузгалды. Муса аңа «Фауст»ны китереп тапшырды һәм тәмле тел белән рәхмәт әйтте.

— Әгәр мөмкин булса, иртәгә миңа Шиллер әсәрләрен кыстырып килә алмассызмы? — дип үтенде.

Курытко әфәндеңең бу егетләр белән дә бер иркенләп сөйләшәсе килә икән, бик әдәпле, мөлаем күренәләр икән... Ә китапны ул иртәгесен, әлбәттә, алып килер.

— Баш өсте, әфәндем, — диде Муса. — Игътибарыгызга бик рәхмәт. Сез дә бик һәйбәт кеше күренәсез. Рәхим итегез, теләсәгез кайвакытта килегез, бик рәхәтләнеп сөйләшербез.

Патер чыгып киткәч, Муса Италия солдатын кайнар итеп котлап алды; Фоатны да шуңа мәҗбүр итте. Аннары: «синнән ярты тия болай булгач!» дип, көлешеп алдылар.

Ә Лангфредини аларга күп кенә яңалыклар сөйләде:

— Сезнекеләр анда бик котырып киләләр икән. Инде Румыниянең башкаласы Бухарештине алганнар. Румыния фюрергә каршы сугыша башлаган. Сезнекеләр хәзер Польша, Карпат, Венгриягә аяк басканнар. Чехлар бик каты эчке көрәш алып баралар ди. Төньяк Италия — минем туган ил! — Инде немецтан бөтенләй диярлек әрчелгән, хәзер Югославиядә каты сугышлар башланган. Ә Көнбатышта икенче фронт ярты Франциягә җәелеп бара икән. Немецның цивильни халкы бик борчылуда, куркуда, күп шөбһәләр эчендә яши икән хәзер... Патер миңа шуларны сөйләп утырды. Үзе дә бик пошына карт, — дип сүзен тәмамлады Лангфредини.

Алар өчесе дә куаныша һәм көлешә-көлешә йокларга яттылар. Муса белән Фоат күңелендәге өметләр, язгы кояш җылысын тойган күбәләк шикелле, тагын уянып, терелеп киттеләр. Бүген, гомумән, шактый ямьле генә узды көн. Нинди һәйбәт хәбәрләр. Димәкки, безнекеләр җир селкетеп килә! Озакламас, озакламас!..

Алар күңелендәге өмет күбәләге һаман канат җилпеде. Ул нишләптер ике катлы тәрәзә арасында төсле күренә иде, әгәр шул пыялалар тоткарламаса, тагын бераз гына җылыныр да, тирбәлә-тирбәлә әллә

кайларга очып китәр кебек тоелды. Кара әле син, ә: Лангфредининең үлемнән котылуы нинди шәп!

Ә җан тынычлыгына ирешкән Лангфредини инде күптән борынын чыйнатып йоклый иде. Муса белән Фоат сүзсез яталар, бер-берен йоклый дип уйлыйлар. Ләкин әле кичен генә ишетелгән яңа хәбәрләрнең якты дулкыннары күңел ярларына кагып уйныйлар, алар йокламыйлар иде. Төн караңгысында Фоатның уйлары эченә сыймастай кинәт зураеп, тәрәзә арасындагы өмет күбәләге күгәрчен хәтле булып китте. Ул, тынычлык таба алмыйча, як-ягына әйләнде, аннары чалкан ятты. Муса белән дә шундый ук хәл иде, ул да йөз тапкыр әйләнгәндер. Тик алар бер-беренә эндәшмәделәр. Икесе дә, туасы иртә белән үзләренә дә ниндидер олы куаныч киләчәген тойган кебек булып, таң алдыннан гына йокыга киттеләр.

## III

Ләкин алай булып чыкмады, тойгылар алдаучан да булалар икән... Төн урталарыннан соң, инде бөтен камералар авыр һәм хафалы йокыга талганда, Алишлар торган камераны шалтыр-шолтыр ачтылар да, Әхмәт Симаевны әйберләре белән алып чыгып киттеләр. Кинәт кенә сикереп торырга мәҗбүр булган кешеләр, ярым йокы аралаш хәлдә, үзләренең актык сүзләрен әйтергә дә өлгерә алмый калдылар. Әхмәт барысы белән дә кочаклашып чыкты да бүрек хәтле генә төенчеген алып ишеккә юнәлде.

— Хушыгыз, туганнар! — диде ул, әкрен тавыш белән. — Көрешмәсәк, бәхил булыгыз...

Бусагадан атлавына ике сакчы ике ягына басты. Артта калган төрмә надзирателе ишекне бикләргә җыенганда гына Алиш абайлап алды: димәк, әйберсе белән булгач, икенче төрмәгә алып киттеләр. Надзиратель карт солдат иде, бик үк әшәке немец та түгел иде, Алиш җавап өмет итеп пышылдады:

— Кайсы төрмәгә?..

— Плецензее, — диде немец һәм китеп барды.

Яңадан ут сүнде. Кешеләр, башта шушы хакта әкрен генә сөйләшеп, аннары уйланып ята торгач, яңадан йоклап киттеләр. Алишның гына йокысы качты. Шулай берәм-берәм төннәрен алып китеп, төрлесен төрле җирдә, төрле вакытта юк итәрләр микәнни?..

Бу хәл бик үкенечле, бик авыр, хәтта бик куркыныч булыр кебек тоелды аңа. Бер ялгызың. Уңга карасаң да буш, сулга карасаң да буш... Бер терәк тә юк янында... Аһ, хәтәр!..

Аның хәтта бөтен тәненә суык йөгерде, арка сөякләре чымырдап һәм шыгырдап киткәндәй булды. Юк, үләргә булгач, бергә үлүгә җитәме соң! — Як-ягыңда иптәшләрең булса, аларның култыгына кагыласың, аларның җылысын тоясың, аларның актыккы карашларын күрәсең, актык сүзләрен ишетәсең... Һәммәсе дә бергә була, бергә бетә... Күп җиңел җиңелрәк...

Ялгыз әнә ничек бит ул: кешенең татлы йокысын бүлеп керделәр дә суырып алдылар. Ул ут йотып, кая басканын, кая барганын белмичә, караңгы төн эченә чыгып китте. Плецензеегә барып җиткәнче, күпме газаплар кичерә инде ул. Соң ни өчен аны ул төрмәгә күчерәләр икән?.. Ул Остминистериумның «Винета» бүлегендә эшләгән иде. Алай дисәң, аларның «җинаять эше» бер төрле бит... Әллә калганнарны да шулай берәм-берәм шунда күчерәчәкләрме?.. Ә ул төрмәдә гильотина диләр, фашист балтасының үзе...

Шундый чишелмәс уйлар, чуалчык фаразлар белән таң атты. Августның салкынча җылы иртәсе килде. Дөньяның кайсыдыр ягыннан кояш чыгып, төрмәнең өске катларына якты сипкәне беленде. Алиш аны үз

авылларындагы сабый чак кояшы итеп күз алдына китерде. Әнә ул, Кама ягындагы уйсулыктан кып-кызыл булып, көлемсерәп килеп чыга да чиләкләрен мөлдерәмә тутырып чишмә суы күтәргән матур һәм оялчан кыз шикелле, сөйкемле генә юргалап авыл каршындагы үргә менеп бара. Менгән саен балкый бара, кайнар көлүе белән дөньяны куандыра бара. Бәләкәй Абдулла аның артыннан куып җитмәкче булып, аргамакка камчы соскан шикелле, түбәтәен ботына суга-суга, үргә таба йөгерә. Ә кояш һаман ерагая бара аннан. «Ярар инде, энекәш, иртәгә куып җитәрсең!» дигән төсле көлеп, аңа кул болгаган сыман күренә...

Кояш нурлары түбәнгәрәк катларга да кул суза башлады. Сасы, тынчу камераларда төн уздырган кешеләрнең тар гына тәрәзәләрне тизрәк ачып җибәргән тавышлары ишетелде, әз булса да саф һава суларга ашыга иде кешеләр. Шулар арасында Муса да үз тәрәзәсен хәзер генә ачып җибәргәндер кебек тоелды Алишка. «Алар да минем шикелле йокысыз чыктылар микән бу төнне?.. — дип уйлады ул. — Хәер, алар шул әле Симайны алып китүләрен белмиләрдер...»

Әйе, алар бу күңелсез хәлне белмиләр иде. Алай гына да түгел, кичәге куанычлы хәбәрләр һәм шуннан килеп туган өмет хыяллары дулкынында ярсынып ятканнан соң бик татлы (әгәр төрмәдә шул мөмкин булса) йокладылар да алар. Фоат бик матур төш тә күргән икән. Алтыдан ук сикереп торды да шул төшен тәмләп сөйләргә кереште.

— Кызымны күрдем, малай, төшемдә, Эсфирамны! — дип канатланып тотынды ул. — Шундый үскән, шундый әйбәт сөйләшә, чутылдап кына тора инде менә! Ә үзе чат минем төсле, ул күзләре, кашлары, борыннары, иякләре, көлүләре дисеңме, әйтерсең, калька белән күчереп алган! «Әтием, ник кайтмыйсың инде, дигән була, мин дә бик сагынам, әнием дә бик сагына», — ди, былбыл булып сайрый инде менә! Һу-у, мондый матур төшне беренче күрүем, сөенечтән башларым әйләнеп китте хәтта... Әллә исәннәр микән, дип уйлый башладым...

Муса аны елмаеп тыңлап торды. Мондый татлы төшләрне аның инде бик күп күргәне бар. Тик бу төнне генә күзләрен йому белән каршына килеп баса торган Чулпанын да, Әминәсен дә, ни өчендер, күрмәде ул.

— Әйбәт төш бу, — диде ул Фоатка. — Әйбәт төш күңелне күтәреп җибәрә. Хәерлегә юрыйк! Болай булгач, Эсфира янына тәгаен генә кайтабыз инде без. Кызың шулай сагынып чакыргач, кайтмыйча булмый, дускай...

Ул арада надзиратель килеп, шалтыр-шолтыр ишекне ачты. Лангфрединине, әйберләрен җыйдырып, икенче камерага алып китте. Фоат белән Муса исәнләшеп калдылар. Авыр булды бу.

— Яшисе кеше бит, — диде Фоат, — алар чыгып киткәч. Смертниклар камерасында тотмыйлар, күрәсең...

Муса эндәшмәде. Ул үзенең һәр иртәдә ясый торган зарядкасы белән мәшгуль иде. Озак та узмады, иртәнге кофе дигән болганчык су белән бер кабарлык каткан ипи кисәге һәм, Алиш язганча, чыпчык борыныдай маргарин, ике сигарет куеп чыгып киттеләр. Бүген бу «нигъмәтләр» ни өчендер иртәрәк китерелгән кебек тоелды.

Булатов әле һаман үзенең төшеннән суынмаган иде.

— Мин бу төштән соң аптырап калдым әле, — диде ул ахырдан. — Әллә, дим, җүләр әйтмешли, үз исәнлекләрен хәбәр итәр өчен кызым төшемә керде микән?..

— Тукта әле, Фоат, — дип көлде Муса, — бик ераккa киттең түгелме? Мистика була торгандыр ич бу... «Ходай кушуы буенча...» дип тә әйтерсең, бәлки?..

Фоат кычкырып көлде.

— Ну, табасың да инде, малай! Ходайның монда чуртым эше бармы? Интуиция нәрсә? Бәлки шуның көчедер? Ә бәлки... кеше бик теләсә, бик сагынса, бик күрәсе килсә, төшен дә шул рәвешчә күрүе мөмкин

бит. Бу минем көннәр, атналар, айлар, еллар буе кызчыгым белән сөйләшеп йөрүемнең төшкә әйләнүе генә дип карыйм мин.

— Ихтимал, — диде Муса. — Бу каһәр суккан төрмәләрдә ятып, көндез йолдыз күрә башласаң да һич гаҗәп түгел инде.

Кофе эчелеп беткән иде. Фоат тәрәзә каршына басып, бик тәмләп, бик кадерләп, төтеннәрен сары майдай эчкә йотып кына, сигарет суыра иде. Ишек тагын шалтырап ачылды.

— Нах Аусганг! [1] — дип кычкырды карт һәм китеп барды. Ишек төбенә чыгарга кушты, ләкин әйберләрен алырга әйтмәде... Муса белән Фоат, баскан җирләрендә катып калып, тиз генә бер-беренә карадылар.

— ?..

— ?..

Шундый сүзсез сорау иде ул карашларда,

Аннары Муса үзенең вак-төяк нәрсәсен җыйнаштырып, кичәге газетага төреп куйды, гүяки ул аны үзе белән алып китәргә уйлый иде. Монда килгәч язган берничә шигырен, әле дәфтәргә теркәп өлгермәгәнлектән, аерым кәгазьләрдә йөртә иде, аларны төреп кесәсенә тыкты, янадан алып карады, нигә кирәк инде болар, дип уйлады, ахрысы, сүтеп тигезләде дә үз койкасы турына стенага беркетелгән бәләкәй әрҗәгә салды. Күкрәк кесәсеннән әлеге Пауль төшергән рәсемен чыгарып, шул ук әрҗәгә, шигырьләре өстенә, стенага терәп куйды. Фоат та үзенең рәсеме белән кубызын шулай ук үз әрҗәсендә калдырды. Болар һәммәсе дә эшләнеп беткәннән соң ишеккә килделәр. Артларына борылып күз ташлагач, инде ияләшеп өлгерелгән бу шыксыз һәм караңгы почмак та ничектер ямьле булып, якын булып тоелды. Беравыкка бик моңсу булып китте... Коридордан кабат ишетелгән тавыш аларны уятып җибәргәндәй итте һәм алар, ике ятим шикелле җитәкләшеп, чыгып киттеләр...

Шыгырдап ачыла торган авыр һәм пычрак ишек төбенә инде барысы да җыелып беткән диярлек иде. Муса аларның һәммәсенә сүзсез генә кул биреп чыкты. Арада ике яңа егет тә бар икән. Муса аларны хәтерләп алды: берсе рота командиры Мифтахов, берсе взвод командиры Атнашев. Ләкин алар эләкмәгәннәр иде шикелле. Муса аларны бервакытта да төрмәләрдә очратмады. Башкалардан да бу егетләр хакында ишеткәне юк иде. Ул, бер генә секундка алар каршында тукталып, күзләренә карады.

— Безне соңыннан эләктерделәр, Муса абый, — диде бөдрә чәчле Мифтахов, куанычлы хәбәр әйткәндәй елмаеп. Ул үзе матур гына егет, ләкин ике катлы булып үскән бер казык теше көлгәндә-елмайганда авызыннан кинәт бәреп чыга да бөтен сөйкемлелеген җуеп ташлый иде. Шул тешен хәтерләптер, ахры, ул тиз генә авызын йомды һәм елмаюсыз гына өстәп куйды: — Инде Станиславка күчерелгәч, узган елның сентябрь актыкларында...

Муса да, Фоат та иптәшләре арасында Әхмәт Симайны күрмәделәр. Нәрсә, авырый микән әллә?.. Ул арада «кара козгын» килеп туктады. Арткы ишек ачылып, як-якка ике конвоир басты.

— Безнең персональ машина килеп җитте, дуслар, рәхим итеп, яхшырак урыннарны эләктереп калыгыз, — диде Булатов, һични юк кебек шаян булырга теләп. — Калсагыз, янадан утыра алмассыз...

Әмма берәү дә көлмәде. Һәркемнең йөзе түбән, күңеле сүрән иде. Муса белән Алиш бергә утырдылар. Урнашу ыгы-зыгысы арасында Абдулла үткән төнге хәлне әйтеп бирде.

— Гаҗәп, — диде Муса. — Ни өчен Плецензеегә? Ни өчен аердылар икән? Аңлый алмыйм...

[1] Тышка чыгарга.

— Сөйләшү! — дип кычкырды сакчыларның берсе, күзләрен акайтып. Хәтта автоматы белән дә янап куйды. Әмма бу машинадагы кешеләр андыйларны бик күп күргәннәр инде. Хәтта, кайчандыр җүләр булып, курыккан чаклары да булгалаган. Ә хәзер аларга барыбер. Өркетә алмыйсың... һәм җирән солдатның кабат җикеренүенә дә карамастан, үзара кайнар пышылдауларыннан туктамадылар.

«Кара козгын» озак бармады. Күп булса, унбиш-егерме минут вакыт узгандыр, кинәт кенә борылып, килеп тә туктады. Сакчылар эчтән бикләнгән ишекне ачтылар да җиргә төшеп ике якка баскач, тоткыннарны төшерә башладылар. Көн чалт аяз иде. Зәңгәр күктәге җете кояш күпме вакытлардан бирле төрмәдә саргайган кешеләрнең күзләренә килеп бәрелде. Кинәт алар сукырайгандай булып калдылар, күз алларында алтын биш тиеннәр уйный башлады. Кояшка артлары белән борылып, берәр минут күз йомгалап алганнан соң гына әз-мәз күрә башладылар. Аяк астына шакмак таш җәелгән, якында гына ике йорт. Тирә-якта кара чуен рәшәткә. Зур капкасы да шундый ук. Түргә таба балчыктан өелгән биек валлар сузыла. Араларында алты метр чамасы тигез урын кала. Түрдә һәм валларның ике ягында куе яшел агачлык. Нindидер бакчаны хәтерләткән матур гына урын бу...

Ул арада тагын ике җиңел машина килеп туктады. Аның берсеннән комитет мулласы Усман Ганиев белән профессор фон Менде килеп чыкты. Икенчесеннән бер оберлейтенант, бер фельдфебель һәм Пауль төште. Ул шунда ук Мусаларга таба атлады, дусларча кыяфәт белән елмаеп, аларга кул изәде. Ләкин Муса аның монда ни өчен килүен аңлап бетермәде. Әллә... яхшы кеше булган булып йөргән бу бәндә палачлык хезмәтен дә үтиме?.. Шуңа күрә ул аңа җавап елмаюы күрсәтмәде.

Ә Паульнең күңелендә икенче нәрсә иде. Җәлилчеләрнең монда җәзаланасын белгәч, ул тиешле башлыклардан бик үтенеп сорады: «Миңа да рөхсәт итсәгез лә. Шул кызыклы экзекуцине бер дә күргәнем юк...» диде. Аңа рөхсәт иттеләр. Пауль алдашты: аның моннан бер ел элек биредә булганы бар иде. Тик хәзер башлыклар алмашынганга күрә генә аны белмиләр. Бу урын Зеебург полигоны дип атала. Монда яңа алынган солдатларны төз атарга өйрәтәләр. Әнә ул валлар арасындагы тигез полоса дүрт йөз метрга сузыла. Аргы башында мишеньнәр утырта торган механизмлы «күпер» бар. Солдат шул мишеньне хәрәкәттә вакытта атып ега алырга тиеш. Ә моннан бер ел элек анда үлемгә хөкем ителгән рус әсирләрен тере мишень итеп бастыралар һәм солдатлар шуларны атып егалар иде. Хәзер дә шулай булыр микән, бу әйбәт егетләрне дә шулай мәсхәрә итәрләр микән? Әгәр шулай итсәләр, Пауль ничек тә фотога эләктереп калса иде!..

Мусаларны ике вал арасындагы бушлыкның эченәрәк алып киттеләр. Урталыккарак җиткәч туктатып, тезелергә куштылар. Уртага Муса белән Алиш басты, алар янына Гайнан Кормаш белән Фоат Булатов, Гариф Шабаев белән Габдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнев белән Фоат Сәйфелмөлекев, иң кырыйга Мифтахов белән Атнашев басты. Барысы да бер төрле алача кәфен кигән бу тоткыннар һәммәсе бер кешедәй булып, гәүдәләрен бөтен көчләре белән төз һәм горур тотып, култыклашып алдылар. Аларның болай торуында борынгы юнан сынчыларының оста куллары белән ясалган мәрмәр һәйкәлләрнең соклангыч мәһабәтлеге, үлемсез кешеләр батырлыгы бар кебек тоела иде. Пауль түзмәде, бер кулын күтәреп, «айн момент, айн момент»ны кабатлап, йөгереп килде дә төркемне тиз генә фотога төшереп алды. Аны, комачауламаска кушып, читкәрәк тибәрделәр. Оберлейтенантның баш изәве белән Усман мулла Мусалар каршына килеп басты. Ул, җомгага юнәлгән хәзрәт шикелле, башына ак чалма ураган, өстенә буй-буй аклыяшелле, кызыллы-күкле чапан кигән, кулына коръән тоткан иде.

— А я, мөселман кардәшләр! — дип башлады ул. — Бу дөнья фани, ахирәт бакый. Ихтимал, сез бу фани дөньяда кылган гөнаһлы эшләрегездән тәүбә вә истигъфар кылырсыз, хәзрәти хода каршына пакь күңел, саф вөҗдан белән барып сыгынырсыз...

— Сабыр итегез, Усман әфәнде! — диде Гариф Шабаев, ачулырак тавыш белән аның сүзен бүлдереп. — Юкка көчәнмәгез. Алла каршында тәүбә итәрлек гөнаһларыбыз юк. Ходалар белән эшебез дә юк, без аңа ышанмыйбыз да! Сез инде үзегезне кайгыртыгыз. Кайчандыр халыктан куркып качкан бай малае «мөгаллим абзый» ның безне үтерүчеләргә булышып йөрүе бик гыйбрәтле хәл... Ә без ак күңел белән, саф намус белән үләбез! Безгә сатлык суфыйлар кирәкми!..

Оберлейтенант, каты кычкырып, аңа сүзен бетерергә ирек бирмәде. Мулланы да артка таба чигереп җибәрде, егерме метрлар читтә басып торган солдатларына, ике бармагын күтәреп, искәртү командасы бирде.

Егетләр һаман шулай, бер кешедәй булып, солдатча җыенкы һәм горур булып, башларын батырларча югары күтәреп, басып торалар иде.

Бер кырыйга баскан профессор фон Менде бу татарларның шушы дәһшәтле минутта да үзләрен болай бәйсез һәм кыю тотуларына аптырап калды. Кара, нинди батыр сөйләнәләр? Кара, нинди эчке көч кайный аларда?.. Ә бит ул азиатларның соңгы минутта сыгылып төшүләрен, җиргә чүгеп елауларын күрер өчен килгән иде. Ул, төрки телләр белүче профессор, бу акылсыз дауга чыккан мактанчык егетләрнең, актык сулышта немец алдында баш иеп, фюрердән кичерү сорап ялваруларын ишетергә, шул кәмитнең шаһите булырга килгән иде. Ә монда бер тиенлек кызык та булмады. Әллә нинди кыргый, кеше аңламаслык фанатик болар!..

Һәм профессор, сулагай кулын селтәгәндәй, гамьсез адымнар белән машиналар янына китеп барды.

Тоткыннар аны хәтта күрмәделәр дә. Җәһәт кенә бер-беренә күз ташлашып, тагын да тыгыз култыклаштылар, гәүдәләрен тагын да өскә калкыттылар һәм Муса белән Гайнан кинәт җыр башлап җибәрде. Шунда ук, алдан сөйләшенгәнчә, башкалар да кушылды. Ниндидер үзәк өзгеч моң белән, күңелләр түренә җыелган актык көч, актык давыл белән, һәрберенә балачактан ук газиз булган сүзләр яңгырады:

И мөкатдәс моңлы сазым, уйнадың син ник бик аз.
Син сынасың, без сүнәбез, аерылабыз, ахрысы.
Без үләбез: синең өчен җан аямый яулашып,
Сау бул инде, и туган җир! И өметләр татлысы!..

Пауль исе китеп тыңлады моны. Җыр тавышы ишетелгәч тә, әллә «Интернационал»мы? дип уйлаган иде ул. Юк, башка җыр булып чыкты. Аның мондый моңлы, мондый көчле аһәң белән, сагыну һәм өмет тулы тавыш белән яңгырый торган көйне ишеткәне юк иде. Сокланды, тетрәнде ул. Әле генә кул селтәп киткән профессор да хәйран калып кире килде. Габдулла Тукай дигән татар шагыйренең бу юллары таныш иде аңа. Әмма аның мондый дәһшәтле куәткә ия булып, үлем кайгысыннан өскә күтәрелеп, җиңүчеләр авазын яңгырата торган җыр булып китү мөмкинлеген белми иде ул. Карт немец әрле-бирле йөренде, калтыранып йодрыкларын кысты, тизрәк туктатасы килде, аның күз алдыннан кинәт мең-миллион гаскәрнең шушы җыр белән өстенә килүе һәм үлем шәүләсе уйнап узды.

— Ауфһерен! [1] — дип кычкырды ул, түзә алмыйча.

Төркеме-төркеме белән кеше үтерүдә тәҗрибәсе зур булган оберлейтенантның да ачуы килде. Бу кире беткән тартареннар һаман үзлә-

[1] Туктатырга!

ренчә кыланалар. Әле берәүнең дә аның каршында мондый тетрәнмәс тимер стена булып, теләсә нәрсә сөйләп торганы юк иде. Ә болар янәсе, култыклашкан килеш бер көч булып, җир селкетеп авачаклар, бергә үләчәкләр. Туктагыз әле өрәкләр, сез теләгәнчә булмас ул!

Һәм ул, палач командасына борылып, башта уң кулының, аннары сул кулының имән бармагын күрсәтеп, команда бирде. Ату тавышлары яңгырады. Төркемнең ике кырыена баскан Атнашев белән Мифтахов егылды. Команда тагын кабатланды: Сәйфелмөлекев белән Хәсәнев егылды. Аннары... Шабаев белән Батталов егылды, аннары... Кормашев белән Булатов егылды, аннары... Алиш егылды... Оберның кәефе килде: барыбер бергә үләргә ирек бирмәде ул!..

Муса бер үзе басып калды... Аның тирәсендә яткан иптәшләре төрле рәвештә егылганнар иде. Кайберләренең чәчләре тузгыган, кайсыныңдыр бер күзе йомылмый калган, кайберләренең аягы-кулы туры түгел. Һәммәсе дә аңа карыйлар кебек тоелды. Муса, үзен нәрсә көткәнен дә онытып, тешләре шыкырдаган тынычлык белән алар өстенә иелде. Алишның кулларын күкрәгенә куйды, яңагындагы кан тамчысын учы белән сөртеп, маңгаеннан үпте. Бер генә тыныш аңа карап торды. Аннары Кормаш белән Фоатның чал чәчләрен йөзләреннән сыпырып куйды. Сәйфелмөлекевнең аягын рәтләде, Батталовның гәүдәсен турайтты...

— Җан дусларым!.. дип йөрәге елый иде аның. — Бәхил булыгыз...

Оберлейтенант боларның һәммәсен дә көлеп карап торды да кинәт тагын нигәдер ачуы килеп:

— Ауфштеен! — дип кычкырды.

Муса ашыкмый гына турайды. Якты күккә күзләрен күтәреп кояшка карады, кулларын да шунда сузды. «Тукта, кояш, мин дә синең янга... Очыйк, ерак очыйк бу җәһәннәмнән!..» дигән кебек тоела иде ул.

Соңгы тавыш яңгырады... Муса әкрен генә, бер дә теләмәгән кебек кенә, артка каерылып, чалкан егылды. Әле йомылып өлгермәгән күзләре югарыга юнәлде. Әле генә яп-якты булып та, инде караңгыланып килгән күк йөзендә йолдызлар мириадасы җемелди иде. Кайдадыр якындагы болында гына нindидер бик матур тавышлы кошлар сайрый иде, аппак күлмәк киеп, алтын чәчләренә зәңгәр тасма бәйләгән Чулпан шул болында чәчәкләр җыеп йөри иде... Тиз-тиз караңгы төште, йолдызлар сүнде. Чулпан да югалды. «Әтием!» — дигән тавышын тик бер генә тапкыр ишетәсе килгән иде аның, никтер ишетә алмыйча калды...

*Бетте.*

---

*Гамил Афзал*

## Моң

Урман буйларында сары юрган,
Галиябану монда арыш урган.

Чәчәк исе килә тирә яктан,
Зөлхәбирә монда печән чапкан.

Ачык зәңгәр һаваларга карап,
Тау битендә утыра ялгыз нарат.

Дастан серен сөйли җилләр килеп,
Таһир-Зөһрә йөргән җирләр кебек.

Көтү үткән тугайларга тулып,
Минем моңым агыла томан булып.

## Онытыма хат

Томан булып күтәреләм иртән,
Һәм чык булып төшәм кичләрен.
Тел шартлатып
Карап йөрим читтән
Онықларның кырган эшләрен...

Бөтен тирә мәрмәр, пыяла, чәчәк,
Хуш бакчалар белән бизәнгән
Матур заманнарда яшәячәк
Онытыма сәлам җибәрәм.

Исән-таза гына ятасызмы,
Сәламәтме бала-чагагыз!
Без әбиең белән дөнья артыннан
Чабабыз да һаман чабабыз.

Мин күп белмим, лектор сөйләмәсә,
Син яшәгән заман хакында.
Үзең белән илне бизәп яшә,
Үзең белән җирне матурла!

Фараз кылам: сездә космонавтлар,
Ракеталар белән күк тулыр.
Җанга куәт биргән ак канатлар —
Шигырьләр һәм җырлар күп булыр.

Сез шагыйрьләр булып туарсыз да,
Шигырь белән буа буарсыз.
Карап карыйк,
Безнең китапларны
Кайсы шүрлекләргә куярсыз?

Бабайлардан танавыңны борма
Шигырь мәйданында ярышта.
Айга менеп Тукай җырын җырла,
Такташ шигырен укы Марста!

Мин йөземне борып сезнең якка,
Тәмле-татлы уйга талырмын.
Каберемә басып киткән чакта
Табаныңны үбеп калырмын.

## Әрем

Тәкәбберләр чәчәк иснәп йөрде,
Тәгәрәшеп бал-май эчендә.
Язмыш көлеп миңа әрем бирде,
Рәхмәт инде әрем өчен дә!

Әрем телле булдым әрем татып.
Телемдәге әрем өчен дә,
Салкын көздә
Сары чәчәк атып
Әрем үссен каберем өстендә.

### УДМУРТ МӘКАЛЬЛӘРЕ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘРЕ

Илен оныткан кеше гомерлеккә адаша.
Халык гомере — агым су, ә аккан су — матур ул.
Энҗе — тауда, акыл — халыкта.
Халык бердәм алынса, күлне күчерә ала.
Атаң улы гына булма, Ватан улы була бел.
Кешегә ышанмаганның үзенә ышанмыйлар.
Тирән диңгез төбеннән дә өскә чыга дөреслек.
Дөреслекнең бер юлы бар, ә ялганның — мең төрле.
Бөтен нәрсә картая, тик дөреслек мәңге яшь.
Күпме генә өрсә дә, эт тавышы тау ишми.
Бензинны яшереп куйсаң да, исе борынга бәрә.
Йөреп торсаң — мүкләнмисең.
Елганың да үзәне үзгәрә.
Тик бер тәрәзәдән карап бөтен урам күренми.
Юлны тормыш үзе күрсәтә.
Үз күләгәсеннән ары беркем дә китә алмый.
Юл алга алып бара, ә тел илтеп җиткерә.
Телне кимсетсәң, йөрәк хурлана.
Туган телен онытнан—туган анасын белмәс.
Йөрәктән чыккан җылы сүз өч кыш буе җылытыр.
Тел сөяксез, уй төпсез.
Сөйләшергә тел кирәк, яратырга җан кирәк, эш белергә аң кирәк.

## Роберт Әхмәтҗанов

### Лирик экият

Әсин гүя горур болан кызы,
Йөгереп уздың язгы юлларны.
Минем гомер килә синең эздән
Ерып чыга ташкын суларны.

Мин бу ярда торам. Син, яз кичеп,
Җәйгә кердең. Кошлар иләнә.
Җәйгә керәм. Анда гөлләр яна,
Иркәләнеп синең җиләнә;

Коя анда синең яңгырларың,
Ак болытлар коена күлләрдә.
Ул күлләрдән миңа бер йотым юк,
Сиңа зарыгып янган көннәрдә.

Җитеп булмый сиңа. Толымыңнан
Ташлыйсың да алып тарагың,
Эзләреңдә шаулап урман калка,
Карурманнар каплый араны;

Кызыл тарак төсле, юл өстендә
Янып тора көзге урманнар.
Көзгә керсәм инде — көзне уздың:
Арада — кыш,
Аера бураннар.

Язга керәм. Җиттем, дигән чакта,
Әйтерсең лә, көзге ташладың:
Ялкынланды кинәт язгы күлләр,
Елгаларның ярдан ашканы
Юлны бүлде...

Тагын килеп җиттем
Әфсенләгән утлы сызыкка...
Еллар аша сине эзләп барган
Чакыру тавышым җәелә офыкка.

● ● ●

Каеннарны үт тә, сугыл миңа.
Күңелем әле утсыз йорт сыман.
Анда бар да синең җыр шикелле
Исемеңне көтә, юксына.

Син кер анда. Калдыр бусагада
Икеләнү тулы уйларны.
Син кер анда. Ут ал күзләремә,
Уз, тәртипкә китер дөньямны.

Анда бар да синең кулны көтә.
Үз итеп йөр. Үз ит, тарсынма.
Утлар кабыз. Чыгар гөлләреңне
Коеп яуган яңгыр астына.

Бар да синең якты эзне саклый,
Син кагылган әйбер кузгалмый.
Ак мендәрдә синең җылың тора,
Гөлләреңнең төсен көз алмый.

Бусагада синең адымнарың,
Тоткаларда җиңел кул эзе.
Шәүләң йөри. Саклый пыялалар
Еллар җуймас ике йолдызны...

Күңелем — бер йорт. Аңа калдырып кер
Икеләнү тулы уйларны.
Син йөр анда, ут ал күзләремә,
Уз, тәртипкә китер дөньямны.

## Җирдә июнь

Иртән,
әле син йоклаган чакта
күкрәгеңә тартып ак юрганны,
дөнья рәхәтләнеп мунча керде,
яңгыр коендырды газоннарны.

Җир парлана. Җирдә яфрак исе —
Иделемнән диңгезләргә чаклы.
Җир чабынды кояш ләүкәсендә,
җилкәсеннән гөрләвекләр чапты.

Йөрде күкрәү июнь күге буйлап,
күкрәп йөрде түбән регистрда;
офыкларга китеп юашланды,
сөю булып керде минем җырга.

Тәрәзә ачтым. Ак болытлар оча.
Өй түремдә җил дә юкә шавы.
Җир шундый яшь! Җирдә июнь тора —
мәхәббәтен чатта көткән чагы...

Иртән,
әле син йоклаган чакта,
мин
бәхетебезгә
чират алдым.

● ● ●

Кар астында зәңгәр автоген
чаткысыдай, чәчелеп, нурланып
язгы күлү тора. Беренче
күлүе бу язның уянып;

Кар астына төшкән язгы ут —
карындагы язгы яралгы;
ташкыннарның гомере шушында
килә генә әле яралып;

Елгаларның башы шушында,
һәм диңгезләр шуннан юл ала.
Җыена сабый, гүя десантчы,
ташланырга олы дөньяга.

*Галимҗан Латыйп*

## Озата һәм каршы ала

Кайчан кермә
Вокзалларга
Корт иледәй кайнап тора.
Кабул итми кешеләрне
Дәрәҗәгә
булеп-булеп
Сайлап кына.

Ял алды юк.
Ял көне юк.
Бәйрәм дә юк вокзалларга.
Берәү килә,
Берәү китә,
Күз яшьләре кабатлана.

Көн дими ул,
Төн дими ул,
Яз ни,
Көз ни,
Кыш ни аңа.
Йөз чөерми беркемгә дә
Озата һәм каршы ала.

Сеңдергән ул буй-сынына
Шатлыкларны,
Кайгыны да.
Ничә тапкыр туры килде
Якыннардан аерылырга.

Үпте солдат нечкә билен,
Кысып-кысып,
Суырып үпте.
Иреннәрнең кайнарлыгы
Табаннарга кадәр үтте.

Китте солдат,
Ерак китте.
Күтегез дип
Кулын болгап.
Калганнарны моңсу итеп,
Тәгәрмәчләр китте җырлап.

Дәһшәтле авыр көннәрдә
Җир сыналды,
Ил сыналды.

Ир сыналды.
Баһадирлар
Каннар коеп,
Җаннар биреп
Тотты авыр фронтларны.

Уйналды хәрби маршлар,
Яңгыратып тирә-якны.
Күктә кояш,
Йөзләр якты,
Дан казанып солдат кайтты.

Кайтты тыныч көнгә солдат,
Мәхәббәткә сусап кайтты.
Шомлы уйлардан күңеле
Бөтенләйгә бушап кайтты.

Каршылады якыннары,
Каршылады шул ук вокзал.
Ләкин менә кайберәүләр
Төшмәделәр вагоннардан.

●●●

Пермь төрмәсе алдында Декабристлар бакчасы бар.

Атна түгел,
Айлар үтеп китте,
Этап әле чыкмый Себергә.
Уйлыйлармы әллә тоткыннарны
Себердән дә ерак сөрергә.
Себер юлы авыр, озын икән,
Ә күпмесе аның үтелде!
Юллар,
Юллар кая алып китмәс,
Декабристлар шуны үтенде:
Рөхсәт итегез агач утыртырга,
Бер истәлек булсын калганнарга.
Күләгәсе аның ярап куяр
Юлдан килеп,
Арган-талганнарга...
Кая инде сораганны тыңлау,
Үрә торды чәче түрәнең.
Агач имеш,
Төрмә каршысына,
Үстермәсләр иде үләнне.

Алар тагын,
Тагын сорадылар:
«Рөхсәт итегез агач утыртырга!..»
Һәм ул сорау таләп булып үсте,
Әверелде аннан көчле җырга.
Җырлый төрмә,
Бар тоткыннар җырлый,
Декабристлар белән бергәләп.
Түрәләрнең мие шартлар кебек,
Күз аллары — утлы түгәрәк.

Туктаталмый жырны янаулар да,
Богаулар һәм тимер чыбыклар.
Жыр дигәнең утны-суны кичкән,
Сөргеннәрдә йөреп чыныккан.
Ахыр чиктә
«Рөхсәт» дигән сүзне
Таләп итеп алды тоткыннар.
Әкренләп агачларга күчте
Жыр дигәнең казна йортыннан...
Шылдыр-шылдыр,
Шылдыр-шылдыр.
Декабристлар күптән киттеләр.
Яшь агачлар яшел яфрак ярып,
Россиянең,
Иске Россиянең
Яңаруын хәбәр иттеләр.

## Ай үтә, еллар үтә дә

Ай үтә,
Еллар үтә дә
Кайтасың тагын урап.
Тауларым, урман, кырларым
Сәламләп каршы алалар,
Һәммәсе мине зурлап.

Чакырды еллар буена
Гел килеп торган хатлар,
Чакырса,
Чакырмаса да
Сагыныла туган яклар.

Сагыныла!
Сагынмый яшәү,
Мөмкин дә түгелдер ул.
Сагынмый торган көнелләр
Өметсез көнелдер ул.

Салды да кабык бишеккә
Үстерде безне авыл.
Ә жирдән калкыр вакытта
Кузгалды утлы давыл.

Кая ул шикәр дигәнең,
Кая ул сөтле чәең.
Кузгалак ашлары белән
Үткәрә идек жәен.

Ләкин без эчләр бора дип,
Һич шыңшып еламадык.
Әләксә күмгән бәрәңге,
Башканы сорамадык.

Кая ул хәзерге байлык,
Кая ул асфальт юллар.
Кая ул кичке якларда
Электр янган урам.

Әй заман!
Бәхет дигәнең,
Әкияттән алда чаба.
Бу бәхет каян икәнне
Белерме бала-чага!

Чакырды еллар буена
Гел килеп торган хатлар.
Чакырса,
Чакырмаса да
Сагыныла туган яклар.

*Гәрәй Рәхим*

# ЛИРИК ПАРЧАЛАР



## Песнәк

Бәхәсләшмим. Яз җырчысы дип сыерчыкларга сокланган, табигатьнең сайрар патшасы дип сандугачларны мактаган кешеләр белән бәхәсләшмим. Тик мин бүген нәфис каурыйлардан һәм гүзәл сайраулардан мәхрүм булган песнәкне мактыйм, шуны җырлыйм.

Сыерчыкларның канатлары да нәфис, сайраулары да гүзәл. Тик сыерчыклар сайраган апрель көннәренең түбәләрдән яуган тамчы яңгырлары да, урам буйлап бөтенесе бер якка чапкан көмеш гөрләвекләре дә бар.

Ә менә февральнең салкын бер иртәсендә тәрәзә рамыгызга килеп кунган песнәкнең нечкә аваз белән чыелдап куюын ишеткәч, сезнең күңелегездә быелгы беренче яз дәрте кузгалып китә. Ә бит әле сез бүген генә, тәрәзәдәге боз абагалар аша, айлар буе һаман бертөрле булулары белән күзләрегезне арытып бетергән кар көртләрен күзәтә идегез. Әле язга кадәр тагын салкыннар да, бураннар да булачак. Ләкин шул тәрәзә рамыгыздагы песнәк тавышын ишеткән көннән соң инде сездә быелгы яз дәрте сүнмәячәк.

Миңа калса, салкын февральдәге песнәк чыелдавы җылы апрельдәге сыерчык сайравыннан ягымлырак! Чөнки песнәк яз дәртен бураннар арасыннан эзләп ала!

Сандугач — табигатьнең сайрар патшасы, ләкин салкын яңгырлар көн буе ялангач ботакларны тараган, кайчандыр эре чәчәкләр күтәреп торган гөл сабаклары соргылт курай гына булып калган көзге көннәрдә инде сандугачлар да тыналар.

Анның каравы, тәрәзә каршыгыздагы шәрә ботакта әле яңа гына авылга килгән шул каралы-сарылы песнәкне күргәч, сезнең күңелегез шатланып куя: «Табигать әле бөтенләй үк үлмәгән икән...»

Ә песнәк үз бәясен ничек кадерләп саклый белә! Ул бөтен кошлар безнең якларга кайткан яз һәм җәй көннәрендә кеше күзеннән аулак булган урман чытырманнары арасына кереп яшеренә. Әйдә, көз көне авылга кайтыр әле. Матур җирдә ямьсез булып яшәгәнче, ямьсез җирдә матур булып яшәвең мең артык!

Бәхәсләшмим. Яз җырчысы дип сыерчыкларга сокланган, табигатьнең сайрар патшасы дип сандугачларны мактап җырлаган кешеләр белән бәхәсләшмим. Тик мин бүген нәфис каурыйлардан һәм гүзәл сайраулардан мәхрүм булган песнәкне мактыйм, шуны җырлыйм.

## Бөре тышчасы

Урман. Кояш куе ботаклар арасыннан озын нур-кылычларын сузган. Күзләрне чагылдырып ялтыраган нур-кылычлар талгын җилдә тирбәләләр, чайкалалар. Менә, менә алар ялгыш бер ботакка килеп тиярләр дә, «эһ» иткәнче кисеп тә төшерерләр кебек. Әнә, җеп кебек нечкә бер кылыч соргылт бөрегә китереп чапты да инде. Сагызлы бөре тышчасы көнбагыш кабыгыдай «черт» итеп ярылып китте дә, эчтән каз бәбкәсе кебек яшькелт-сары нәфис яфракчык килеп чыкты. Ул да булмады, бөре тышчасы яфракчыкка:

— Ярый, хуш! Мин үз вазифамны үтәдем. Хәзер үзең үс инде! — дигән кебек бөтерелә-бөтерелә былтыргы яфраклар өстенә очып төште.

Соргылт бөре тышчасы!

Ул үзе туңа-туңа булса да, яфракларны январь зыкыларыннан, февраль, март бураннарыннан; апрель төне салкыннарыннан саклап килә дә, табигать әле яңа гына уянып килә торган иң җылы, иң матур вакытлар җиткәч, яфракларны үз иркенә калдырып һәлак була.

Яшел яфраклар кояш нурларына иркәләнә-иркәләнә, җылы җәйге яңгырларга коена-коена шау-гөр килеп яшәгән бер чорда, ул инде аларга ашлама булып җирдә ята.

Җәй көне урман һавасы сулап та, сагызлы бөре тышчасының ачкылтым-татлы исен тоя алмаган, миллионлаган яфраклар шавы арасында язын «черт» итеп ярылып киткән бөре тышчасының кайтавазын ишетә алмаган илтифатсыз кешеләргә зур үпкәм бар.

## Апрель

Әгәр: «Әниеңне нәрсә белән чагыштырыр идең?» — дип сорасалар, минем җавабым һәрвакыт бер булыр:

— Апрель белән!

Мин аның җилкәсенә салынып төшкән чәчләренә карасам, һәрвакыт чалт-аяз һәм чем-кара була торган апрель төннәрен күз алдыма китерәм. Ә аяз төннәрдә иң ерак йолдызлар да ачыграк һәм яктырак булып яналар. Алар анда да, миллион еллар буе безгә текәлеп торган чиксезлектә дә, нииндидер тормышлар, нииндидер яңа дөньялар бар икәнен хәбәр итәләр. Нәкъ шуның шикелле, әниемнең чем-кара толымнарында ялтыраган чал чәч бөртекләре дә миңа аның моннан ничәдер еллар элек нәрсәләр күрүе, ниләр кичерүе турында сөйлиләр.

Ә инде әниемнең бераз тоныклана төшкән күзләре апрель таңындагы һаваны хәтерләтәләр. Чөнки алар апрель һавасы кебек саф һәм зәңгәрләр. Апрель таңнарында җирдән ап-ак пар күтәрелә. Иртәнге парлар анда да, җир астында да, тормышның уянуын, меңләгән тамырларның яшәве өчен туң җирнең эрүен искә төшерәләр. Әниемнең җиңелчә аксыл томан белән өретелгән зәңгәр күзләре миңа киләчәк тормышның никадәр матур булачагы турында сөйлиләр.

Мин әниемнең бер ялгызы гына калган чакларында җырлаганын ишеткәнем бар. Аның эчтән, күкрәк тирәнлегеннән чыккан авазлары апрель җилләре кебек күңелгә бетмәс-төкәнмәс рәхәтлек бирә торган җылы да һәм үзәк өзгеч сагышлы да.

Әниемнең кулларындагы тамырлар, апрельдәге нечкә ботаклар кебек бүрткәннәр һәм зәңгәрсу-соры төс алганнар. Алар әле һаман яшәүгә һәм эшкә сусыйлар бугай.

Әгәр мин бүген бихисап яфракларга күмелгән, бөтен чәчәкләре киерелеп ачылган һәм һәр авазы белән яз җырын җырлый торган май аена охшаганмын икән, боларның барысы өчен дә әнкәемә бурычлымын.

Чөнки табигатьнең үзгәрмәс бер законы бар: шаулы майның житүе өчен баштан апрель килергә тиеш. Шаулы майны безгә апрель, бары тик апрель генә алып килә.

## Алдауны яклау

Әгәр тормыш кешеләрне алдарга өйрәтмәгән булса, кешеләр бер-берсен бу кадәр ярата алырлар иде микән?!

Якын дустын тиздән рак авыруы алып китәчәген белсә дә, аны:

— Терелерсең,— дип алдый белгән кешеләрне ничек ачуланасың?!

Бары үзен генә ярата белгән ата аркасында мәңгегә ятим калган сабыйны:

— Тиздән әтиең кайтыр, — дип ышандыручыларга ничек үпкәлисең?!

Кипкән куллары белән бер-берсенең җилкәләренә суга-суга:

— Син һаман картаймагансың әле! — дип сөйләнә белүче чал сакаллы бабайлардан ничек көләсең?!

Җирдә шулкадәр дөреслек эзләп тә, бер-берегезгә җылы сүз кирәк булганда шул дөреслекне дә корбан итә белүегез өчен яратам сезне, кешеләр!

## Омтылыш

Диңгез ярында утыра идем. Диңгез дулкыннары гранит ярларны ашый, диңгез дулкыннары гранит ярларны читкә этә. Ирексездән: «Диңгез дә киңлеккә туймас икән!» — дип куясың.

* * *

Узган җәй генә ярылмаган иде бит әле бу гранит таш, көзге юеш җилләргә, кышкы ачы салкыннарга түзмәгән, күрәсең. Әнә, су чыпчыгы да таш артындагы былтыргы оясында бала чыгарып өлгергән.

Диңгездә быелгы беренче давыл башлана — дулкын сыртлары пычак кебек үткенләнделәр. Алар инде кичәгедәй иренеп кенә тәгәрәмиләр, ә әкиятләрдәге аждаһалар кебек боргалана-сыргалана диңгезнең буеннан-буена сузылдылар. Менә беренче дулкыннар гранит ярга бәрелеп челпәрәмә килделәр һәм биек яр өстендәге таш ярыгыннан су чыпчыгының оясы янындагы иңкүгә беренче тамчылар чәчрәде. Чыпчык, һәлакәт киләсен сизенде булса кирәк, гаҗәпләнгәндәй диңгезгә карап озын койрыгын сикерткәләп алды да, шәрә балаларының чыелдашуларына да карамастан, каядыр очып та китте. Ул да булмады, ярга баягыдан да зәһәррәк дулкын килеп бәрелде. Бу юлы инде иңкүгә дистәләрчә вак тамчы коелды һәм алар ялтырашып гранит ташка ябышып калдылар. Ярга өченче дулкын китереп бәргәндә инде шактый эре тамчылар элеккегеләрен дә юып төшерделәр һәм нечкә генә агым булып кош оясына табан юнәлделәр. Бу арада инде су чыпчыгы да әйләнеп кайтты. Ул тамчылар агып килә торган иңкү төбенә авызындагы борчак кадәр генә үзле балчыкны сылады да ашыгып кире очты.

Дулкыннар гранит ярга торган саен ешрак бәрелә башладылар, ләкин инде су чыпчыгы да тизлеген арттырды. Озакламый иңкүлектә кечкенә генә буа хасил булды. Торган саен зурая барган дулкыннардан иңкүлеккә һаман эре тамчылар чәчрәде. Кошчык менә генә буасын биегәйтеп китә, ә килүенә инде ул мөлдерәмә тулган да була.

Су чыпчыгы инде тизлегән икеләтә-өчләтә арттырды, ә диңгез әле һаман иләмсез тавыш белән гүли, әзмәвердәй дулкыннар килеп бәрелүдән гранит яр калтыраныл-калтыраныл куя.

Инде тәмам ачыгып җиткән кош балалары су чыпчыгы очып килгән саен әнкәләре азык китерә дип авызларын күтәреп чыелдашалар, ә котырынган дулкыннар ярга китереп бәргәндә куркышып ояларына посалар.

Су чыпчыгы арый башлады бугай, ул кызу көндә әлсерәгән шикелле авызын ачып еш-еш сулыш ала. Алып килгән үзле балчыгын иңкүлеккә сылый да, арыган канатларын сәлперәйтеп бераз гына диңгезгә табан карап тора һәм тагын озын койрыгын сикертә-сикертә гранит ташларның аръягына оча. Диңгездән искән көчле җил аны читкә каера, кайчакта шактый гына очыртып та китә. Ә чыпчык түбәннән генә, ташларга ышыклана-ышыклана һаман оча да оча.

Кичкә табан диңгезнең гүләве бераз басыла төште. Ләкин әле тәмам ярсып җиткән дулкыннар тиз генә бирешергә теләмәделәр, алар әледән-әле гранит ярга килеп бәреләләр дә, иңкүлеккә ике-өч тамчы түкереп кире чигенәләр. Янадан бәрелгәндә инде алар шактый хәлсезләнгән булалар, әйтерсең, гранит ярларга бәрелеп сөякләре сына.

Су чыпчыгы тәмам хәлсезләнде. Ул инде балчыкка киткән җирennән дә тиз генә килеп җитә алмый, балчыгын сылагач та озаграк ял итә. Борыны һәм аяклары кызыл балчыкка буялып беткән, болай да өч бармак бите кадәр генә булган гәүдәсе туктаусыз тамчы тамып торудан тәмам кечерәеп калган. Ләкин әле канатларын җәеп җибәргәндә шактый гына хәлле күренә.

Озакламый диңгез тәмам тынды. Ул, хайвани теләгенә ирешә алмаган ерткыч җанвар кебек тагын бераз гына ажгырып торды да, соңыннан тонык тавыш белән чупылдый башлады. Ә су чыпчыгы диңгезгә ышанмады булса кирәк, ул һаман балчык ташып инде үзе кереп батарлык булган буасын ныгытты. Кош балалары бүгенге азыктан тәмам өмет өзеп бер-берсенә сыеныша-сыеныша йоклап та киттеләр.

* * *

Кичтән көнбатыш ягында батып баручы кояш күренде. Сабырсыз дулкыннар һаман гранит ярларны ашыйлар, диңгез дулкыннары гранит ярларны читкә этә.

Биек яр башында, кояшның соңгы нурларында җылынып, берни булмагандай йокымсырап утырган уймак кадәр генә кошчыкны күргәч, диңгезгә карап:

— Нәрсә ул синең омтылышың?! — дип куйдым.

*Равил Фәйзуллин*

# НЮАНСЛАР ИЛЕ

## I. Этюдлар, фәлсәфи эскизлар

*Диңгез кабырчыгының да җаны бар.*

●

Кырмыска саламны сөйрәп
тумгәгенең түбәсенә менде.
Кояшка тәки якынайды!

●

Атышларда
яңа казылган кабергә
бомба төште.
Акыллы бомба!

### Көн уртасында үлгән солдат

Көнбагышка ябышып үлгән.
Ачык күзләрендә
икешәр кояш.

●

Инде апрель.
Елка булган чыршы кәүсәсендә
кисәк мамык һаман тора.

### Тулай торакта

Кызлар күптән йоклый.
Кефир шешәсендә гөлләр
танны көтә.

### Кыш. Кечкенә авылда

9 баллы давыл кичкән
карт моряк
(тельняшкасы бәби өстендә)
бишек тирбәтә.

### Әсир

Вазада җикән-камыш.
Ханым кулмәк салгандагы җил
Җилмени ул!

## Полигонда

Танкларны таптап,
генерал итекләреннән атлап,
үз түмгәген эзли
бер кырмыска.

●

Пәһлеван кабере өстендә
нәзек, кәкре усак.
Хет калтыранма!

## Көзге яңгыр

Торналар китеп бара.
Кош канатлары орынгач,
болытларның күңеле тулды.

## Натюрморт

Тәлинкәдә — Кояш.
Тастымалда — Икмәк.
Телем күзләренә нур тулган.

●

Чыршы мәңге яшел!
Чыршы мәңге яшел!
Төптә кызыл энәләр...

●

Беренче сары чәчәк!
Яфрагын үги-ана дигәннәре
кемгә хаҗәт...

●

Скульптор өтергесен ташка куйды.
Горизонтта көянтәле бер сылуның силуэты.
Бәхетле таш!

●

Судья судта карар укый.
Ә чебен...
тәрәзәдән ярык эзли.

## Искәртү

Күмелгән бәрәңге астында
күмелгән мина ята.
Көтүче чыбыркысы шартлады.

●

Диңгез аша очар
кош канаты
кабартма майлый.

## Горурлык

Таз эчендә орчык малай.
Пар эчендә ата елмаюы:
арка ышкырга кеше бар!

●

Байракларның кулагәсе кара.
Каберләрнең эче кара...
Ә җәннәт якты имеш!

## Маяк

Мизгел генә кабынып алды.
Карашны ялмап алырга
ул да җитә!

## Хәтер

Язын
иң беренче булып
таудагы кабер ачыла.

## Самолетта

Полигон урыны
ындыр табагына охшаган.
Пилот, тизрәк үтик бу турыдан!

## Теләк

Хет бер алмам
кеше кулына эләксә иде!
Карурманда карт алмагач.

●

Җырлады ятимә:
«Башка берни дә кирәкми...»
Кара, нинди көр бу моңлы көй!

## Навигация ачылгач

Беренче пароход гудогы
карга оясына эләгеп калды.
Балыкчы карт юк шул быел...

●

Бөкресе нәни генә күмелсен дип,
кулын артка куйды.
Дөнья аз гына камилләнде.

●

Үзән читендәге сау субайдан
чәрдәкләнгәннәре көнләште.
Ә ул: «Ах, бер генә боз бәрелсә икән!»

●

Чия чәчәкләре пышылдашты:
«Зәңгәр күктә түшәлергә иде!»
Төнлә
кара, салкын туфракта
ак йолдызлар.

●

Кондуктор хатын күкрәгенә
акча салкыны елыша...
Бала имезәсе бар!

●

Тудыру йортыннан чыккан
хәлсез хатын
көрттән арчылган тирәкләргә:
«Котлыйм!» — диде.

●

Ичмасам поезд да ашыкмады.
Караңгылык бераз чигенә иде.
Авыру туннельдә үлде.

## Тормыш төбендә

Туй күлмәгеннән
шикәр капчыгы теккәннәр.
Ире токмачка онны үлчәп бирә.

## Балалар

Хыял агачлары корымаган,
өмет куаклары киселмәгән,
ышаныч бөреләре кипмәгән...
Уенчыклар гына җитми.

## Ярлылык

Кесә тишегеннән җил өрә.
Маңгайга тотынып өчен
кул өскәрәк шуды.

## Без үлгәч тә дөнья матур калыр

Кояш чыгуга
чыкларның гомере бетте.
Көлеп үлделәр!

### Аерылгач

Тамчылы гөл
нәкъ әнием төсле.
Элек гөлне гел яратмый идем.

●

Иген игү нинди рәхәт!
Армиядән
пилоткадагы йолдыз эзе генә калды.

### Ялгыз карт

Өй артына каен түгел, —
имән утырткан булсам!

●

Кыз кияүдән кайтты.
Капка төбендәге утыргычка
быел кем утырыр?..

### Балыкчы диңгезгә киткәч

Уылган керләрдән дә
балык исе килә.
Тиздән ире кайтыр.

## 2. Ул көннәр дәфтәреннән

*Мин учак яктым.*
*Җир яктырганын*
*чит планетада*
*бәлки сизгәннәрдер.*

### Гашыйк булгач

Өметемнең күзе
шундый зур!
Керфекләре генә ябылмасын.

### Янымда син булсаң

Җилдә соңгы шырпыны кабыздым.
Мин дөньяда иң бәхетле!

### Иделдә йөзгәндә

Маяклар, күрдегезме
яңа ак дулкынны!
Чуерташлар арасында туфляларым.

●

Балык чистартканда
маңгаена тәңкә кунды.
О, болай син нинди матур!

●

Ап-ак сабын күбегендә
чем-кара толымнары.
Бәхетлеме,
бәхетсезме сез, күбекләр?

## Йоклап булмаган төннәрдә

Ак Кремль стенасындагы
без язган исемнәргә
яңгыр гел бәреп ява кебек.

●

Сүз куешкан җиргә килмәде ул.
Мин ярты көн көттем.
Тунгустагы кебек
метеорит төшсен ул җиргә.

## Аны көткән кышны

Ой, быел кыш озын булды!
Тәрәз арасындагы
мамыктан да туйдым.

## Онытмадым

Мәрмәр муенында
ялган чокыры юк та...
Хыянәтеңнән барыбер үч алам.

# 3. Күңел калейдоскобыннан

*Үземнән канәгать булсам,*
*сез җирәнегез миннән!*

## Хурлык

Олы уйлар төртеп уята да,
кәрлә эшемне кочаклап
йокыга китәм.

## Язганда

Шатлык әчкә сыймый:
күңел локаторы
ике сүз тотты!

## Ялсыз эштән соң

Желек кипте. Ябыктым.
Ай яктысында
сөякләр ялтырый.

Күңелемдә нәфрәтем чиксез иде.
Сыймаганы йодрыгымда йөрде.
Уч төбендә эзләр калды.

Бөртекләп җыйдым хәтердән
бәхетле көннәремне.
Ярты уч та тулмады.

Камыл
табанымнан
йөрәгемә кадәр чәнчеде.
Ах, син, икмәк!

Кайгыны шатлыкка
әйләндерергә булса, —
мин дә алхимик.

## Сәбәп

Аерылышабыз.
Аяк бармагындагы
миңе ошамады.

Быел язын
бар гөрләвекне укыдым:
һәммәсе яшәү турында!

Мәңге онытмам! — диде.
Оныкларының
оныкларын уйлап куйдым.

## 4. Читтә–туган җир турында

*Читтә баскычлар шундый биек!*

●

Ярлар бик тар булса — ул инеш,
ярлар ерак булса — ул диңгез,
ярлар чиксез булса — океан...
ә һәр тамчының
дулкын өстендә булырга
хыялы бар.

●

Салават күперендәге
төсләргә кысан түгел.
Җирдә нинди генә халык юк!

●

Таш койма өстендә
үсте каен.
Тамырлары киткән саен —
хәвефлерәк...

### Болгар

Чиркәү нигезендә
бабайлар кабер ташы.
Гади ташлар да
юк түгел тирәдә...

### Я. Райнис янында

Ригада, Бирзе аллеясында
Такташ кабере
искә төште.

●

Будапештта — имән!
Балачакта мин сыйпаган
ботак очлары
хәзер кәүсәдер инде...

### Эмигрант

Җир тәнендә тигезләнергә
кайда да урын бар.
Бабайлар күзәнәге тарта.

## Югославиядә

Хатка тамган күз яше күк
авыр мин бүген.
Музейга сөйрәп йөртмәгез,
очрашуга да...
Кайтасы килә.

# 5. Толлар яныннан узганда

*Иртәнгә — хәтерләүләр,*
*Көндезгә — хәтерләүләр,*
*Кичкә — хәтерләүләр...*
*Мине икмәк белән тора диләр!*

## Җәен

Тулы башаклардан җиргә төшкән
орлыкларның барсын җыйсаң икән!
Икмәге дә, бәлки, тәмсез булмас иде...

## Көзен

Юк ла ул әбиләр чуагы!
Бары кыр тулы
тормышка ашмаган сөю җепләре.

## Кышын

Тирәкләргә кадәр, карга төренеп,
бер-беренә сыенганнар.
Өйгә керим тизрәк!

## Язын

Алла боерса ташулар да уза,
Алла боерса ташулар да бетә.
Елгалар үз ярына кайта инде.

*Г. Зәйнашева*

## Ак челтәр уйларым

Аһ, зифа буйларың,
Мин күреп туймамын,
Гел сиңа үреләә
Ак челтәр уйларым.
Көн туа алланып,
Чык тама балланып,
Дөньяда син барга,
Яшим мин куанып.

Йөрегән юлларың,
Тын гына буйларым,
Гел сиңа үреләә
Ак челтәр уйларым.
Яз килә Иделгә,
Моң сала күңелгә,
Дөньяда мин барын
Син белмисеңдер дә!

## Язгы кичтә

Кичен килеп тәрәзәмне
Бер генә чиртсәң иде.
Таңда ачылган чәчәктәй
Ачылып китсәң иде.

Ачылып бер генә сүз әйт,
Аңлар идем барсын да.
Я булмаса елмаеп тор
Сүзсез генә каршымда.

Бөредә яткан хисләрем
Уянды язгы кичтә.
Ни булды бу йөрәгемә,
Тынгылык тапмый һич тә.

Гөрләвек булсам каршыңа
Челтерәп агар идем.
Яңгыр булсам иреңеңә
Мөлдерәп тамар идем.

# *Язучы трибунасы*

*Гаҗәеп дәрәҗәдә игътибарлы, кайгыртучан һәм үз фикерләрен кемнең-кем булуына карамый күзгә туры карап әйтә алучы таләпчән матур әдәбият сөючеләребез күп безнең. Матбугатка теге яки бу яңа әсәр чыккан саен, газета-журналлар редакцияләренә һәм авторларга әнә шул укучылардан күпләп хатлар килә башлый. Ләкин, нигәдер, без укучы хатларын җыю, туплау, өйрәнү эшенә үтә салкын карыйбыз. Бу эш бездә бөтенләй диярлек эшләнми. Ә бит ул хатлар — әдәбият турында халык фикеренең тамчылары, укучылардан килгән хатларның күбесендә конкрет әсәр турында да, әдәбиятыбызның гомуми торышы, көчле һәм җитешсез яклары турында да бик кыйммәтле фикерләр була.*

*Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы басыла башлаган көннән алып бүгенгә кадәр журнал редакциясенә укучылардан өзлексез рәвештә хатлар килеп тора. Журналыбызның түгызынчы санында без ул хатларның кайберләрен укучыларыбызга тәкъдим иткән идек инде. Ләкин алар бик күп, барысын да бастырып бетерү мөмкин дә түгел. Әлегә матбугатка чыкмаган ул хатларда да игътибарга лаеклы, кызыклы мәсьәләләр күтәрелә. Күп кенә укучылар романның язылу тарихы, әдәби образлар, аларның ничек иҗат ителүләре белән кызыксыналар. «Ак чәчәкләр» турында журнал редакциясенә килгән шул хатларга күзәтү ясауны һәм укучыларның күп санлы сорауларына җаваплар язуны үтенеп, без романның авторына — Габдрахман Әпсәләмовка мөрәҗәгать иттек. «Казан утлары»ның бу санында язучының безнең үтенеч буенча язылган мәкаләсен урнаштырабыз.*

*Габдрахман Әпсәләмов*

# ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ЯНЫНА

## «АК ЧӘЧӘКЛӘР» РОМАНЫ ТУРЫНДА УКУЧЫЛАРНЫҢ ФИКЕРЛӘРЕ

«Ак чәчәкләр» романы журнал битләрендә басылып чыкканнан соң, газета-журнал редакцияләренә һәм авторның үзенә укучылардан бик күп хатлар килде һәм килеп тора. Мөмкин булган кадәренчә, ул хатларга җавап бирелә. Ләкин хат — хат инде ул, анда рәхмәттән башка әллә ни әйтеп булмый. Ә укучының сораулары төрле, күп, кызыклы һәм аерым әсәр, аерым язучы рамкасыннан чыгып, гомумән әдәбият мәсьәләләренә дә кагылып китәләр. Менә шуларны искә алып, «Казан утлары» бу турыда аерым мәкалә язарга киңәш иткәч, мин шатланып риза булдым. Ихтимал, укучыларга һәм яшь язучыларга да бераз файдасы тимәсме дип уйладым. Яшермим, бу тәкъдимнең үзем өчен тагын бер куанычлы ягы бар иде: бу — «Ак чәчәкләр»нең укучылар белән журнал битләрендә кабат очрашу шатлыгы. Моннан бер ел элек, романны редакциягә тапшырганда, укучы аны ничегрәк каршы алыр дип, бик борчылган идем. Хәзер бит журналның һәр санында диярлек яхшыдан-яхшы әсәрләр чыгып тора, шулар арасында минем әсәрем югалып калмасмы, укучы аны күрерме дигән шикшөбһәләр аз булмады. Аннары врачлар дөньясы... Мин бит үзем врач түгел... Медицина проблемалары арасында тәмам буталып бетмәмме, көлкегә калмаммы... Тезә китсәң, андый шикләнүләрнең очы-кырые булмас иде. Әсәрне врачлардан кат-кат укыткач та, җаным тынычланмады. Мөгаен, медицина күзлегеннән караганда кимчелекләр шактый калгандыр әле, дип эчтән сызып йөри бирдем. Һәм шулай булып чыкты да. Журналның беренче саны укучы кулына барып керү белән үк Әгерҗе больницасы врачы иптәш М. Шаммасовтан хат килеп төште. Медицина терминнарында ялгышлар бар! Мин Шаммасов иптәшкә рәхмәт әйтеп хат яздым, киткән хаталарны төзәтәчәгемне әйттем. Һәм... башка врачлардан тагын да хәтәррәк хатлар көттем. Бәхеткә каршы, андый хатлар бүтән булмады. Ә иптәш Шаммасов әйткән кимчелекләрне романны китап итеп әзерләгәндә төзәттем,— алар күп булып чыкмады, кайберләрендә хәреф хатасы гына иде. Шулай да романны тагын бер мәртәбә белгеч кулына биреп алу-

ны кирәк дип таптым һәм бу нәрсә эшләнде дә. Казан врачлары үзләренең батыр һәм матур хезмәтләре, тормышлары белән мина язу өчен материал биреп кенә калмадылар, бәлки консультация юлы белән дә чиксез зур ярдәм күрсәттеләр. Моның өчен аларга чиксез бурычлымын һәм җае туры килгәндә, тагын бер мәртәбә рәхмәтемне белдермичә уза алмыйм.

«Ак чәчәкләр» турында укучыларның хатларында бик күп җылы сүзләр әйтелгән. «Социалистик Татарстан» газетасында (29 август, 65 ел) һәм «Казан утлары» журналында (9 сан, 65 ел) ул хатларның үрнәкләре басылганлыктан, минем эшем шактый җиңеләеп китте. Шуңа күрә хатларның ул якларын, ягъни әсәргә турыдан-туры бәя бирү моментларын бөтенләй төшереп калдырып (әгәр теләсәләр моны тәнкыйтьчеләр, әдәбият белгечләре эшләрләр), алардагы гомуми мәсьәләләргә күбрәк тукталырга уйлыйм. Алары да җитәрлек һәм бер мәкаләгә генә сыеп та бетәрлек түгел.

## ЯЗУЧЫ ҺӘМ УКУЧЫ. РОМАН ҺӘМ ТОРМЫШ

Хатларны укыганда, мине китап укучыларыбызның киң күңелле, культуралы, белемле, әдәбият эшен йөрәкләренә бик якын итүләре, язучы хезмәтенә ихтирам күрсәтүләре, язучыга булышырга әзер торулары аеруча сокландырды. Идел буе фанера-мебель комбинатында мастер булып эшләүче Икрам иптәш Фәйзуллинның хатында мондый юллар бар: «Мин «Известия» газетасында бер мәкалә укыган идем. Шунда бөек көнчыгыш медигы Әбүгалисинаның сүзләре китерелгән иде: «Врачка карчыга күзләре, кызлар куллы, елан хикмәте (мудрость) һәм арыслан йөрәге кирәк». Менә шушы сүзләрне романыгызның яңа басмасында эпиграф итеп файдалансагыз, минемчә, бигрәк тә яхшы булыр иде».

Казанда яшәүче Заһидә ханым Сәубәнова, «Казан утлары»ның элекке редакторы Газиз Мөхәммәтшинга мөрәҗәгать итеп, болай яза (бусы роман басылып бетмәс борын ук килгән хат):

«Личный минем үтенеч: зинһар автор Мансур белән Гөлшәһидәне кавыштыра күрсен. Кавыштыргач та аларның тормышларын беркадәр күрсәтсен. Мансурның Диләфрүзгә тәкъдим ясавы вакытында минем нихәлдә булуымны язучы белми, ярый әле миндә Хәйдәр абыйдагы «инфаркт» юк. Гөлшәһидә урынында минем йөрәгем өзелгән булыр иде».

Заһидә ханым журналны үзе генә укымый икән. Ул аны якыннарына да, хезмәттәшләренә дә кычкырып укый икән. Мин аңа хат язганда, аның шул изге эшен хуплап, аны «агитатор» дип атаган идем. Шуннан ул редакциягә бик озын яңа хат язган (бер дәфтәр!). Без бу хатны бик зур кызыксыну белән укыдык. Бик гыйбрәтле хат булып чыкты әле ул.

«...Минем турыда бик яхшы агитатор дип әйтеп ялгышкансыз. Үз гомеремдә миңа андый мактаулы бурычны тәкъдим итүче булмады,— дип яза Заһидә ханым.— Булса да, башкарырга көчем җитмәс иде. Көч-хәл белән генә биш класс бетердем, анысы да моннан 35 ел элек булган хәл... Мин үзем кечкенә генә бер парикмахерскаяда кассир-гардеробщица булып эшлим. Китап укуны кеше юк чакларда, бигрәк тә кичке сменада башкарам. Әгәр клиентлар килеп керсә, алар да тыңлыйлар. Кырыналар да, тыңлыйлар да. Эштәге иптәшләр арасында руслар да бар. Мин аларга русчага тәрҗемә ителгән татар китапларын укыйм. Әле тәрҗемәләре булмаганнарын үзем сөйлим. Белмим, әллә без бик тату яшәгәнгәме, алар мине аңлыйлар (гәрчә русча бик ару сөйләмәсәм дә), укуымны да яраталар. Клиентлар арасында исә төрле кешеләр була. Күпләр кызыксынып тыңлыйлар, чыгып киткәндә рәхмәт әйтәләр. Китапның исемен, авторын сорыйлар, кайткач үзебез табып укыйбыз, диләр. Кайвакытта шундыйлар да туры килә... Бервакыт бер кеше минем үземнең генә укып утырганны күрде дә, нәрсә укыйсыз, дип сорады. Аннары җавап биргәнне дә көтмичә, журналның тышын әйләндереп карады да, йөзен чытып:

— А-а, татарская литература... Там и читать нечего,— диде.

Минем йөземә кан бәрде, әйтерсең, йөрәгемне өзеп алып аяк астында таптады. Җитмәсә, «У вас среди татарских писателей классиков нет и не будет», ди. Оят булса да сезгә әйтим, елап җибәрдем. Аннары тегеңә:

— Мин үземне бик надан хатын дип йөри идем, миннән дә наданрак бер кеше бар икән. Коры надан гына түгел, ахмак надан! — дидем.

Әкрен генә әйтсәм дә, иптәшләрем минем сүземне ишетеп көлеп җибәрделәр һәм бертавыштан: «Без ахмакларның чәчен кырыкмыйбыз, сакалын кырмыйбыз! Поп шикелле яллы булып йөрсеннәр», — диделәр. Ахырда теге кеше минем янныма килеп:

— 4 : 2 сезнең файдага. Сез яхшы вратарь булмасагыз да, яхшы болельщица икән. Гафу итегез, сүземне кире алам. Күрәм, яхшы нәрсә укыйсыз,— диде. Ул моны чын күңелдән гафу үтенеп әйттеме, әллә поп булып йөрмәс өчен генәме, анысын да мин аңламадым. Көне буе күңелсезләнеп, гарьләнеп утырдым (ә сез агитатор!).

Бервакыт тагын шулай булды: ял көне иде, халык та күп иде, радиодан көндезге ял концерты тапшыралар иде. Бер егет керде дә радионы туктатып куйды.

— Татары поют, к дождю, наверное,— дип көлде. Ярый әле чират көтеп утыручы 15—20 ир арасында тоздан төрелгәне бер генә булып чыкты, югыйсә ял концертыннан мәхрүм каласы идек. Башкалар да әйтә башлагач, шып булды егет. Ә чәчен алдырып акча түләгәндә, миңа татарча итеп:

— Рәхмәт, апа, сез миңа беренче мәртәбә татарча концерт тыңларга булыштыгыз. Минем әле үзебезчә чын-чынлап концерт тыңлаганым да юк иде,— диде. Татар башы белән шулай кыланган бит, юньсез!..»

Укучы күргәндер, мин аз гына да ялгышмаганмын, Заһидә ханым чын агитатор. Кайчакта без агитаторларны нинди дер формаль билгеләргә таянып билгеләп бик начар эшлибез һәм зур, кирәкле, аерата мөһим эшне салкын күңелле, сүнгән йөрәкле кешеләр кулына тапшырып, халыкка файда китерәсе урынга зыян гына китерәбез. Агитация эшендә дәртсезлек аерата куркыныч нәрсә. Ә Заһидә ханым шикелле тыйнак, ләкин кайнар йөрәкле кешеләр бездә бик күп, тик аларны күрә белергә һәм аларга ышанырга гына кирәк.

Казан мәктәпләренең берсендә укытучы булып эшләүче Зәкия ханым «Ак чәчәкләр» романы буенча бүтән бик күп мөһим мәсьәләләрне күтәрә. Безнең Казан халкының үз-үзен тотышы, бер-берсенә мөгамәләсе, элементар әдәплелек кагыйдәләрен бик күпләрнең белепме-белмичәме бозулары, шәһәрнең чисталыгы һәм башка бик күп мөһим мәсьәләләр турында яза ул. Аннары Ленин районының 11 номерлы поликлиникасындагы тәртипсезлекләр турында сөйли. Гомумән, больницаларыбызның эше һәм врачлар турында (яхшылары һәм игътибарсызлары турында) бик күп язалар. Бу мәсьәләне аерып алып, сәламәтлек саклау министрлыгында сөйләшергә туры килмәгәе дип торам әле. Күп кенә авырулар романны үзләренең дәвалаучы врачларына укырга бирәләр. «Карагыз, монда сезнең турыда да язганнар» диләр икән. Әгәр роман бер унайдан безнең больницалардагы кайбер кимчелекләрне бетерергә дә булышса, мин бик шатланыр идем.

Балтач районының Түбән Кенә авылында яшәүче Тәзкирә Гомәрованың хатлары бик кызыклы. Менә ул әдәбият турында нинди фикердә: «...Әдәбиятны укымаган, аны чын түгел, язучы уйлап чыгарган фантазия, хыял гына дип йөрүчеләр, минемчә, нинди зур эштәге кешеләр булсалар да, яңа дөньядан, бәхеттән, гүзәллектән мәхрүм, мескен кешеләр кебек. Бәлки, минем фикерләрем дөрес түгелдер, минем әдәбиятны шулай көчле яратуым гына мине шулай уйларга мәҗбүр итәдер».

Юк, бик дөрес фикерләр болар. Тәзкирә Гомәрова хаклы рәвештә китапны үзенә бертөрле яңа дөнья итеп, бәхет һәм гүзәллек дөньясы итеп аңлый, китап тормышны аңларга ярдәм итә, зур эшләргә дәрт бирә, дип әйтә. Бу инде безнең укучыларыбызның гаять югары үскәнлеген, аның культура дәрәҗәсен күрсәтә. Элеккерәк елларда укучылардан килгән барлык хатларда да диярлек иң элек геройлар кавыштылармы, юкмы, балалары бармы, дип кенә сорыйлар иде. Ягъни мәгънәсенә кермичә гади кызыксыну гына күбрәк була иде. Хәзер бөтенләй башкача, мәгънәгә керәләр.

«Журналның һәр санын түземсезлек белән көтеп алам. Ә инде яңа санын укып чыккач, бу романның дәвамын күз алдыма китерәм, геройларның тормышларын үз уемча үстерәм...» дип яза Бәләбәй педучилищесыннан Әлфия Фазлыәхметова. Монысы да кызык бит! Укучы иҗат эшенә кушылып китә, үзе иҗат итә башлый. Моны исә әзерлекле укучы гына эшли ала. Әлфия Фазлыәхметова, күрәсең, музыкаль җанлы кеше, Гөлшаһидә җырының көен дә сорый. Гомумән, музыка безнең кешеләрнең тормышына бик нык кереп бара ахрысы. Гөлшаһидә җырының нотасын сораучылар бик

күп булды. Хәзер инде укучыларның бу теләге үтәлгәнлеген дә әйтә алабыз. Композитор Җәүдәт Фәйзи аңа бик уңышлы көй язган. Бу җыр радио тапшыруларыбызда да яңгырады инде.

Әйе, безнең укучыбыз китапны эчке тирән кичерешләр һәм зур кызыксыну белән укый, дөреслекне һәм матурлыкны сиземләп укый. Бу — факт. Хәтта ишек чыптасы кебек вак кына детальләрне дә, әгәр алар аның карашынча дөреслеккә туры килмәсә, күзеннән ычкындырмый. «Ак чәчәкләр»дә Асияләрнең ишекләре чыпта белән тышланган дип әйтелә. Укучы шуны искә алып: «Чыпта хәзер авылда да юк. Авыл өйләрендә әлеккеге кебек чыпталы ишекләр бетте инде. Киндер яки клеенка куялар...»— ди. Яки менә тагын бер характерлы деталь. Гөлшәһидә баласын күтәргән. Укучы шул уңай белән болай ди: «Минемчә, шәһәрдә ире янында булганда, хатын бала күтәреп йөрми. Хәзер авылда да укыган ирләр балаларын үзләре күтәрәләр... Шулай отышлырак чыга хәзерге заман өчен, ышандырырлык була. Киләсе романнарыгызда искә алырсыз...»

Хикмәт бу детальләрнең дөрес яки дөрес түгеллегендә генә түгел, хикмәт укучының шуны күрә белүендә, яңалыкны тоя белүендә һәм шушы матур яңалыкларны тормышта гына түгел, әдәбиятта да күрергә теләвендә, икенче төрле итеп әйткәндә, укучының эстетик зәвыгы үсә баруында. Бу аерата шатлыклы, куанычлы нәрсә.

Яки менә тагын бер деталь:

«Безнең район больницасында шушы көннәрдә баш врач үзен-үзе атты, никадәр белемле әрәм итте. Болай кешелекле иде кебек. Башта, билгеле, кызгандым. Аннары «Ак чәчәкләр»не укыса, бу ахмаклыкны эшләмәс иде дип уйладым. Эшләмәс иде, гыйбрәт тапкан булыр иде, укымавы кызганыч...»

Күрәсез, китапка никадәр ышаныч. Ә үз-үзенә кул салган врач турында нәрсә әйтергә мөмкин? Борынгы римлыларда бер мәкаль булган. Алар үлгәннәр турында яки мактап кына сөйләргә кирәк, яки бернәрсә дә сөйләмәскә кирәк дигәннәр. Бу очракта соңгысы хәерлерәк. Әмма шулай да үз-үзенә кул салучыларны аклый торган очрак бармы икән? Хәтта үлем лагерьларында кеше чыдамаслык шартларда да, үлеме белән дошманга протест белдергәндә дә, чын патриотлар андый үлемне акламаганнар, андый юлны кәрәш юлы дип исәпләмәгәннәр.

Һәр хат тормышның нинди дә булса бер яхшы ягын яки күләгәсен, кеше күңеленең шатлыгын яки тирән әрнү-хәсрәтен, фаҗигасен яки өметен алып килә. Һәм шулар белән бергә йөрәк серләрен дә алып килә. «Романны укыгач, үземдә яшәүгә көч таптым, сәламәтләнүемә өметем артты...» Бу юлларны озак еллар буенча төрле авырулардан җәфа чигүчеләр язалар. Минем өчен бу юллар бик кадерле. Кешедә өмет чаткысы кабызу — ул бит мактаулы эш.

«Ак чәчәкләр» романының үзәгендә торган проблемаларның берсе — мәхәббәт мәсьәләсе. Шунлыктан укучылардан килгән хатларда да мәхәббәт мәсьәләләре зур урын ала, хатлар сер һәм йөрәк яралары белән тулган. Кешеләр үзләренең мәхәббәтләре, фаҗигаләре турында сөйлиләр, киңәш сорыйлар. Мондый хатлар язучылар өчен бик кыйммәт дисәм, һич ялгыш булмас. Чын тормыш кисәкләре ич алар, кеше язмышлары, күбесе утлы күмер кебек, тотып алуың белән ук кулны куыргандай була. Укучы үзенең беркемгә дә сөйләмәгән серләрен язучыга ышана, чөнки аның беркайчан да гайбәт сатмавын, серне фаш итмәвен белә. Шуңа күрә мондый хатларны язган кешеләрнең исем-фамилияләрен күрсәтү һич тә ярый торган эш түгел. Бу ике арада гына кала торган сер.

«Кино, спектакльләрдә,— дип яза бер кыз,— чын мәхәббәтнең булуын күрсәтәләр, китапларда язалар. Мин дә моның булуына ышанам, әмма үземә мәхәббәт утында янарга туры килгәне юк. Минем дә, Диләфрүз әйткәнчә, сөясем һәм сөеләсем килә...» Шуннан ул үзенең күңел тибрәнүләре, җилкенүләре, моң-зарлары турында язып, еракта гы бер дусты турында сөйли, аны котәргәме, юкмы дип сорый. Чөнки теге сөям дип тә, сөймим дип тә әйтми икән. Аннары мәхәббәт кайчан башлана, читләтеп үтеп китмиме дип сорый.

Бүтән хатларда да шуңа охшашлырак сораулар бирелә. Тагын бер нәрсәгә игътибар иттем: мәхәббәт турындагы хатларны гел хатын-кызлар гына язалар. Күрәсең, ни әйтсәң дә, хатын-кыз күңеле нечкәрәк һәм мәхәббәтне тирәнрәк аңлый, тирәнрәк кичерә. Кайберләре ирләрдән көнләшеп «ирләргә ни, алар теләсә кемгә мәхәббәтләрен белдерә алалар, ә хатын-кызлар янып-көеп йөргәндә дә моны эшли алмый»,—дип язалар.

Кеше күңеленең иң нечкә, иң матур, иң катлаулы һәм иң четерекле тойгысы — мәхәббәт турында берәүгә дә син менә болай эшлә, ә син менә тегеләй ит дип, шул проблеманы гомер буе өйрәнүчеләр дә конкрет киңәш бирә алмыйлар. Әгәр шундый бер бәндә табылса, аны шунда ук юләрләр йортына озатырлар иде. Язучы фәкать образлар аша теге яки бу геройның мәхәббәтен күрсәтә, тасвирлый, бертөрле мәхәббәтне ул яклый, икенчесен кире кага, шулар белән үзенең мөнәсәбәтен белдерә, укучыны уйландыра, аңардан да шул мәсьәләләр тирәсендә фикер йөрттерә. Язучы укучыны мәхәббәтнең кадерен белергә өйрәтә, аның зур, матур хис икәнен, яшәүгә ямь һәм бәхет бирүен әйтә, әмма беркемгә дә рецепт бирми, бирә алмый, кулыннан килми. Чөнки, Такташ әйтмешли, мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны янарта. Янартып кына да калмый, бәлки һәрбер йөрәк үзенчә генә сөя һәм бернинди кануннарга да, календарьга да буйсынмый. Шуңа күрә аның кайчан килүен һәм читләтеп узып китү-китмәвен кеше үзе генә белә ала.

«Нигә сез, язучы иптәшләр, гадәттә, кешенең физик матурлыгына ныграк басым ясыйсыз? Ирексездән шундый уй туа: чибәр булмаган кешеләр бөек эшләр эшли алмыйлар икән»,— диелә янә бер хатта. Икенче төрле әйтсәк, бу инде сәнгатьтә матурлык-ямьсезлек проблемасы. Бу мең еллардан килә торган мәсьәлә. Рус һәм дөнья әдәбиятлары һәм сәнгатьләре тарихында бу турыда бик күп язылган, сөйләнелгән. Безнең татар әдәбияты һәм сәнгате тарихында, хәтерем ялгыштырмаса, бу мәсьәлә буенча хезмәтләр юк шикелле, булса да бик аздыр. Ә мәсьәлә, күрәсез, кешеләрне борчып тора. Гомумән, без укучыбызның күңеле турында, бигрәк тә аңа әдәби, сәнгати һәм матурлык тәрбиясе бирү турында аз кайгыртабыз, күбрәк гомуми сүзләр белән тулып беткән, акылга да, йөрәккә дә азык бирми торган гомуми мәкаләләр белән чикләнәбез. Бу кимчелекне бетерергә вакыт җиткән. Мин уйлыйм, безнең тәнкыйтьчеләр, белгечләребез бу мәсьәлә буенча аерым чыгыш ясарлар әле. Мин исә бу мәсьәләгә бик кыска гына тукталам.

Язучылар кешенең гел тышкы матурлыгына гына басым ясый дип әйтү бик дөрес түгел. Хәзер язучылар кешенең рухын ачуга, аның эчке матурлыгына күбрәк игътибар бирәләр. Ләкин эчке һәм тышкы матурлыкны кара-каршы куярга ярамый. Безнең идеал: кеше үзенең рухы белән дә, тышкы кыяфәте белән дә матур булырга тиеш. Сәнгатьтә бигрәк тә. Чөнки сәнгатьнең бурычы — кешеләрдә матурлык хисе тәрбияләү. Сәхнәгә, әйтик, берәр җырчы чыга икән, ул инде үзенең тышкы кыяфәтенә игътибарсыз булырга тиеш түгел. Әйтик, талымсыз гына киенгән берәү сәхнәгә чыгып мәхәббәт турында җырлый икән, аның тавышы, моңы бик матур булганда да, тыңлаучыга биргән ләззәте житенкерәмәве һәркемгә билгеле. Мин үзешчән артистларны бик яратам, алар арасында гаҗәп талантлы җырчылар, биючеләр бар. Кыяфәтләре, буй-сыннары да әйбәт, ләкин кием салымга, сәхнәдә үз-үзләрен тотышларына игътибарсыз булулары аркасында, үзләре тудырган матурлык дөньясын үзләре үк ямьсезләп йөрәкне әрнеткән чаклар булгалый. Бернәрсәне онытырга ярамый: сәнгать кешенең барлык тойгыларына берьюлы тәэсир итәргә тиеш, шунда гына аның көче тулы була. Аннары шуны да истән чыгармаска кирәк: чын сәнгатьнең, чын матур әдәбиятның натурализм белән һичбер уртаклыгы юк. Тормышта, әлбәттә, физик яктан гарип кешеләр дә, гомумән ямьсез кешеләр дә аз түгел. Натуралистлар гына, чынбарлыкны дөрес күрсәтәбез дип, әллә нинди коточкыч, шүрәле сыман кешеләр ясап куярга маташтылар. Ләкин халык андый карачкыларны кабул итмәде, чөнки әдәбиятта һәм сәнгатьтә ул иң элек *Кеше* күрергә тели, ә *Кешенең* асылы һәрвакыт матур. Ниһаять, халыкның тормыш шартлары туктаусыз яхшыра баруы, халыкка медицина хезмәте күрсәтүнең үсә баруы һәм шул нигездә элекtә кешене гарип итә торган бик күп чирләрнең бетә баруы, физик тәрбиягә шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да көннән-көн күбрәк игътибар бирелүе кешеләрне тышкы яктан да матурайтуга таба алып бара. Гомумән алганда, дөньяда искитмәле матур нәрсәләр — җанлысы, җансызы — бик күп, әмма кешедән дә матур булганы юк. Шулай булгач, ни өчен әдәбиятта аның матурлыгына басым ясамаска?

## СОРАУЛАР. ӘДӘБИ ОБРАЗЛАРНЫҢ ТУУЫ

«Ак чәчәкләр» романын укучыларның яшьләре төрле-төрле — хатлардан тагын янә шул күренә. Бу шатлыклы хәл, чөнки элегрәк елларда минем әсәремне яшьләр генә укый дип үзенә бертөрле «кимчелек» табалар иде тәнкыйтьче агайлар.

«Мин карт инде, шулай да сезнең романнарны яратып укыйм,— дип яза Актаныш районыннан Сабира апа Җиһаншина. Оренбургтан биш романыгызны да укыдым дип хат җибәргән Маһишәрәф апа Юсуповага 80 яшь, ул Тукайның яшьтәше икән. Ташкент шәһәреннән хатлар язучы хөрмәтле Шакир абзый Мөхәммәдьяров тагын да өлкәнрәк. Ул, үзбәкләр әйтмешли, мең ай күргән карт (84×12=1008 ай). «Мәрхүм Каюм Насыйри хәзрәтләрен күмгәндә, учительская школада укый» торган булган! Тукайлар, Фатих Әмирханнар, Галимҗан Ибраһимовларның югары әдәби мәктәбендә тәрбияләнгән һәм алар белән заманында аралашкан бу мөхтәрәм аксакалның фикерләре минем өчен бик тә кадерле, аларда бер гасырлык тормыш тәҗрибәсе бар бит.

Яшьләрнең хатларында тормыш дәрте, яшәү шатлыгы аеруча күзгә ташлана һәм сорауларында да яшьлеккә хас шуклык сизелеп-сизелеп китә. Арада елмаю уята торганнары да бар. Роман басылып бетмәс борын ук, Башкортстанның Айбуләк авылыннан бер төркем яшьләр журнал редакторына мөрәҗәгать итеп болай язалар: «Романның төп герое Әбүзәр абзый Таһиров турында белергә ашыгабыз. Романның ахырын көтәргә түземлелегебез җитмәгәнлектән, сезгә хат язып сорарга булдык...»

Башкортстанның Иске Казанчы мәктәбенең унынчы классында укучы Роза Ганиева болай яза: «Врач булу — минем иң татлы хыялым. Мин кешенең тәнен дә, җанын да дәвалаучы врач булырга телим». Шуннан соң Роза роман геройларының адресларын табып бирүне үтенә. Күрәсең, алар белән үзенең булачак профессиясе турында хат язып киңәшергә уйлый. Туймазадан Гәрәева, Мөхәмметова, Мингазова иптәшләр дә Гөлшәһидәләрнең адресларын сорыйлар. Гомумән, мондый сораулар шактый күп. «Безне кызыксындырган, безнең сорап язасы килгән шул: бу врачларның үз исемнәреме, алар әле дә шул ук больницада намуслы хезмәтләрен дәвам иттерәләрме?» — дип сорый Биектау районының Ямаширмә авылында яшәүче Наилә Шиһапова.

«Гадәттә язучылар үзләренең геройларын уйлап чыгарылган кешеләрдән төзиләр. Күңелдә шулкадәр эз калдыра торган Гөлшәһидә дә уйлап чыгарылган түгелдер бит? Хәзер ул, әлбәттә, Казан клиникаларының берсендә я профессор, я медицина фәннәре кандидатыдыр. Югыйсә, Гөлшәһидәнең шулкадәр нечкәлекләрен уйлап чыгарырга мөмкин түгел! Язучы, күрәсең, үзе дә Гөлшәһидәне иң матур хисләр белән яраткандыр, алай булмаса Гөлшәһидә образын ул шулкадәр ачыклый алмас иде... Медицина тормышын язучы шактый гына ачык язган. Язучыга, үзен авыру төсенә кертеп, ирексездән больница койкасына ятарга туры килгәндер дип уйлыйм...» Монысын Караиделдән шулай ук врач булырга хыялланучы Һәдия Ямалетдинова яза.

Менә икенче төрлерәк фикерләр:

«Әбүзәр абзый, Гөлшәһидә, Мансур, Маһирә Хәбировна, Диләфрүз, Юматша һәм Акъяр больницасы бармы дип сорамыйм. Алар бар — минем күңелемдә алар һәрвакыт яшәрләр инде» (Гумерова Т.).

«Романны укып чыккач, ул больницадагы вакыйгаларны гына түгел, мин анда үземне дә күрәм. Асия — мин ул. Аерма тик шунда: аның йөрәге, минем ул вакытта үң аягым авырта иде... Кисәргә кирәк дигәннәр иде. 17—18 яшьлек кызга аяксыз калу үлем белән бер» (З. С.).

Сөембикә исемле кыз да (Казан) үзенең Асиягә бик нык охшаганлыгын яза: «Асиянең сәламәтләнеп чыгуына бик шатландым. Бәлки, мин дә терелермен әле. Мин дә бит рәсем ясарга, гармунда уйнарга яратам, аккордеон да сатып алдым, музыка мәктәбенә керергә хыялланам...»

Күрәсез, монысы тагын бер Асия. Хатлар язучылар арасында үзләрен кичерешләре белән Гөлшәһидәгә охшатканнары да бар. Диләфрүз кебекләре дә юк түгел. Ә бит ул кешеләрне минем күргәнем дә юк. Роман чыгып, алар хатлар язмаса, шундый кешеләрнең дөньяда яшәүләрен дә белми калыр идем. Шулай итеп, без тора торгач иҗаттагы иң кыен эшләрнең берсенә — әдәби образлар иҗат итү мәсьәләсенә килеп җиттек. Кыска гына булса да, бу турыда да аңлатып китүне кирәк табам. (Гомумән, бу бик кызыклы тема һәм тәнкыйтьчеләрнең хезмәтен көтә. Татар әдәбиятында моның өчен җитәрлек материал бар.)

Кайбер язучылар, бу сораулар барысы да матур әдәбиятның үзенчәлеген аңламаудан гына килә дип, мәсьәләне ансатлаштырып котылмакчы булалар. Ләкин мәсьәлә җитдирәк һәм катлаулырак. Менә бер үк журналда бер үк вакытта диярлек ике роман басыла: «Ак чәчәкләр» һәм «Муса». Тегесе дә, монысы да роман дип аталган.

Муса Җәлилнең реаль кеше икәнен бөтен дөнья белә. Ул романдагы бүтән күп кенә геройлар да чын кешеләр. Шуның янына укучыларга мәгълүм «Яшь гвардия» романын, «Чын кеше» повестен, «Лиза Чайкина», «Александр Матросов», «Газинур», «Мәңгелек кеше» әсәрләрен китереп кушыгыз. Шулар янына тагын геройлары реаль тормыш кешеләре булган бүтән йөзләрчә китапларны кушыгыз. Бәс шулай булгач, «Ике буйдак»ның да, «Гомер ике килми»нең дә, «Бала күңеле далада»ның да, «Ак чәчәкләр»нең дә геройлары нигә тормыштан алынмаска, ягъни реаль кешеләр булмаска тиеш ди? Тәҗрибәсе һәм белеме җитенкерәмәгән укучы өчен бу сорау бер дә гаҗәп түгел. Аннары сорау бирүчеләрнең күбесе геройларның прообразларын күз алдында тоталар бит.

Монысы мәсьәләнең бер ягы гына, әлбәттә. Иң мөһиме, әдәби образлар ничек туалар, Л. Толстой әйтмешли «миллионның бере» ничек табыла, ничек иҗат ителә? Монысы инде язучының иҗат лабораториясенең ишеген кагу була. Язучылар бу турыда үзләре сөйләргә яратмыйлар, мин дә артык тирәнгә кермәскә тырышачакмын. Чөнки четерекле яклары бик күп.

Теге яки бу әсәрне язу теләге кинәт кенә тумый, образлар берьюлы тулы канлы һәм тере булып күз алдына килеп басмый. Барысы да әкренләп, озаклап һәм, дөньяга туа торган һәрнәрсә шикелле, каты газап белән туалар. Сугышка кадәр мин авырмадым һәм авыруның нәрсә икәнен дә белми идем. Беренче тапкыр врачлар кулына фронтта, яралангач эләктем һәм шунда бу профессия кешеләренә беренче мәхәббәтем уянды. Ул мәхәббәт, күрәсең, шактый көчле булган, мин беренче романымда ук врач образын тудырырга омтылып карадым. Ул «Алтын йолдыз»дагы военврач Мөнирә образы иде. Мөнирә образы, әдәби эшләнеше җитәрлек булмаса да, минем иң яраткан образларымның берсе. Ул Гөлшәһидәнең бертуган апасы дип әйтергә ярый. «Газинур» романын язганда мин янадан врач образын бирергә тырыштым — ул Катя Бушуева иде. Күрәсең, бу ике образ гына минем врач турындагы хыялымны канәгатьләндермәгән. 1955 елда авылдашым һәм якын дустым атаклы хирург Әхмәт абый Айдаров турында очерк язу нияте белән Әгерҗе тимер юл больницасына киттем. Байтак вакыт Әхмәт абый янында кунак булып, аның больницасында йөреп, ул ясаган операцияләрне карап, уннарча авырулар белән сөйләшеп, күңнәремне үткәрдем. Әмма Әхмәт абый турында очерк яза алмадым. Ә Әгерҗедән кайткач, врачлар турында берәр зуррак нәрсә язу теләге көчәйде. Ләкин ул арада «Сүнмәс утлар» белән мавыгып киттем һәм ул «утлар» минга бик кыйбатка төште. Һәдия әйткәнчә, юри түгел, чын-чынлап авырып больницага эләктем. Шунда мин үземне «иҗат командировкасында» итеп хис иттем һәм больницадан Татарстан язучыларының IV съездына җибәргән хатымда да шулай дип язган идем. Больницадан чыкканда, калын бер дәфтәр шушындагы күзәтүләр белән тулган иде. Бернича елдан соң янадан йөрәк чыгымлый башлады. Нәтиҗәдә янадан больница койкасы һәм янадан калын бер дәфтәр күзәтүләр. Һәм булачак геройлар күз алдына ачыграк, конкретрак итеп килеп бастылар. Өченче тапкыр больницада ятканда, «Ак чәчәкләр» язылып беткән иде инде. Шушы ук больницада эшләүче врач Диләрә ханым Хаджаева романны укып чыкты, аннары икенче бер больницада эшләүче терапевт Зөмәрә ханым Зарипова укып чыкты. Әмма минем төп консультантым һәм миңа ярдәм итеп торучы кеше Әхмәт абый Айдаров булды. Романны укучы башка врачлар арасында аның улы — яшь хирург Марат Айдаров та бар иде. Профессор Әбүбәкер абзый Терегулов белән без бер палатада яттык һәм... дуслашып киттек. Әмма аңа роман язарга теләгем барлыгын ул чакта әйтмәдем. Әгәр белгән булса, ул миңа бернәрсә дә сөйләмәгән булыр иде. Аның сөйләгәннәрен мин үзенә күрсәтмичә генә язып бардым. Мин беренче тапкыр больницада ятканда да, икенче һәм хәтта өченче тапкыр ятканда да атаклы артист Николай Иванович Якушенко белән бергә туры килдем... Кыскасы, Казанда яшәүче һәм медицина эшчеләре белән беркадәр аралашучы иптәшләр әсәрнең прообразларын азмы-күпме төсмерлиләр. Хәтта урамда туктатып бу турыда әйтәләр, кайберәүләр исә бөтенләй мин күздә тотмаган кешеләргә дә юрыйлар. Әмма иҗат эшендә иң кыены, иң авыры прообраздан образга бару юлы. Бу юл бик катлаулы, бик сикәлтәле һәм шулхәтле үзгәрүчән, кайчакта прообразлардан бернәрсә дә калмый диярлек. Һәм моны аңлатуы да бик читен, чөнки бу ничектер үзеннән-үзе эшләнә, кайдадыр акыл артында эшләнә дип әйтсәм, әллә нәрсәләргә юрарга урын кала кебек. Шуңа күрә фикеремне ачыклар өчен бер

мисал китерим. Менә җиргә яңгыр тамчылары төшкән. Менә алар бу булып яңадан һавага күтәрелә, кайдадыр, ниндидер хәрәкәтләр ул тамчыларның буларын бергә җыя, укмаштыра, температурасын, сыйфатын үзгәртә, ниндидер җилләр аларны каядыр алып баралар. Аннары яңадан яңгыр ява. Иҗат эшендә дә шуңа охшашлырак бернәрсә була. Хәтта мин әйтер идем, иҗат эше катлаулырак та, серлерәк тә. Син героеңның прообразын тапкансың, ләкин ул әле образ түгел. Ул образ булсын өчен тагын шуның ише уннарча, йөзләрчә прообразларның сыйфатлары кирәк. Сиңа гүя образ иҗат итәр өчен бер мәрмәр кисәге тоттырганнар. Шушы мәрмәр кисәгеннән конкрет прообразның сурәтен тудырыр өчен таштагы бөтен артык кисәкләрне алып ташлау да җитә. Әмма образ тудырыр өчен мондый хезмәт кенә аз, образ тудырыр өчен тагын да зуррак хезмәт салырга кирәк, чөнки анда бөтенләй яңа сыйфатлар, яңа чалымнар килеп чыга. Ничек, нинди юллар белән эшләнә бу? Моны фәкать язучының бетмәс-төкәнмәс караламаларын җентекләп өйрәнгәндә генә ачыкларга мөмкин. Бездә исә, кызганычка каршы, язучыларның караламалары җыелмый, без аларны язабыз да ертып кәрзингә ташлыйбыз. Шулай итеп, бик күп образларның туу серләре мәңгегә югала (кабатлап әйтәм, язучы моны соңыннан бөтен нечкәлекләре белән сөйләп бирә алмый, чөнки иҗат иткән чагында ул боларны теркәп бармый). Серләр бозгаланган, сызгаланган, яңадан өстәлгән, яңадан мең кат сызылган, бозылган һәм өстәлгән сүзләр, юллар эчендә яшеренеп кала. Образ тууның серен ачканда, әнә шул бозылган, сызылган, өстәлгән барлык сүзләрне, юлларны яңадан торгызырга, аларны җентекләп өйрәнергә, чагыштырырга, очраклыларын ташларга һәм шушы бик авыр хезмәттән соң гына теге яки бу образның ничек тууын күрсәтергә мөмкин. Рус әдәбиятында моның мисаллары бар. Кызыксынучы иптәшләр, мәсәлән, Анна Каренина образының ничек барлыкка килүе турында укый алалар.

Пушкин бер вакытны: «Бу Татьяна мине кызык итте әле, кияүгә чыгып куйды», дип әйтә. Нәрсә бу, бөек шагыйрьнең шаяруымы? Юк, бу иҗат процессының иң мөһим законнарының берсе — характер логикасы турында кисәтү. Укучыларның үтенечләре дә булгач (Гөлшәһидә белән Мансурны кавыштыру турында), бу турыда да беркадәр аңлатып китүне кирәк дип табам.

«Ак чәчәкләр»не уйлап йөргәндә, Мансур белән И[illegible]ираны өйләнештерергә һич ниятем юк иде, Мансур Диләфрүзгә өйләнер дип хафаланмадым, ә менә Диләфрүзнең аның тәкъдимен кире кагарга көче җитмәс дип бик каты борчылдым. Ә Гөлшәһидә Яңгурага кияүгә чыгып куймагае дип, роман тәмам булганчы котым алынып торды! Ә кайбер укучылар язучы үзенең геройларын теләсә нишләтә ала дип уйлыйлар. Юк шул, художество дөреслеген дуамалланып бозмаганда, җимермәгәндә язучы үз геройларын теләсә нишләтә алмый инде, чөнки алар язучының колы түгел, алар ирекле, җанлы кешеләр, аларның үз үсеш законнары, үз юллары, үз характер логикалары бар. «Сүнмәс утлар»дагы ике башлы Сөләйман абзый, романга килеп кергәч, минем алдан корган барлык планнарымны җимереп ташлады, чөнки алар аның өчен тар иде. «Алтын йолдыз»дагы сөйкемле һаҗәрнең үлеме өчен әле дә йөрәгем әрни, шулай ук Әбүзәр абзыйның үлеме турында язганда күземдә яшь иде. Хәтта Әбүзәр абзыйның прообразы исән булган хәлдә шундый хәл килеп чыкты бит! Хәзер бик күпләр, бигрәк тә Әбүзәр абзыйның прообразын белгән кешеләр, нишләп сез болай эшләдегез дип миңе әрлиләр. Художество дөреслеге шулай таләп иткәч, минем бүтән чарам калмады. Тагын да ачыграк итеп әйткәндә, эш болай тора: дөрес художество образы гына әдәбиятта мәңге яши. Мин Әбүзәр абзый образын әдәбиятыбызда озак яшәсен дип иҗат итәргә тырыштым.

Инде ни өчен Гөлшәһидә мине шулкадәр борчыды? Укучылар дөрес сиземләгәннәр, мин Гөлшәһидәне бик яратам, ә яраткан кешең, гәрчә ул бер әдәби образ гына булса да, күбрәк борчылырга мәҗбүр итә.

Мәсьәлә ачыклансын өчен, башта Мансур һәм Яңгура турында берничә сүз әйтергә кирәк. Чөнки бу өч кешенең язмышы бер-берсенә бик нык үрелгән һәм алар арасындагы конфликт та аларның характерларыннан туа. Мансур, мисал өчен генә гадиләштереп әйткәндә, акыл һәм бурыч кешесе (бурыч дигәне бу урында долг мәгънәсендә), Яңгура коры исәп кешесе, Гөлшәһидә хисләр кешесе. Федосеев дамбасындагы мәгълүм вакыйгалардан һәм кичерешләрдән соң, җәйге матур кичләрнең берсендә Мансурның күңеле дә кузгала башлый, ул Гөлшәһидәне кочып ала, үбә. Соңыннан

ул курка, чөнки аның хисләре Гөлшәһидәнеке кебек гөрләп ташып китә алмый (һәр кешедә дә мәхәббәт бер үк вакытта кабынмый бит, хәтта бер үк төрле агачлар да берсе алданрак, берсе соңрак чәчәк ата). Яхшы мәгънәдә интеллигентный семьяда һәм хатын-кызга тирән хөрмәт һәм намуслылык принципларында тәрбияләнгән Мансур Таһиров үзе тирәнтен ихтирам иткән кызны — Гөлшәһидәне алдарга теләми, чөнки тигез мәхәббәт булмаганда, яхшы семья, бәхетле семья булмавы турында ул күп укыган, күп ишеткән. Шуңа күрә ул, яшьлеге һәм тәҗрибәсезлеге аркасында, үз халәтен һәм хисләрен дә аңлап бетермичә, бүтән рәтле чара да тапмагач (Гөлшәһидәгә турыдан-туры әйтергә көче җитми, чөнки күңелендә әле үзенә дә аңлашылып бетмәгән тагын нәрсәдер бар һәм ул бу чаткыны сүндерергә теләми, вакыт ихтыярына калдыра), Гөлшәһидәне «азат» итәр өчен кая булса китүне артыграк күрә, әмма төньякта ул Гөлшәһидәне оныта алмый, ул өн шикелле якын да, ерак та. Дәү әнисе кисәтеп тә куйгач, Мансур Илмирадан саклана. Ләкин Илмира аның муенына тагылырга омтылмый, ул, вак җанлы кайбер хатыннар кебек, ир эзләми. Менә шул намуслылыгы белән ул тора торгач Мансур каршында тирән хөрмәт казана. Ниһаять, алар төньякта бер авыруны коткарырга баралар. Авария вакытында Илмира яралана. Мансур аңа операция ясый һәм соңыннан аның баш очында утырганда кулы белән Илмираның маңгаена кагыла. Илмира аның кулын тотып яңагына кыса... Илмирага өйләнгәннән соң да Мансур Гөлшәһидәне оныта алмый, тик ул ераграк, томан эченәрәк чигенә, ләкин чак кына томан тарала башлауга калкып чыга. Әгәр Илмира һәлак булмаса, Мансур аңа хыянәт итмәс иде, ул аңа мәңгегә турылыклы булып калыр иде, чөнки алдашырга вөҗданы кушмый аның. Ә Гөлшәһидәне кабергәчә хыялында йөртер иде. Ләкин тормыш Мансурны яңа сынаулар алдына куя. Илмира һәлак булып, Мансур Казанга кайткач, аның юлында Илһамия калкып чыга. Илһамия яктысында Мансурның Гөлшәһидәгә булган хисләре инде чынлап торып кузгалып, ачыкланып китә. Хәер, болары бар да әчтә генә була, бүтәннәргә күренми, беленми. Шуңа күрә дә укучылар хаклы рәвештә нигә бу Мансур хатын-кызга карата бу кадәр салкын дип сорыйлар. Хәлбуки, әш салкынлыкта түгел, әш Мансурның холкында. Яңгура исә югарыда әйткәнебезчә, коры исәп кешесе, ул мәхәббәтне бар дип тә белми, хатын-кызга мөнәсәбәте дә аның эгоистлыгыннан ургып чыга. Шуларның барысы өстенә ул шактый мәкерле дә әле, төсен дә бик шәп алмаштыра белә. Менә шуңа күрә дә йөрәк хисе белән әш итүче Гөлшәһидә, үзенең мәхәббәт уңышсызлыгыннан соң, Яңгураның тозакларын сизмәс, аның җәтмәсенә үзе барып керер дип курыккан идем. Йөрәк бит ул бүген болай, иртәгә тегеләй. Аңа нинди закон бар? Татьяна Пушкиннан рөхсәт алмыйча гына кияүгә чыккан икән, нигә шуны ук Гөлшәһидә дә эшләмәскә тиеш ди...

Нокта куяр алдыннан тагын бер хатның ахырына күз салыйк әле. Яңа Балтач (Башкортстан) почта бүлеге эшчесе Наилә Корбанова хатының ахырында безгә бөтен почта коллективы исеменнән кайнар сәлам тапшыра һәм почта бүлегендә «Казан утлары»н яратып укуларын әйтә. Алар үзләре генә укып калмый, журналны подписчикларга тизрәк җиткерергә тырышалар, журналны халык арасында пропагандалыйлар, аңа подписка җыюны оештыралар икән. Моның өчен аларга мең рәхмәт. Быел да алар шул изге эшләрен дәвам иттерерләр дип ышанабыз. Әгәр дә илебездәге барлык почта бүлекләре дә Яңа Балтачтагы шикелле эшләсә, «Казан утлары»ның тиражы бермә-бер артыр иде. Кызганычка каршы, бездә әле «Казан утлары»на язылырга килгән кешеләрне дә, андый журнал юк, дип кире борып җибәрү фактлары булгалый. Без ышанабыз, быелгы подписка кампаниясе вакытында укучылар үзләренең сөекле журналларын таратуда җиң сызганып эшләрләр, халыкка рухи азыкны күбрәк бирергә булышырлар һәм үзләре дә журналга беренче булып язылырлар.

...Башлаганда башлый алмыйча аптырап беткән булсам, инде тәмамлый алмыйча интегәм. Күрәсең, сөйләшәсе сүзләр дә күп, сөйләшү тәҗрибәсе дә житенкерәп бетми, әле бер якка, әле икенче якка сугыласың һәм адәм аңларлык бернәрсә дә әйтеп булмый кебек. Шулай да беренче адымның атлануы хәерле. Моннан соң түгәрәк өстәл янына ешрак утырыйк. Коммунизм төзүче халык алдындагы бурычлар үсә барган саен, әдәбият һәм сәнгать алдындагы бурычлар да катлаулана бара. Халыкны коммунистик идеялелек һәм матурлык рухында тәрбияләү көннең иң актуаль бурычы булып кала. Бу бурычны кулга-кул тотынып эшләгәндә генә хәл итәргә мөмкин.

## *М. Җәлил юбилеен каршылап*

# МУСА ТУГАН ЯКЛАРДА

## *(фоторепортаж)*

*Оренбургтан 150 километр ераклыкта, әби патша заманында салынган борынгы зур тракт буенда Мостафа авылы урнашкан. Тракт буенча үтеп баручы юлчының игътибарын авылның үзәк һәм иң калку җирендә биек ак постаментка куелган мәһабәт бюст үзенә тарта. Муса Җәлил... Әйе, иксез-чиксез Оренбург далалары арасында урнашкан һәм башка бик күп авыллардан бер ягы белән дә аерылып тормаган гади генә бу авылда моннан 60 ел элек татар халкының хәзер бөтен дөньяга билгеле булган патриот-шагыйре Муса Җәлил дөньяга килгән.*

*«Безнең әтинең атасы — Әбүбәкер бабай — авылның көтүчесе булган. Аның биш-алты баласы үскән. Икмәккә дә туеп тормаганнар. Әбүбәкер бабайның иң кече улы Мостафа — ул безнең әти — 8—9 яшендә үк кызыл мал кибетенә малайлыкка эшкә бирелә.*

*...Сату-алу эшендә безнең әти азмы-күпме акча туплаган һәм өйләнгәч, үзе дә кибет ачып сату итәргә ниятләнгән. Баеннан вексель белән бурычка акча алган һәм, Мостафа авылына кайтып, кечкенә бер бакалея кибете ачкан». — дип яза Мусаның абыйсы Ибраһим Җәлилов үзенең истәлегендә.*

*Ләкин турылыклы һәм хәйлә-алдауны белмәгән Мостафа абзый яхшы сәүдәгәр булып китә алмый. Күпме генә тырышса да аның сәүдә эшләре һаман кирегә тәгәри барган. Хәтта байдан вексель белән алган акчасын да кайтара алмагач, бурычын түләмәгән өчен, Мостафа абзыйны 2—3*



1 нче рәсем.

2 нче рәсем.






3 нче рәсем.



4 нче рәсем.

*айга долговой төрмәгә утырталар. Бөтен йорт-җирен, малларын саталар, кибетен ябалар. Аннары Мостафа абзый, семьясын ияртеп, Оренбургка күчеп китәргә мәҗбүр була.*

*2 нче рәсемдә — кайчандыр Мостафа абзый салган бакалея кибете нигезе. Аның өске катында ул заманнарда агач өй булган. Мусалар шунда торган. Хәзер монда авыл кибетенең склады.*



5 нче рәсем.

*Мостафа авылында Мусаны яхшы хәтерли торган, аның белән бергә үскән, бергә уйнап йөргән замандашлары, яшьтәшләре байтак.*

*Шуларның берсе, Мусаларның күршесендә генә торган Гобәйдә Даутова (3 нче рәсем) әле бүген дә Муса турында бик җанлы итеп, бирелеп сөйли.*

*— Муса кече яшьтән үк җыр-шигырь чыгарырга исткиткеч сәләтле иде, — ди Гобәйдә апа. — Авылда андый-мондый хәл булса, хәзер шуның турында җыр чыгарып өлгерә иде. Бервакыт безгә кергәч Муса мич артында таракан күргән, һәм шунда ул таракан турында да җыр чыгарган иде. Тик ул җыр хәзер минем исемдә калмаган.*

*Мусалар белән бергә спектакльләр куеп, пионер-комсомол эшендә катнашып йөргән Сәлимҗан ага Мөхәммәтев (4 нче рәсем) моңача билгеле булмаган шундый кызыклы бер эпизод турында сөйли:*



6 нчы рәсем.

*— Бервакыт Мусалар үзләре оештырган кечкенә генә сәхнәдә театр уйныйлар. (Ул вакытта клублар булмый әле, клуб урынына бер ярлы тол хатынның өен файдаланалар.) Уен барышында Муса кинәт һушын югалтып идәнгә ава. Халык, моны пьеса буенча шулай кирәк дип уйлап, дәррәү кубып кул чабарга тотына. Ләкин Муса егылган җиреннән тормый. Аны күтәреп алып чыгып китәләр. Тик соңыннан гына Мусаның бик каты авырып киткәнлеге, шул авыру көенчә дә, спектакльне өзмәс өчен тырышып уйнавы һәм чын-чыннан аңын югалтып егылуы халыкка билгеле була...*

*Оренбургка килгәч, Мостафа абзый Хөсәения мәдрәсәсенә дворник булып урнаша. Муса да шул ук мәдрәсәгә укырга керә. Мусалар семьясы мәдрәсә ишек алдындагы подвалда яши башлый.*

*5 нче рәсемдә Мусалар яшәгән подвал тәрәзәләре (аста). Соңгы елларда подвалның тәрәзәләре бераз зурайтылган. Элек алар бигрәк тә кечкенә һәм караңгы булганнар.*

*«9—10 яшьләргә җиткәндә инде Мусаның ул вакыттагы татар әдәбиятыннан укымаган китабы калды микән? Калмагандыр. Чөнки «Белек» китапханәсендә аңа бирергә китап таба алмый аптырый торганнар иде. Барысын да ул белә, укыган булып чыга иде». (Мәрьям Сәйфетдинова истәлегеннән.)*

*6 нчы рәсемдә элек «Белек» китапханәсе урнашкан йорт (аскы катта). Соңыннан бу китапханәгә Хөсәен Ямашев исеме бирелә һәм ул башка бинага күчерелә.*

Р. МОСТАФИН тексты һәм фоторәсемнәре.

## *Хәй Хисмәтуллинга 70 яшь*

# ХЕЗМӘТТӘ ЯУЛАНГАН ХӨРМӘТ

*Күренекле әдәбиятчы, галим Габделхәй ага Хисмәтуллинга җитмеш яшь тулды. Җитмеш җәй, җитмеш кыш: никадәр якты таңнар, йолдызлы төннәр, давыллар, өермәләр узган. Аның күзләре күпне күргән, йөрәге күпне кичергән, ул һәрвакыт үз халкы белән бергә яшәгән. Гомер буена гыйлем эстәгән бу олы йөрәкле кешенең акылы күпне белә, күңеле күпне хәтерли.*

*Ул Габдулла Тукайның ялкынлы сүзләрен тыңлаган, кичләрендә авыру Фатих Әмирхан янында утырган, Мәҗит Гафури белән чәй эчкән, Г. Ибраһимовның фатихасын алган, ярсу йөрәкле Г. Кутуй белән бергә эшләгән, Ш. Мөдәррриснең беренче шигырьләренә юл күрсәткән... Татлы истәлекләр калдырып, матур еллар үткән. Ул хәзер дә татар культурасының алдынгы көчләре, язучылары, фән эшлекләләре белән бер сафта атлый һәм үзе дә танылган әдәбиятчы, галим.*



*Илле еллык иҗат гомерендә Габделхәй ага Хисмәтуллин тарафыннан татар теле һәм әдәбияты буенча ничәмә-ничә дәреслекләр, методик кулланмалар язылган, хрестоматияләр төзелгән. Арада М. Корбангалеев, Г. Алпаров, Ш. Рамазанов кебек күренекле тел галимнәре белән берлектә язылган хезмәтләре дә байтак.*

*Каюм Насыйрилар, Тукай, Гафурилар тарафыннан күтәрелгән мәгърифәтчелек идеяләре белән рухланып, «Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә» дигән якты өметләр, изге теләкләр белән канатланган яшь шәкерт, башында рухани ата торган кадимче семья таләпләренә каршы килеп, караңгы татар авылында мөгаллим булып эшли башлый, беренче көннәреннән үк революциягә, халыкка турылыклы хезмәт итү юлына баса һәм ул әле дә шул юлдан туры атлый. Аның, укытучы булып, беренче мәртәбә мәктәп ишеген ачуына нәкъ илле ел. Никадәр нәниләрнең язмышы күңел түреннән үткән, балалар йортларында эшләү елларында никадәр үксезләргә йөрәк җылысы бирелгән! Гомер бушка узмаган— барлык көч яңа дөнья кешесен тәрбияләү эшенә бирелгән.*

*Габделхәй аганың халык мәгарифе, культурасы, фән эшенә багышланган хезмәтләре күп, аларның колачы киң. СССР Фәннәр Академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында гына да ул егерме биш елдан артык вакыт эшләп килә. Татар классик әдәбиятын барлауда һәм фәнни нигездә бастырып чыгаруда Габделхәй ага күп көч куйган кеше. Г. Тукай, М. Гафури, Ф. Әмирхан кебек классик әдипләребез әсәрләренең академик басмаларын хәзерләүдә ул зур активлык күрсәтте. Г. Камалның драматургиясенә багышланган хезмәте өчен аңа филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә бирелде. Ул аерым язучыларның иҗатларына карата шәхес культы заманында, вульгар социологизмнан һәм субъективлыктан чыгып бирелгән ялгыш карашларны, бозуларны төзәтү буенча да күп эшләр башкарды. Аның Ф. Әмирхан иҗаты турындагы хезмәтләре моның ачык мисалы. Соңгы елларда татар һәм рус телләрендә чыккан «Совет чоры татар әдәбияты» һәм «Борынгы татар әдәбиятыннан дәреслек-хрестоматия» дигән фәнни хезмәтләрдә Хәй аганың өлеше зур. Ул мәшһүр тарихчы, галим Ш. Мәрҗаниның «Сайланма әсәрләре»н, шагыйрь Сайядиның «Бабахан дастанын» («Таһир белән Зөһрә кыйссасын») басарга әзерләде. Татар әдәбиятын, аның язучыларының әсәрләрен халыкка җиткерүдә ару-талуны белмәгән бу тынгысыз кеше һаман да эш өстендә, кешеләргә игелекле хезмәт күрсәтә торган мактаулы юлда.*

*Габделхәй ага гаять тыйнак, югары культуралы, сизгер кеше. Ул үзе белән бергә эшләгән коллективның һәр уңышына чын күңелдән сөенә, аның кечкенә кимчелекләренә дә көенә, борчыла. Ул тормышка гашыйк, аның үткән юлы саф һәм шуның өчен ул шат. Әйтерсең, Габдулла Тукай Габделхәй аганың җитмеш яшьлек вакытын алдан белеп язган:*

Бабай бик күп яшь яшәгән, карт ул үзе,
Ләкин һаман сәламәт ул, матур йөзе...
Яшьләрчә саф, ачык чыга аның сүзе.

***Ш. Абилов.***

# КИТАП БӘХЕТЕ

*Бу юлларның авторы Бөек Ватан сугышы елларында Арча районы «Кызыл йолдыз» колхозы председателе урынбасары, аннары Наласа МТСы партия оешмасы секретаре булып эшли. Сугыштан соң партия райкомы аны китап кибетенә эшкә җибәрә. Ул бик күп еллар Арча китап кибетендә сатучы һәм мөдир була, ә хәзер Арча райпотребсоюзының китап буенча товароведы.*

*Китап — гаять зур көч*

*В. И. ЛЕНИН*

Минем алда китаплар, китаплар, китаплар... Аларны укыган саен тормыш офыклары киңрәк ачыла, моннан бернечә мең еллар элек булып үткән вакыйгалар, көрәшләр, халык батырлары күз алдына килеп баса. Туган-үскән җирләрдәге хезмәт иярәренең элекке газаплы тормышын күңелдән кичереп, бүгенге матурлыкны күбрәк күрәсең, бүгенге якты тормышка шатланып туймыйсың. Китаплар алар үткәнне онытмаска, бүгенге матурлыкның кадерен белергә, киләчәкне күрергә өйрәтәләр.

Менә борынгы грек шагыйрьләреннән Эсхилның, Софоклның, Еврипидның безнең заманнарга килеп җиткән трагедияләре тупланган бер китап. Мин Эсхилның «Прометей» дигән трагедиясен укый башлыйм. Прометейны җәзалыйлар. Богауланган хәлдә таш кыяга терәп, башта аның бер кулын, аннары икенчесен, шуннан гәүдәсен, аякларын әлеге кыяга кадаклыйлар. Прометей әнә шул коточкыч авыр хәлдә дә җәзалаучылар алдында баш ими, үзен горур тота. Аны җәзага тарткан Зевска ул чирканып карый, нәфрәт яудыра. Палачларга, үлемгә җирәнеп караган һәм күңелләрдә мәңгемәңге сакланачак Прометей кем ул һәм анар коточкыч җәза биргән Зевс кем булган? Зевс — борынгы Грециядә барлык аллаларның да алласы булган икән. Башка бик күп аллалар ярдәмендә бердәнбер алла дәрәҗәсенә ирешкән Зевс, табигатьнең барлык байлыгы, тормыш, тереклек уты белән бары үзе генә файдаланган, башкаларга, бигрәк тә гади кешеләргә берни дә бирмәгән, аларны караңгылыкта, кыргый хәлдә, бәхетсезлектә яшәткән. Прометей бу хәлгә түзә алмый һәм Зевс бирмәгән күк Олимпы утын яшереп кенә алып, гади кешеләргә бирә, тормыш уты кабыза. Аларны Прометей шулай ук тау куышларыннан чыгара, хезмәт итәргә, кирпечтән йортлар салырга, кораблар төзергә, металлдан кораллар ясарга, укырга, язарга, дарулар белән файдалана белергә, бал чәчәкләрен, йолдызларны танырга, иҗат итәргә, кыскасы, Зевстан башка, кешечә яшәргә өйрәтә. Прометейның гади кешеләргә яхшылыклар эшләвенә ачуы кабарган Зевс, аны җәзага тартырга, кеше аяк басмаган кыргый сахрадагы таулар кыясына кадаклап куярга куша. Ләкин караңгылыкка каршы, яктылык өчен, гади кеше тормышын бәхетле итү өчен тырышкан Прометейга теләсә нинди авырлык та, теләсә нинди җәза да куркыныч түгел.

Моннан бернечә мең ел элек язылган һәм һәркемнең күңелен тетрәтеп, алдынгы прогрессив кешелек дөньясын сокландырып яшәгән бу әсәрнең кыска гына эчтәлеге әнә шундый. Коллар тарафыннан папирустан — папируска [1], кулдан күчерелеп, гасырлар аша сакланып безнең көннәргә кадәр килеп җиткән Прометей образы, «Прометей» китабы, кешелекнең уннарча буын алдынгы, кыю вәкилләрен халык бәхете өчен кара

[1] Папирус — борынгы халыкларда кыяк яфраклы тропик үсемлектән булган язу материалы.

көчләргә каршы үз-үзләрен аямыйча көрәшкә рухландырган. Менә шуңар күрә дә ул бөтен дөнья халыклары телләренә диярлек тәрҗемә ителгән һәм республикабыз хезмәт ияләре дә «Прометей»ны ана телләрендә укыйлар.

Кулыма тагын бер китап — бөек язучыбыз Алексей Максимович Горький томын алам. Аның «Изергиль карчык» әсәрен йотлыгып укыйм. Күз алдыма һич тә онытылмаслык Данко образы килеп баса. Менә бервакыт кара урманда халык юл таба алмыйча интегә, бөтен тирә-якны караңгылык баса, кешеләр һәлакәткә дучар булалар. Нәкъ шул чакта Данко, үз күкрәген ярып, йөрәген тартып ала. Аның йөрәге кинәт искиткеч якты ут булып, нурлар сибеп кабына һәм халыкны коточкыч караңгылыктан яктылыкка алып чыкканга кадәр юл күрсәтеп яна.

Прометей һәм Данко! Борын заманнарда иҗат ителгән Прометей да, әле егерменче гасыр башларында гына язылган Данко да аваздашлар. Алар халыкларның азатлыгы өчен ярсып көрәшүче образлар булып яшәп килгәннәр һәм яңа буыннарны да янадан-яңа бәхеткә өндәп яшәячәкләр.

Китап буенча товаровед итеп билгеләнгәч, миңа яңа китапларны тагын да күбрәк укырга, белемемне арттыру өстендә эшләргә, китап турында әйтелгән фикерләр белән тирәнрәк кызыксына барырга туры килә. Мин үземә-үзем: «Китап нәрсә?» — дигән сорауны әле китап сатучы булып эшли башлаганда ук биргән идем. Бу соравыма җавапны тулырак итеп башта бөек революционер-демократ А. И. Герценнан таптым.

Искәндәрне (А. И. Герценның кушаматы шундый булган) «җәмгыять өчен куркынычлы кеше» дип сөргенгә озаталар. Егерме өч яшьлек Герцен Вяткада (хәзерге Киров) халык китапханәсе оештыруда катнаша. Аның шул вакытта сөйләгән сүзләре бүген сөйләгән кебек яңгырый. Александр Иванович Герцен анда китапның әһәмияте турында менә нәрсәләр әйткән:

«Бу — бер буынның икенче буынга рухи васыяте, үлем алдындагы картның тормыш итә башлаган яшь кешегә киңәше, ялга китүче сакчының үзе урынына сакка басучыга боерыгы. Кешелекнең бөтен тормышы эзлекле төстә китапта яктыртыла барган: кабиләләр, кешеләр, дәүләтләр юкка чыкканнар, ә китап калган. Ләкин китапта тик узган заманнар гына чагылмый. Китап ул тир һәм кан түгеп, авырлыклар кичереп яулап алынган хаклык һәм тырышлык дөньясына, бүгенге көн хәзинәләренә алып керүче документ, китап ул киләчәкнең программасы. Шулай булгач, китапны яратыйк без!»

Китапның «бер буынның икенче буынга рухи васыяте» булуын раслау өчен мин иң элек заманыбызның бөек шагыйре Владимир Маяковский әсәрләрен, аның «Владимир Ильич Ленин» дигән поэмасы, совет паспорты турында һәм Америка турында язган әсәрләрен күрсәтер идем.

Владимир Маяковскийның тирән мәгънәле юлларын укып уйланып утырганнан соң, тагын бер калын китап, поэзия елъязмалары китабын — «Татар поэзиясе антологиясе» битләрен ачам. Моннан йөз еллар элек һәм яңа гасырда иҗат ителеп бу китапка урнаштырылган бәетләрдә, җырларда, йөздән артык шагыйрьнең иң яхшы поэтик әсәрләрендә азатлык дошманнарына каршы халкыбызның ачы нәфрәтен, көрәшчен батырлыгын, җиңүен, якты уй-теләкләрен кичереп дулкынланасың. Менә өлкән язучыбыз Нәкый Исәнбәтнең 1919 елда язган «Колчак фетнәләре» дигән бер шигыре. Бу шигырьдә Октябрь социалистик революциясе, яшь совет власте дошманы ак офицер, бугазын киереп, коммунистларны терелэй тотып күмәргә, аларга «коммунаны җир астыннан» эзләтергә әмер бирә. Шул чакта тоткыннарның берсе, башка коммунистларның уртак фикерен белдереп, яшен яшьнәгәндәй көчле тавыш белән: «Мә, үтер! Надан, кол!» дип түшен ача. Аннары:

Эстәк[1] үлмәс җир астына кергән белән,
Орлык үлмәс җир астына күмгән белән,
Уңдыручан җир шарында орлык уңар,
Күмгән саен бер орлыктан миллион туар! —

дип, хаклык эшенең, коммунистлар эшенең җиңәчәген әйтә, коммунистларның ярсулы сүзләрен революция дошманы өстенә бомбадай ташлый.

---

[1] Якты теләк, максат

Әйе, коллык, караңгылык, кыргыйлык һәм ачлык, ялангачлык богауларын өзеп азатлыкка чыккан халык «коммунаны җир астыннан эзләтергә» маташкан дошманнарын чәлпәрәмә китерде, тиңе булмаган бөек җиңүләргә иреште. Халкыбыз каны аккан азат Ватаныбыз җирләрендә социализм чәчәк атты.

Китаплар, китаплар, китаплар... Менә алар безгә Бөек Ватан сугышы батырлары турында сөйлиләр. Мин совет баһадиры генерал Дмитрий Михайлович Карбышев турында укыдым. Фашист баш кисәрләре сатылырга, Ватанына хыянәт итәргә теләмәгән өчен аны Маутхаузен лагеренда кышкы салкында ялангач килеш бозга катырып үтерәләр. Соңгы сулышында да ул: «Яшәсен Советлар Союзы!» дип, фашистларның җаннарын тетрәтә. Д. М. Карбышевның якты образы, хисе, уйлары Ватаныбыз, халкыбыз эшләрендә мәңге яшәр. Палач балтасы астында да Ватанына, халкына, азатлыкка дан җырлаган Муса Җәлилнең батырлыгын, «Моабит дәфтәре» китабын бөтен дөнья белә. Язучы Борис Полевойның Советлар Союзы Герое Александр Маресьев образын чагылдырган «Чын кеше турында повесть» китабы, Габдрахман Әпсәләмовның Александр Матросов батырлыгын кабатлаган, дошман дзотына күкрәге белән ташланып, сугышчан иптәшләренә юл ачкан Газинур Гафиятуллин турында язган «Газинур» романы... Бу китаплар — халкыбыз батырлыгының җанлы шаһитлары. Аларда совет халкының баһадир уллары һәм кызлары йөрәге тибешен, хәзерге заман Прометейларының, Данколарының йөрәк тибешләрен күрәсең.

Бөек революциянең давыл хәбәрчесе, совет халкының сөекле язучысы Алексей Максимович Горький, мәсәлән, үзендәге яхшы якларның барысына да китап уку аркасында ирешкән. «Китаплар, — дип язган ул, — акыл һәм йөрәккә дәрт биреп, мине черек сазлыктан күтәрелергә ярдәм иттеләр. Китапсыз мин, ахмаклык һәм әшәкелек белән гарык булып, шул сазлыкта батып калган булыр идем. Китаплар, минем алда дөнья офыкларын һаман киңәйтә барып, яхшыга омтылган кешенең никадәр бөек һәм гүзәл булуын, аның җир йөзендә күп эшләвен... сөйләделәр».

Китап ул кешенең көндәлек көче, юлдашы һәм иң якын дусты. Китапсыз үсүе, яшәве, алга баруы, дөньяны танып белеп, революцион юл белән үзгәртеп кору мөмкин түгел. Даһи юлбашчыбыз В. И. Ленин биш яшендә үк укырга, язарга өйрәнеп, китап укуын гомере буена дәвам иткән. Бик яшь вакытында ук инде ул Россиянең алдынгы революционер-демократ язучыларының барлык әсәрләрен диярлек укып чыккан. Н. Г. Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә?» дигән романын 14 яшендә үк яхшы белгән. Ә 15 яшендә Карл Маркcның «Капитал»ын өйрәнә башлаган. Ул В. Г. Белинский, М. Е. Салтыков-Щедрин, А. С. Пушкин, Н. А. Некрасов, А. С. Грибоедов, Н. В. Гоголь, Радищев һәм, гомумән, рус халкының барлык классик язучыларының әсәрләрен яратып укыган. В. И. Ленин шулай ук үзенең гаять тирән эчтәлекле, ялкынлы публицистик хезмәтләрендә классик әдәбияттагы Иудушка Головлев, Хлестаков, Молчалин, Ноздрев, Манилов, Собакевич һәм башка персонажларны дошманга каршы көрәштә бик еш файдаланган. Лев Николаевич Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» дигән зур әсәрен укыганнан соң, бу язучыны ул «рус революциясенең көзгесе» дип атаган. В. И. Ленин борынгы әдәбиятны тирән өйрәнгән һәм бөтен дөнья әдәбияты классик язучыларының китапларын үз телләрендә укыган, матур әдәбият яңалыклары белән якыннан танышып, кызыксынып барган. Бөек юлбашчыбыз әдәбиятның гомуми пролетар эше булуын әйткән, әдәбиятның, сәнгатьнең колач җәеп үсүе турында Октябрь социалистик революциясенең беренче көннәреннән үк кайгырткан. Аның күрсәтүе буенча, 1918 елның май аеннан 1919 елның маена кадәр булган бер ел эчендә генә дә Советлар Россиясендә классик язучыларның 115 исемдә 6 миллион том китабы бастырылып чыгарылган. В. И. Ленин барлык коммунистлардан югары культуралы, зур белемле булуны таләп иткән һәм «кешелек дөньясы эшләп чыгарган барлык байлыкларны белү белән зиһенеңне баеткanda гына коммунист булырга мөмкин»[1] дип язган.

Владимир Ильич Ленин васыятьләрен тормышка ашыра баруы нәтиҗәсендә, Советлар Союзы хәзерге вакытта китап бастырып чыгаруда дөньяда беренче урынны алып тора. «Правда» газетасы сүзләре белән әйткәндә, халкыбызның культура илчесе булараk, совет китабы бөтен дөньяда дан казанды һәм прогрессив чит ил китабының үсүе дә совет китабы йогынтысына нык бәйләнгән.

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басма, 31 том, 258—275 битләр.

# Казан артында кояш

Казан артында: Арча, Әтнә, Тукай-Кырлай, Күлле-Киме якларында китапка булган мәхәббәт иң элек халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай шигырьләреннән башлана. Балалар аның искиткеч матур «Туган тел» җырын әти-әниләреннән, абый-апаларыннан әле бик кечкенә чакларында ук отып алып җырлыйлар:

И туган тел, и матур тел — әткәм-әнкәмнең теле,
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән...

Ә мәктәпкә йөри башлагач инде аның «Бабай», «Бала белән күбәләк», «Мәктәптә», «Бишек җыры», «Карлыгач», «Сабыйга», «Эш беткәч, уйнарга ярый» һәм башка шигырьләрен ятлап, балаларның күңелләре күтәрелә һәм алар үзләрен яз көннәрендә кояшка үрелгән гөлләр кебек хис итәләр. Габдулла Тукай шигырьләре аша мәктәп балалары шулай ук бөек рус халкының А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтов кебек шагыйрьләре, Л. Н. Толстой кебек титан язучылары, көнбатыш илләрнең Байрон, Шиллер, Гете кебек классиклары белән танышалар. Шулай итеп, туган телгә, кешелеккә, дуслыкка мәхәббәт белән язылган Г. Тукай әсәрләре, Г. Тукай китаплары туганыбыз рус халкы әдәбиятына, бөтен дөнья әдәбиятына тәрәзә ача, тирән мәхәббәт тәрбияли. Бөек шагыйребез үзе дә күп укыган һәм эче пошып рухы төшкәндә, җанына җылы таба алмаган чакларда яхшы китап аның өчен зур юаныч булган:

Шул вакытта мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам;
Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,
Шуннан гына дәртләремә дәрман табам.

Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем
Була минем юл күрсәтүче йолдызым;
Сөйми башлыйм бу дөньяның ваклыкларын,
Агыладыр, нурланадыр күңлем, күзем.

Җиңелләнәм, мәгъсумланам мин шул чакта,
Рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка,
Ышанычым арта минем үз-үземә,
Өмит белән карый башлыйм булачакка, —

дип дулкынланып яза ул, китапка югары бәя биреп.

А. С. Пушкиннан һәм М. Ю. Лермонтовтан үрнәк алып үскән Кушлавыч җире егете Г. Тукай, татар совет әдәбияты, милли формалы, социалистик эчтәлекле татар әдәбияты чәчәк атуына әйтеп бетергесез зур йогынты ясады һәм ул киләчәктә дә сүнмәс кояшыбыз булып балкыр.

Г. Тукай туган яклар хәзер таныргысыз та түгел. Эре хуҗалыклы, бай техникалы колхозларда һәм совхозларда намуслы хезмәт кайнап тора. Якты мәктәпләрдә коммунизм төзүче яңа, яшь көчләр тәрбияләнә. Кичләрен культура йортлары, клублар, китапханәләр халык белән тула. Өйләрдә электр утлары яна. Авылларда югары һәм урта белемле кешеләр хезмәт итә. Бездәге инженерларны, техникларны, агрономнарны, укытучыларны, тракторчылар, комбайнчылар һәм шоферларны, авыл хуҗалыгының төрле өлкәләрендә эшләүче белемле һөнәр ияләрен һәм, Казанда гына түгел, Мәскәүдә дә дан тоткан музыкантларны, җырчыларны санап бетергесез. Безнең якларда язучылар да үсеп чыктылар. Үзенең «Намус» романы белән бөтен Советлар Союзына һәм хәтта чит илләрдә дә танылган Гомәр Бәширов, шулай ук романнары, повестьлары, хикәяләре белән киң укучылар массасына билгеле Рафаил Төхфәтуллин, Гариф Ахунов кебек язучылар, Сибгат Хәким, Мостафа Ногман, Самат Шакир, Нәҗип Мадьяров кебек шагыйрьләр республикабыз әдәбияты үсешенә сизелерлек өлеш кертәләр, илебез

партиябез тарафыннан куелган бөек бурычларны үтәү өчен кэрәштә халкыбызны яңадан-яңа уңышларга рухландыруда ярдәм итәләр.

Хезмәт ияләренең тормыш-көнкүреш шартлары яхшыруы, культура дәрәҗәсенең үсүе аларның әдәбиятка, сәнгатькә булган сорауларын да бик нык күтәрде. Менә шуңа күрә дә безнең якларда хәзер шәхси китапханәсе булмаган гаилә юк диярлек.

Безнең Арча райпотребсоюзы магазиннары һәм бүлекләре соңгы берничә ел эчендә генә дә 350 мең сумлык китап саттылар. Бу урында мин, «Өч йөз илле мең сум» дип әйтүдән элек, меңнәрчә кешегә меңнәрчә китап сатылуын басым ясап әйтер идем. Чөнки коммунизм төзүче кешеләрнең акылларына һәм йөрәкләренә дәрт бирүче (М. Горький) китапларның бәясен акча белән генә билгеләп буламы соң? Халыкның әдәбиятка, китапка булган мәхәббәтен, культура дәрәҗәсе өзлексез үсүен меңнәр яки миллион сумнар гына түгел, миллиардлар белән дә бәяләп булмый. Меңнәрчә кешегә сатылган меңнәрчә китап бу иң элек рухи байлык артуын раслаучы факт. Ул колхозчының, механизаторның, авыл интеллигентының яңача, җирне фән кушканча эшкәртүгә, уңышны фән кушканча яулауга, Ватаныбыз табынына муллык өстәүгә омтылуын күрсәткән факт.

Безнең як колхозлары белән хәзер югары белемле председательләр җитәкчелек итә, авыл хуҗалыгының һәр өлкәсендә агрономнар, зоотехниклар, ветврачлар, инженерлар эшли. Алар шулай ук башкаларны да белемгә, яңалыкка рухландыралар, колхозчыларның масса күләмендә укулары белән җитәкчелек итәләр.

Фән һәм техника, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары, укымышлыларның, язучыларның, новаторларның әсәрләрен укучыларга җиткерү бурычы йөкләтелгән кешеләр буларак, авылдагы бу зур борылышлар безне дә яңача эшләүгә рухландыра.

Әйе, безгә дә искечә эшләү, кечкенә генә бер кибеттә прилавка артында нинди китап бар, шуны ашыкмыйча гына, тыныч кына сатып утыру заманнары үтте. 1953 елдан соң илнең яңа күтәрелеше, яңа шартлар халыкка китапларны җиткерүдә дә яңача эшләүне, иҗади эшләүне таләп иттеләр. Дөрес, безнең Арча китап кибете чыннан да бик кечкенә прилавкалы, анда кеше керсә борыла алмый иде. Китапларны кирәкчә китереп саклар өчен аның рәтле урыны, склады да булмады. Шуның өстенә, кибеттә яңа мөдир буларак мин дә, сатучы Бибинур Җамалиева да китап сату эшенә алдан әзерләнгән, махсус мәктәп бетергән кешеләр түгел идек. Безгә бик нык тырышырга туры килде. Безнең эшебезгә район партия оешмасы җитәкчеләре, комсомол оешмасы һәм райпотребсоюз да ярдәм итә башладылар. Эшебезне яхшырту турында без шулай ук китап сатуда тәҗрибәләре зур булган Казандагы иптәшләр белән дә киңәштек. Кибеттәге прилавканы бетереп, сатып алучыларга кирәкле китапларын үзләре сайлап алырлык уңай иттек. Арча промкомбинатында, педагогия училищесында, механизаторлар мәктәбендә берничә тапкыр булып, укытучылар, эшчеләр, китап сөючеләр белән сөйләштек. Кибеттә сату эшен дәвам итү белән бергә, әле беребез, әле икенчебез, авыллардагы бүлекчәләргә, китапханәләргә, мәктәпләргә барып, алардагы хәлләрне, китапка булган сорауларны белдек һәм ныклы элемтә урнаштырдык. Безнең кибеткә китапка актив подписчиклар туплана башлады. Үзебез дә яңа романнарны, повестьларны, хикәяләр һәм шигырьләр җыентыкларын тагын да күбрәк укырга, әдәбият яңалыкларын яхшы белеп барырга тырыштык. Болай эшләү безгә яңа китапларны укучыларга тәкъдим итүдә нык ярдәм итте. Шундый чаралар аркасында безнең эш ярыйсы гына көйләнә төште, сату планы үтәлә башлады, ләкин болар зур эшнең башлангычы гына иде әле. Алда тагын да тырышыбрак эшләү бурычлары куелды. Районның партия һәм комсомол оешмасы, урыннардагы коммунистлар активлары ярдәмендә без яңа китапларны йөреп сату эшенә керештек. Арча предприятиеләрендә, зур оешмаларда, авылларда сатучысыз өстәлләр — халык киоскылары оештырдык. Авыл китапханәләрендә теге яки бу язучының яңа басылып чыккан китабы турында укучылар конференцияләре оештыру, әсәрләрне коллектив уку, ә җәйге эш көннәрендә авыл китапханәләре эшчеләренең яңа китаплар белән кырларга, фермаларга барулары да шулай ук китапка булган сорауны, мәхәббәтне үстерүдә, яңа әсәрләрне һәр семьяга җиткерү бурычын аңлатуда бик нык ярдәм итте. Арча районының Пөшәңгер авылы китапханәсе мөдире Мәмдуха Муллахметова бу турыда менә болай сөйли:

— Колхозчыларны җәй көнендә китапханәдә сирәк очратасың. Механизаторлар иртә таңнан төнгә кадәр кырда эшлиләр, ә сыер савучылар һәм көтүчеләр җәйләүләрдә

күп сөт өчен көрәшәләр. Әйе, авыл хезмәтчелләре өчен кызу эш вакыты. Шуны истә тотып, мин, китапханә советы членнары белән киңәштем дә, кулыма совет шагыйрьләренең яңа китапларын алып, җәйләүгә, сыер савучылар янына киттем.

Без анда терлекчеләр йортын бизәдек. Сыер савучыларның эш тәҗрибәсен һәм күрсәткечләрен яктырткан почмак булдырдык. Алдынгы савучы Мәгъмүрә Сәләховага багышлап стена газетасы чыгардык. Анда алдынгы терлекчегә карата язылган шигырь дә урнаштырылган иде. Сыер савучылар аны укыдылар да: «Мәмдуха апа, бу шигырьне үзегез яздыгызмы?» — дип сорадылар. Әйе, мин аны үзем язган идем һәм ул шагыйрьләрнекечә үк булмаса да, ярыйсы гына чыккан иде. Мин шушы уңайдан поэзия турында сүз кузгаттым.

— Менә туган Татарстаныбызга 45 яшь тулды. Аны төзү турындагы документта даһи Ленинның имзасы бар. Шулай булгач, шагыйрьләрнең бу хакта шигырь язмыйча ничек җаннары түзсен! — һәм мин сыер савучыларга Ленин турында бер шигырь укып күрсәттем. Ул аларга бик ошады.

Шагыйрьләребездән Сибгат Хәким, Зәки Нури, Гали Хуҗиев, Нәби Дәүли һәм башкалар белән таныш булуымны сөйләгәч, терлекчеләрнең кызыксынулары тагын да арта төште. Аннары мин С. Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Ленин фәрманы белән» исемле әсәрләренең ничек иҗат ителүен аңлаттым. Соңгы әсәрнең Әтнә ягы карты Сәлах Хисамовка багышланган булуын әйттем. Гади татар кешесенең кызыл-армеец булып давыллы көрәш юлларын үтүе, аның әле дә исән-сау яшәве хакында сөйләвем терлекчеләргә бик ошады.

Кечкенәдән башланган сүз зурга китте. Бик күп сораулар бирелде. Сыер савучылар миннән «Казан утлары», «Азат хатын» журналларының яңа саннарын алып килүемне үтенделәр».

Хезмәт иләрендә китапка мәхәббәт тәрбияләүдәге мондый матур эшләрне, китапханәчеләрнең кырларга, фермаларга йөрүләрен, китап сатучыларның да шулай ук мәктәпләргә, колхозларга, предприятиеләргә йөреп, тормышның үзенә, әдәбият укучыларның үзләренә барып китап сатуларын күрсәткән мондый фактларны күп китереп була. Әнә шулай эшләгәндә, халыкка китап тиз җитә, тиз сатыла. Минем үземне, мәсәлән, шагыйребез Габдулла Тукай томының солдат биштәрендә патрон һәм гранаталар белән бергә Берлинга, Рейхстагка ук барып җитүе турындагы шигырь дулкынландырды. Анда мондый юллар бар:

Ярсып илне саклаганда
Канлы сугыш юлында,
Граната белән җилкәдә
Йөрде синең томың да!

Берлин капкаларын алып
Рейхстагка кергәндә,
Син дә булдың, син дә җиңдең
Фашистны без җиңгәндә...

Берлинны алуда катнашкан шагыйрь кечкенә генә бер җыентыгына урнаштырылган шушы шигырен укып күрсәткән иде, кибеттә ул китапны чират торып шунда ук сатып алып бетерделәр. Язучының китап кибетенә килеп укучылар белән очрашуы бигрәк тә уңышлы була, яхшы тәэсир калдыра. Мондый очрашулар хәзер безнең районда традициягә кереп бара. Гомәр Бәширов, Риза Ишморатов, Сибгат Хәким кебек күренекле язучыларыбыз безнең якларга ел саен диярлек килеп, укучылар конференцияләрендә, әдәби очрашуларда катнашалар, укучылар белән элемтәләрен ныгытып, китапка мәхәббәт тәрбияләү эшенә үзләреннән шактый өлеш кертәләр. Матур әдәбият яңалыкларын, фәнни, политик-популяр китапларны пропагандалауда районның «Коммунизмга» газетасы да актив эш алып бара. Яңа китаплар кайтуын район радио челтәре аша да халыкка без еш кына хәбәр итәбез. Шулай итеп, укучылар яңа китап турында тиз ишетеп алалар һәм аларны өйләрендә булдырырга ашыгалар.

Без китапларны халыкка җиткерү эшен яхшырту өчен барлык чараларны күрергә, активларны, китап таратучыларны үз тирәбезгә даими итеп тупларга, барлык яңа методларны кулланырга тырышабыз. Үзара сөйләшеп, без китап алырга килгән иптәш-

ләр кадерле вакытларын әрәм итмәсеннәр, кире борылып китмәсеннәр, кирәкле китапларын үзләренә уңай вакытта ала алсыннар өчен, кибетне көндезге аш вакытларында гына түгел, хәтта ял көннәрендә дә япмаска булдык. Болай эшләүгә күчүе авыр булмады. Аннары без китапларны йөреп сатуны системага керттек. Районда үткәрелә барган төрле конференцияләрнең, киңәйтелгән пленумнарның, сессияләрнең, район активы җыелышларының, механизаторлар яки терлекчеләр киңәшмәләренең берсендә дә китап сатмыйча калмадык. Мәсһүдә Федорова белән Һаҗәр Закирова иптәшләр китапларны әнә шулай йөреп сатып, китап сөючеләр санын арттырдылар. Ләкин алар бу уңышлы эшләр белән масаймыйлар, китапны йөреп сатуны, укучылар заказларын үтәүне тагын да яхшырту өчен бөтен тырышлыкларын багышлыйлар. Алай гына да түгел, җәй көннәрендә без әлеге кечкенә кибеттән китаплар белән урамга чыгабыз. Нәкъ халык йөргән урында, ачык һавада китап аеруча яхшы сатыла.

Китап айлыклары үткәрүдә дә соңгы ун ел эчендә без беркадәр тәҗрибә туплый алдык. Бу эшкә алдан ук әзерләнәбез, халыкка кирәкле китапларны булдыру, кайтарту өчен бөтен чараларны күрәбез. Китап айлыгын әйбәт итеп үткәрүдә безгә район партия һәм комсомол оешмалары конкрет ярдәм итәләр. Китап айлыгын район үзәгендә генә түгел, ә һәр колхозда, совхозда, уку йортларында, һәр җирдә уңышлы үткәрү өчен махсус комиссия төзелә. Китап пропагандалаучы активлар, бу эшне чын күңелләреннән яраткан коммунистлар, комсомолецлар, журналистлар катнашында төзелгән бу комиссия үзенең эш планында конкрет чаралар билгели. Комиссия китапны йөреп сату, халык киоскылары оештыру эшенә булыша. Клубларда, китапханәләрдә укучылар конференцияләре, әдәби кичәләр үткәрелә, Татарстан Язучылар союзының пропаганда бюросы белән киңәшеп, язучыларның укучылар белән очрашу кичәләре планлаштырыла. Китап айлыгы турында район газетасы һәм радио аша хәбәр ителә. Бу вакытта китап сату эшенә шулай ук райондагы барлык комсомол оешмалары, пионер вожатыйлары актив булышалар һәм алар китапны йөреп сатуда, китап базарлары оештыруда зур тырышлык күрсәтәләр. Алдан әйбәтләп әзерләнгән, бизәлгән, кирәкле китаплар белән тәэмин ителгән базарларда халык күп була һәм китап та уңышлы тарала.

Югарыдагы чаралар белән бергә, безнең Арча китап кибете янында китап сатуга, китап таратуга ярдәм итү буенча 15 кешелек комиссия эшли. Бу комиссия членнарыннан, мәсәлән, Арча РТСы работнигы Рәхимә Вәлиева механизаторлар арасында китап сата, ә Хәлимә Идиятова промкомбинат эшчеләренә китаплар тарата. Р. Хәсәнова, Р. Галимҗанова, Л. Козюра, А. Гурьянова һ. б. иптәшләр Арча поселогы хезмәт ияләренә китап сатуда зур тырышлык күрсәтәләр. Яңа кайткан китапларны укучылар арасында пропагандалау, халыкка сату-таратуда безнең райондагы Иске Чүриле, Курса, Әтнә, Кенәр, Мөндеш, Казанбаш һәм башка авыл мәктәпләрендә дә мактап сөйләрлек эш алып барыла.

Хәзер райондагы бик күп иптәшләр кибеткә яңа китап килүен көтеп кенә торалар. Андый иптәшләрдән Г. А. Курамшина, В. И. Кубин, Р. Н. Әбүбәкерова, Р. Г. Мөхәммәтова кебек врачларны, Ш. Ф. Хисаметдинов, А. Б. Бирюкова, З. Р. Рәхимова, Р. М. Хрестофорова, Т. М. Мусин, Р. П. Башкирова, С. Г. Гәрәев кебек алдынгы укытучыларны күрсәтергә мөмкин. Арча эшчеләреннән С. С. Санков белән Р. Э. Тажиев иптәшләр китапны аеруча ярата лар һәм районга килгән яңа китапны беренче булып алырга тырышалар. «Заря» колхозы члены Миннегөл Сибгатованың өй китапханәсендә В. И. Ленин әсәрләре, С. Смирновның «Брест крепосте» дигән Ленин премиясенә лаек булган китабы, Л. Толстой, М. Горький, Л. Леонов, М. Шолохов, А. Беляев, Г. Ибраһимов, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов һәм башка язучыларның томнары бар. Киров исемендәге колхоз члены Р. Җәмилев, Ильич исемендәге колхоз члены Г. Апакашев, шулай ук колхозчылардан Г. Насыйров, Константинов, Хәкимова, Агафонова иптәшләр дә үз китапханәләрен булдырдылар. Арча йорт хозяйкасы Салиха Галимова да яңа китапларны системалы рәвештә укып бара. Аның китапханәсендә Л. Толстой, М. Стельмах, А. Гайдар, Б. Полевой, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ф. Әмирхан, С. Кудаш, М. Фәйзи, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Г. Әпсәләмов, А. Расих һәм башка рус, татар, казакъ, үзбәк язучыларының томнары бар. Аның өй китапханәсе яңадан-яңа китаплар белән баеп бара. Китап сөюче мондый иптәшләрне Арчада гына түгел, Әтнәдә, Яңа Кенәрдә һәм районның башка авылларында да күп очратырга була.

Китап сөюче иптәшләрнең ярдәме, китап сатучыларның тырышлыгы белән безнең райпотребсоюзның (председателе Таһир иптәш Надыршин) Арча китап кибете китап сату планын ел саен диярлек арттырып үтәп килә. Кибет коллективына 1964 елда коммунистик хезмәт бригадасы дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

1965 ел башында китаплар киң, иркен, якты, коры «квартирга» — яңа кибеткә күчтеләр. Иңе алты, буе илле метрлы кибет витриналарына ун меңгә якын китап тезелеп куелды. Моннан тыш балалар китаплары, төрле әсбаплар, плакатлар өчен дә махсус витриналар җиһазландырылды. Кыскасы, хәзер кибет көлеп, ялт итеп тора, барлык китаплар күз алдында, кер дә таныш, теләгәнеңне сайлап ал, яңа чыгачакларына алдан язылып куй! Бу инде чын мәгънәсендә яңа заман таләп иткән, халык көтеп алган кибет! Арча райпотребсоюзының яңа сәүдә комбинаты бинасында шундый яхшы магазин ачылуы үзенә бер зур бәйрәм булды. Шул уңай белән бер группа татар язучыларының районга килүе бу бәйрәмне тагын да ямьләндереп җибәрде. Гомәр Баширов, Сибгат Хәким, Габдрахман Әпсәләмов, Риза Ишморатов, Фатих Хөсни, Атилла Расих, Зәки Нури, Мөхәммәт Садри, Рәисә Ишморатова, Касыйм Фәсахов кебек язучылар, шагыйрьләр безнең яңа магазинга килеп, укучылар белән очраштылар, аларны үзләренең яңа әсәрләре, иҗат планнары белән таныштырдылар. Аннары китап сату башланды. Укучылар яңа китаплар алып калырга ашыктылар. Автографлар яза-яза авторларның куллары талып бетте. Кибет кичкә кадәр гөр килеп торды. Монда башланган очрашулар, әлеге китап бәйрәме белән, районга күчте. Бу язучылар Арча Культура йортында, педагогия училищесында, китапханәләрдә, күп кенә авылларда, «Северный» совхозында, мәктәпләрдә очрашулар, конференцияләр, әдәби кичәләр үткәрделәр. Авыл клубларында, магазиннарында да язучыларны укучылар чолгап алды, автографлар язу дәвам итте. Барлык әдәби кичәләр үзешчән сәнгать коллективларының матур концертлары белән тәмамланды. Шунысы характерлы: китап бәйрәменә алдан ук әзерлек күреп, безгә киләчәк язучыларның әсәрләрен кайбер башка районнардан да алган идек, алары да җитмәде. Шулай итеп, бер атнада гына да китап сөючеләр сафы йөзләрчә, меңнәрчә кешегә артты.

Татарстан Язучылар союзының укучылар белән язучылар арасында элемтәне ныгыта баруы, урыннарда язучыларның ешрак булуына игътибар итүе, әдәби атналыклар оештыруы, поэзия көннәре үткәрүе — китап сату, халыкта китапка мәхәббәт тәрбияләү эшенә бәя биреп бетергесез зур ярдәм ул. Мондый чараларның системага керүенә, республикабызның барлык районнарында үткәрелүенә без, китап сәүдәсе работниклары, барлык китап сөючеләр белән бергә, шатланабыз һәм мондый әйбәт эшләре өчен Татарстан язучылары коллективына кайнар рәхмәтләребезне җибәрәбез!

Әйе, безнең Арчага килгән китаплар хәзер бик бәхетле. Якты, зур кибеткә килүләре белән генә түгел, ә укучылар тарафыннан олылап каршылануларі, аларның өйләренә тизрәк кайтып, бик тиз укылулары белән бәхетле. Иске кибеттә тупланган шактый зур тәҗрибә, китап сату эшендә барлык яңа чараларны кулланырга тырышу яңа кибеттә тагы да яхшырак эшләү мөмкинлекләрен ачты. Безнең коллектив: «Яңа китап һәр гаиләгә җитсен, һәр гаиләнең үз китапханәсе булсын!» — дигән девиз белән эшли. Бу тырышлык матур нәтиҗәләр бирә — китап кибете быел Татпотребсоюз һәм сәүдә работниклары өлкә союзының күчмә Кызыл байрагын яулап алды. Әтнә, Яңа Кенәр китап кибете эшчеләре һәм райондагы 154 авыл кибетләрендәге китап бүлекләре дә Арча кибетеннән үрнәк алып эшләргә керештеләр.

Безнең илнең китап кибетләре китап алу-сату урыннары гына түгел, ә халыкның китапка булган соравын өйрәнү, аны пропагандалау үзәге, чын мәгънәсендә культура учаклары булып саналалар. Китап сәүдәсе эшчеләре үзләренең Коммунистлар партиясе, Совет дәүләте тарафыннан куелган зур бурычларны үтәү өчен көрәшүче кешеләр икәнен онытмыйлар, даһи В. И. Ленин васыятьләрен тормышка ашыру, халыкны, бигрәк тә яшь буынны, коммунизм идеяләренә бирелгәнлек рухында тәрбияләү эшенә үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр.

*ЖОФАР ФӘЙЗРАХМАНОВА.*




*Бөек социалистик революция бөтен дөньяны тетрәтте. Илдәге элек басылып яткан халык ярсып күтәрелде. Революция сөюче һәр кеше күңеленә үтеп, кешенең бөтен рух, зиһен дөньясын да төбенә кадәр айкап алды, уятты, аны да ярсулы бөек ташкынга кертеп җибәрде. Тарихның объектив вакыйгалары белән кешенең субъектив ашкынулары бергә кушылды. Нәтиҗәдә кеше үсеп, зураеп китте, элек күзгә чалынмаган гади кешеләр геройга әйләнделәр. Алар үзләрен дулкынландырган хисләрен, үзләрен канатландырган уйларын бөтен дөньяга ишетелерлек тулы тавыш белән әйтеп бирергә теләделәр. Революцион җыр туды, революцион шигырь язылды. Ләкин, тарихи вакыйгалар илһамландырган геройлар йөз түгел, мең түгел, алар — миллионнар иде. Җыр чыгарырга, шигырь язарга теләүчеләр дә күбәйде. Беренче совет газеталарының битләре революция алдыннан матбугатта һич күренмәгән төрле-төрле яңа имзалар белән тулды. Аларның күбесе кызыл сугышчы, комиссар яки кызыл командир, укытучы, эшче яки игенче иде. Алар каләменнән чыккан шигырьләргә контрреволюциягә чиксез нәфрәт, яңа строй өчен соңгы тамчы кан калганчы сугышырга ашкынып тору хас иде. Дөрес, аларның бу уй-хисләре әле, язгы ташкын кебек, ярларына сыймый ургылып ага, аларда әле хис-тойгыны шигъри нәфислек белән әйтеп бирү дәрәҗәсенә күтәрү осталыгы җитми, шулай да бу — ташкын, хис ташкыны, революциянең кеше җаны тирәнлегеннән яңгырап килгән авазы иде.*

*Безнең көннәрдә бөтен дөньяны сокландырган совет поэзиясе әнә шуннан башланды. Ләкин давыллы елларда туган беренче әсәрләр шул вакыттагы газета битләрендә, тиз-тиз генә чыгарылган китапчыкларда басылганнар да, шул килеш калганнар. Аларны җыясы, яңадан басасы һәм халкыбызның яшь буыны кулына бирәсе бар әле.*

*Биредә без шул поэзиянең кайбер үрнәкләрен, революция елларында чыккан газеталардан алып, яңадан басабыз, укучыларыбызга тәкъдим итәбез*.*

---

* Бу шигырьләр Сахибгәрәй ага Мортазин тарафыннан җыелган.

*Ибраһим Йосфи*

## Мөселман полкына!

Әй татарның иң беренче инкыйлапчы гаскәре,
Чын дөрес юлдан баручы иң беренче ләшкәре,

Сез тезелдегез фәкыйрьнең иреген саклар өчен,
Утка, суга бакмыйча, аның хакын хаклар өчен.

Бар татарның ярлысы сезгә карый хөрмәт белән,
Күрсәтер дип бар җиһанга үзләрен хезмәт белән.

Бик дөрес: Сез тиз алырсыз зур батырлык шаннары,
Калтырар, куркып качар сездән халык дошманнары.

Алдырырсыз искә иске чын татар солдатларын,
Күрсәтерсез без татарларның советны яклавын.

Булса Колчакның Инсус атлы нәҗис полклары,
Ә бу якта бар анар каршы татар егетләре.

Кычкырыгыз, әй егетләр, яңгырасын җир йөзе,
Өстәге кара болытлардан ачылсын күк йөзе.

Һич курыкма, алга атла, кер беренче сафка син,
Түк каныңны, бирмә урыныңны, Советны сакла син!

Башкалар алдында, син, күрсәт татарның гайрәтен,
Бул батыр дошманга каршы, шунда артыр кыйммәтең.

*«Кызыл армия» № 63, 23 май 1919 ел.*

*Крестьян*

## «Ак»лар сафыннан

Кызыгып алтын-көмешкә
Керештек без юк эшкә,
Союзникларга сатылып
Утырдык без юешкә.

Төрлечә итеп алдап
Иттеләр безне солдат,
Төрле матур сүзләр белән
Сугыштырдылар яллап.

Кызыктырып тәтигә
Каршы иттеләр әтигә,
Ничә айлар, ничә көннәр
Без сугыштык соң нигә?

Аңламыйча хәйләсен,
Саклап байлар файдасын,
Сугышып йөрдек ничә айлар
Хода тафу әйләсен.


Без үзебез дә эшче,
Әткәй дә көн-төн эшли,
Эшчегә каршы сугыштык
Аңламаганнан эшне.

Без үзебез ялангач,
Карыннарыбыз да ач,
Тук байларның файдасына
Булып йөрдек без палач.

Инде, иптәш, күзең ач,
«Ак»лар сафыннан тиз кач,
Алар җинсә, патша куеп,
Киертәчәк алтын таҗ.

Җиңсә алыр җиреңне,
Солдат итәр иреңне,
Көн-төн хезмәт иттерерләр,
Бөкрәйтерләр билеңне.

«Эш» № 141, 12 январь 1919 ел.



*«Ишан Гали»*
*(Г. Камал)*

## Әсир моңы

*(Германия һәм Австриядән кайткан әсирләрне каршылау көенә)*

Тоткынлыкта күп йөрдек без,
Хурлыкларны күп күрдек без,
Ачлыклардан җәфа чиктек,
Күрә алмадык һич көләр йөз.

Авыр йөкләр тарттырдылар,
Салкын җирдә яткырдылар,
Аз гына шикаять итсәк
Һич рәхимсез аттырдылар.

Мөмкин булмады яшәргә,
Бирмәделәр һич ашарга,
Ачлыктан үлмәс өчен дип
Күп кеше ашады карга.

Ачлыктан күпләр шешенде —
Эшләп булмагач эшеңне,
«Ялкау сез, эшләмисез» дип
Аркага камчы төшерде.

Өс-башлар булды ялангач,
Тетелгән кием талангач,
Ашаган аш туйдырмый,
Тамаклар һаман булды ач.

Ачлыктан билләр бөгелде,
Күзләрдән яшьләр түгелде,
Шундый михнәтләрне күргән
Кардәшегез без түгелме?

Сез, илдә калган туганнар,
Бар да бәхетле булганнар,
Ирек алган, бәхет алган,
Золматны да куганнар.

Көне-төне без зар кылдык,
Кайтырга интизар булдык,
Һичбер хәбәр ала алмадык,
Туган илләрне сагындык.

Сугыш беткәч бер көннәрне,
Күрәбез диеп илләрне,
Шатланышып кайткан идек, —
Дошман алган ул җирләрне.

Тагын калдык ят илләрдә,
Турая алмый билләр дә,
Тагын насыйп икән йөрү,
Калтырап ачы җилләрдә.

Бу язганнар эсир моңы,
Исеңнән чыгарма моны,
Эсирләр ярдәм көтәләр,
Аларга суз ярдәм кулы.

«Эш» № 136, 5 январь 1919 ел.

*Фарсин Юныс*

## Җирдән ләгънәт

Мин тудырдым тоз вә икмәк ач-ялангачлар өчен,
Эшләгәч агызып тирен тик бар итеп үз кул көчен;
Мин тудырдым чын якут, мәрмәр, ләгыльдәй ташларын,
Бирдем оҗмах күк сарай һәм анда бал-май ашларын;
Мин тудырдым бриллиант һәм бар көмеш-алтыннарын,
Мин тудырдым таш белән һәм каш белән баш-колларын;
Мин тудырдым һәммәсен — барысын адәм мохтаҗ диеп,
Чикмәсен михнәт-җәфа, торсын диеп ил таҗ киеп,
Җил белән очты уем-фикерем, килеп тар-мар план,
Ярлылар мескен калып, алгач басып бар күк елан.
Йөз вә мең ләгънәт укый туфрак җирем бай өстенә,
Тик талап яткач минем ярлымны тартып көч белә.
Мин хәзер антлар бирәм, вәгъдә бирәм һәркем өчен!
Шул ашар җирдән — әгәр иксә җыеп үз кул көчен!

«Эшче» № 43, 14 май 1920 ел.

*Хас*

## Чын төш

*(Кечкенә фельетон)*

Бик тынычлап йоклаганда, мин гаҗәп раст төш күрәм,
Төшләремдә һәрвакытта өндә булган эш күрәм.

Вәт әле күптән түгел, төштә, Париждамын, имеш;
Өч татар зурлары белән бер номердамын, имеш.
Мин боларны күргәч үк кемнәр икәнен аңладым —
да шулай әзрәк боларга сүз катарга уйладым.
Иң элек башлыклары янына барып бирдем сәлам.
Ул сәлам кайтарды каршы: — Вәгаләйкем әссәлам.
— Садрый абзый! Соң ниләр бар, учредилкаң эшлиме?
Болганамы күлдә су, кармакны чуртан тешлиме?
— Юк энем, эшләр начар шул; кайгыдан һич чыкмый баш,
Нишлисең бит тәкъдирең булгач түгәргә канлы яшь.
Бервакытлар без Татарстанда шәп гизгән идек,
Шура чакларда аяк астын таза сизгән идек.
Көн саен байлар белән майда гына йөзгән идек,
Безгә алданган татар ярлыларын изгән идек.
Юк, хәзер үзгәрде эш, картайдым инде, бетте көч,
Шул советларны җиңәлмәс ахры безнең көчле үч.

— Соң ничек, мәшһүр мөхәррир, сезнең эшләр җайлымы?
Монда да сезнең каләмгә матбугат унайлымы?
— Юк, егет! Мәлгунь французлар мине аңламыйлар;
Шактый ук зур мәҗмугамны санга да санамыйлар.
Карным ач, өс-баш ялангач, бик начар, эшләр начар,
Тик ятып бәхетем көтәм, кайчан ходай бәхетем ачар?
Милли малдан эләктереп тайган сумам бетте тәмам.
Үлмәсәм ачка ярый, тормыш начар, раббем, әман!
Өч олугның берсе «Туктар»ны гүя мин күрмәдем.
Яшмәдем: сүз башласа һич туктамас дип шүрләдем.

«Кызыл армия» № 425, 3 март 1921 ел.

*Г. Гумеров*

## Аю һәм керпе

*(Мәсәл)*

Чыкты бер көнне сунарга
Карт аю ачлык сизеп,
Әллә кайдан шунда керпе
Чыкты юлга тап килеп.

Кечкенә бер керпедән зур
Бер аю каушамады,
Зур аякны бер басудан:
Ул бетәр дип уйлады.

Салды зур аякларын ул
Керпене измәк теләп,
Без кебек очлы энәләр
Тиште итне телгәләп.

Гарьлегеннән ташты ачу,
Алды зур борынын бәреп,
Чәнчелеп анда энәләр
Алдылар борынын ярып.

Уйлады аннан изәргә,
Ташлады бар гәүдәсен,
Каплады кан гәүдәне дә, —
Укый аю тәүбәсен.

Китми юлдан керпе читкә
Аюда гайрәт күреп,
Тик энәләр калка төште,
Өскә чыкты тырпаеп.

Белде аю житмәсен көч,
Көч белән җиңәлмасын,
Уйлый инде башка төрле,
Ул кора зур хәйләсен.

Кул суза, тату булыйк, ди,
Мин үтим, юлдан, җибәр!
Син дә тор, мин дә торыйм, ди
Дөнья һәркемгә житәр.

«Шәрык ярлылары» № 23, 14 май 1920 ел.

*Н. Думави*

## Хөррият белән тәбрик

Мин яшим дип чык алынга,
Бас аякны нык, татар!
Шул татар исемең барында,
Курыкма, алга чык, татар!

Син арыслан, синдә куәт —
Бир тавыш, җир тетрәсен,
Син бөек, син көчле милләт —
Атла коллык киртәсен.

Күп гасырлар сыкрадың да,
Сыкрадың эчтән янып,
Инде атлап чык алынга
Мин яшим дип шатланып.

Бул бәхетле — син ирекле,
Үз эшеңне бел, татар!
Мең яшә, миллион яшә,
Әй яшь татар, әй хөр татар!

«Аң» № 5, 31 май 1917 ел.

*Кави Нәҗми*

## Онытылмый

*(«Кызыл яу» көндәлегеннән)*

Исеңдәме иптәш? Шәһәр урамында,
Кичке караңгылык төшкәндә;
Яфрак, чүп-чарларны анда-монда
Очыргалап, җилләр искәндә;

Бераз тордык чатта тынлык саклап,
Күзләр белән генә сөйләштек,
Соңра төрле якка киттек атлап,
Җил астында «Хуш бул!» эндәштек.

Шул сәгатьтән бирле байтак вакыт
Үтте, айлар бер-бер алмашты.
Озак михнәт соңра кыска бәхет
Белән дөнья безне алдатты.

Туры килде миңа төрле якта
Өстерәлеп дөнья гизәргә.
Булды шундый чак та: бик еракта,
Уйладым тормыштан бизәргә.

Ләкин бу уй үзгәрде дә киңәт,
Үзә алмыйча йөрәктә дәрткә;
«Капиталга, байларга, дип, нәләт!»
Кердем кызыл яуга, бер рәткә.

Аңлап үч алу, дәрт һәм иман
Бирде көч дошманны изәргә.
Бетте фронт, тынды канлы җиһан,
Җитте вакыт илне бизәргә.

Тагы чәчри чаткылар чүкечтән;
Фабрикларда утлар ялтырый.
Ерткычларны изеп кайткан көчтән
Куркып җимерек, ачлык калтырый.

Мин дә таныш станок янында,
Тәгәрмәчкә каешлар әләм...
Эшлим, шатлык-рәхәтлек җанымда;
«Дөнья җәннәт була» дип, көләм.

...Ник ашкынган йөрәгем тынмыйдыр һич
Үткәнемне уйлап торганда,
Искә төшә һаман: ул җәйге кич,
Көрәшүебез җилле урамда...

«Тат. хәб.» № 132, 1 июль 1921 ел.

*Кәрим Әмири*

## Тәгъзия

*(Беренче Май бәйрәменә багышлап)*

Замана ыжгырып көннәр вә төннәр,
Җиһанда йотмады ут кем вә кемнәр;
Елый, елый эчеп зәһәр агулар,
Килеп китте ничә илләр, каумнар.
Елап торды, елап үсте адәмнәр,
Янып көл булды һәм фани әмәлләр;
Гомерләр ыңрашып күргән гамәлләр
Язылды канга манчылып каләмнәр...
Гомерләр сызгырып исте бу җилләр,
Көченнән калтырады күкләр вә җирләр;
Йөрәкләр телгәләнеп парча-парча,
Егылды шунда канча-канча ирләр...
Егылдылар күрәлмыйча бу көнне,
Ачылган күк капусы — изге төнне;
Ташып чыккан күңелләр ялкыныннан,
Колакта чыңлаган шатлыклы өнне...

«Эшче» № 38, 1 май 1920 ел

*Б. Сибгат*
*(Бари Рәхмәт)*

## Түзә алмыйм

*(Лазареттагы мәҗрух авызыннан)*

Ник түзәлми бу яралар...
Җан түзәлми ашкына,
Ашкына атылырга торган —
Төсле дошман каршына.

Бетсә дә көч, дәрманым,
Рух, дәртләр әл дә сүнмәгән,
Әл дә эчтән җилкенә яшь
Күңелем әл дә үлмәгән.

Авыру күкрәктә тибә
Дөрселдәп элекке яшь йөрәк,
Элеккедәй яшьнәп, элекке
Төсле күкрәп, гөлдерәп.

Төннәрен керфек кагалмыйм —
Йоклый алмыйм... уйланам,
Ярлы ил искә төшә дә,
Хәсрәтемнән мин янам.

Кайгыда-хәсрәттә төсле ил,
Туган ил өстенә,
Зур болытлар төсле
Коточкыч кара бер көч белән,

Тешләрен кайрап явыз дошман
Килә төсле тоям,
Ил елый, ил кайгыра —
Дошман көлә төсле тоям.

Ишетелә төсле тагын анда
Гөрелдәү өннәре,
Җырлыйлар төсле туган
Илнең баһадир уллары.

Һәйбәтеннән тетри җир,
Күк күкри, тау-ташлар вала,
Яңгырый дәртле азатлык
Җырларыннан киң дала.

Мин түзәлмыйм... Мин дә тезелеп
Шул егетләр сафына,
Күкрәгем киереп телим атылырга
Дошман каршына.

«Кызыл Армия» № 164, 10 октябрь 1919 е.

*Зыя Ярмәки*

## Гакыл һәм алтын

Искедән каршы киләдер, бу гакыл алтын белән
Нәкъ шулай каршы килә салкын кызу ялкын белән.
Сүз сөйләү тиеш дисә гакыл гали уйга карап,
Бай сөйли сүзне һаман да нурлы алтынга карап.

«Шура» № 3, 1 февраль 1917 ел.

*Зәйнәп Бәширова*

## Кем соң ул?

Кем соң ул барлык табигатьне үзенә кол итә,
Кем, начар, пычрак җиһанны пакь итә, ал-гөл итә?
Кем соң ул юк нәрсәләрне бар итә һәм булдыра,
Кем соң ул икмәк белән сансыз халыкны туйдыра?
Кем кара җиргә үсемлекләр-игеннәр үстерә,
Кем соң ул өскә кияргә дә киемнәрне бирә?
Ис китәрлек бит шәһәрләрне, авылларны кара!
Зур сарайлар, бик матур йортлар, аларны кем сала?

Ярлы илгә файда булсын дип кораллар кем ясый,
Кем, начар, иске нигезләрне вата һәм көл ясый?
Кем, кара көчләргә нык күкрәк киереп каршы тора,
Ярлы илдә якты тормышка нигезләр кем кора?
Кем соң ул кодрәтле зат, бар дөньяны кулда бөгә,
Бар табигать калтырап каршында бөгелеп тез чүгә?
Кем соң ул һәр нәрсәләрне булдыра һәм кем ясый,
Ул бөек, кодрәтле кем? — Эшче — табигать алласы.

«Эшче» № 114, 1 декабрь 1920 ел.

*Кәримә Госманова*

## Сугыш

Әй, бөтен Европа халкын кайгыга салган, сугыш!
Әй, бөтен күк, җирне, тауны, ташны тетрәткән, сугыш!
Бар җиһанны аглатып, кан еглатып, күз яшь белән,
Туйдырып барча халыкны «аһлар»ың берлә, сугыш.
Нинди мөшәффыйк аналардан бала аерып алып,
Куркынычлы, канлы мәйданга атып бәргән, сугыш.
Иң сөекле, җан газизе, күз нуры булган ярын,
Мөдһиш упкын эченә салып, вайран иткән бу сугыш.
Аһ!.. Кара томан, кара болыт кайчан китәр икән?
Бер булырмы беткәне, югалганы ямьсез сугыш?..
Күп гасырларның канын агызып, кисеп, мәҗрух итеп,
Рәнҗетеп, зар иңрәтүләрең бетәр микән, сугыш?

Бер күрер, терек адәмнәр нинди эшләр тудырыр,
Нинди гыйлем, мәгърифәт ишеген ачар безгә сугыш.
Шул сугышлар бер бетеп рухлар тынычланса бераз,
Күп халык өчен рәхәт, мәсгут булыр иде торыш.

«Сөембикә» № 16, 3 сентябрь 1917 ел.

*С. Мортазин*

## Якты көн алда

Юк, агай, кайгырма бер дә, якты көннәр алда әле;
Эшченең барлык бәхет, барлык сәгадәте анда әле.
Алда дуслык һәм туганлык, алда шатлыклы заман,
Алдадыр хөрлек, тигезлек, алда иркенлек тәмам.
Анда юк җәбер, золым, вәхшәт, богау, төрмә фәлән.
Анда юк эшче канынннан корсак үстергән адәм.
Булмас өстеңдә синең һич көчле истибдат кулы,
Син граждан анда, син хөр, булмыйсың байлар колы.
Тик хәзер син йоклама, тынма, көрәш гайрәт белән!
Каршы тор дошманга чынлап, син дә көч-гайрәт белән.
Син тырышсаң тиз бетәр вәхши капитал козгыны,
Иөзтүбән китәр җәһәннәмгә капитал органы.
Әйдә кузгал, тиз житик шатлыклы көн, ак дөньяга!
Мәңгегә җилбердәсен бу канлы байрак дөньяда!..

«Минзәлә иле» № 79, 19 февраль 1919 ел.

### УДМУРТ МӘКАЛЬЛӘРЕ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘРЕ

Уйлау җитми, эш кирәк.
Тел тезгене баш була.
Сүз энәдән үткенрәк.
Имән черек дию белән, имән тамырыннан аумый.
Теле — сандугачныкы, үзе бүре йөрәкле.
Теле белән майлар да, теше белән ботарлар.
Телең белән сөртенгәнче, аякларың сөртенсен.
Теле үткен, кулы тупа.
Бер кулы куйган имзаны икенчесе юк итә.
Су төбенә төштең икән, ярдан дуслар чакырма.
Яхшы дусты юк кеше яман эшен аңламас.
Балы булса, чебен ябыша.
Көч хезмәттә ныгый.
Идән чиста булсын дисәң, билне ешрак бөгәсең.
Урман кисүче кешене тун түгел, балта җылыта.
Иртә торган саескан ризык тапмыйча калмый.
Тимерченең кулы алтын, ә шагыйрьнең—сүзләре.
Кеймәгә дип кискән усак ишкәккә дә җитмәде.
Читән казыксыз тормый.
Юкәсе әле кисмәгән, ул чабата үрмәкче.
Үзе шытып чыкмаганны тартып үстереп булмый.
Кызу урак өстендә кояшны үзең уят.
Бергәләп эшләү уендай җиңел, ә ялгыз хезмәт үлемдәй авыр.

***Театр сәнгате һәм драматургиябезнең торышы киң җәмәгатьчелек вәкилләрен күптән борчып килә торган мәсьәләләрнең берсе. Шуны искә алып, „Казан утлары" журналы редакциясе бүгенге театр сәнгате һәм драматургиябез турында фикер алышу уздырырга булды.***

***Хөрмәтле иптәшләр! Язучылар һәм тәнкыйтьчеләр, театр белгечләре, режиссерлар һәм артистлар, тамашачылар! Редакция сезне фикер алышуга катнашырга чакыра һәм сездән мәкаләләр көтеп кала.***

*Ильтани Илялова*

# ЗАМАН ҺӘМ ТЕАТР

Мин Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театрының сезон йомгаклары, бүгенге хәле турында сөйләргә телим. Үтә җаваплы һәм җитди, шул ук вакытта, күп төрле сәбәпләр буенча, бик кыен бер эш бу.

Татар академия театры. Бу исем — халкыбызның мактанычы һәм горурлыгы. Бу исем белән сәнгатебезнең ярты гасырдан артык үсеш тарихы бәйләнгән. Заманында Г. Камал исемендәге театр базасында уннарча татар театр коллективлары үсеп чыкты. Урта Азия республикаларында милли труппалар оештыруда бу коллективның зур хезмәтләре бар. Исемнәре бөтен илгә мәгълүм язучыларның, артистларның иҗаты шушы театр белән бәйләнгән. Халкыбызга күрсәткән зур хезмәтләре өчен, каршына килеп, баш иярлек хөрмәтле бер театр бу. Менә шуңа күрә дә инде театрның бүгенге хәле, андагы җитешсезлекләр, авыру яклар турында язарга кыен да, читен дә, газаплы да. Нишлисең, авыр булса да, алар турында да сөйләргә, язарга туры килә. Бурычын яшергән — бөлгән, чирен яшергән — үлгән, диләр бит.

Узган сезон йомгаклары турында уйлана торгач, шундый фикергә киләсең. Театрдагы җитешсез яклар кичә, бүген генә башланмаган. Ул җитешсезлекләрнең еллар буенча җыела, туплана килгән объектив сәбәпләре бар икән. Һәм шуңа да, узган сезондагы аерым спектакльләрнең уңышлы һәм кимчелекле яклары турында сөйләүдән дә бигрәк, театрны еллар буена артка сөйрәп килгән әйберләр турында язу урынлырак та, файдалырак та булыр шикелле. Сәнгатьтә кичәге көн белән бүгенге көн бертөсле була алмый, театр сәнгатендә бигрәк тә. Чөнки сәнгать ул — өзлексез хәрәкәт, өзлексез эзләнү, яңа сүз әйтү, ачыш ясау. Шул хәрәкәтнең берәр ноктасында тукталдыңмы, син инде артта калдың дигән сүз. Сәнгатьнең яшәү көче, аның тормышчанлыгы һәм кирәклеге — яңага омтылуда, даими канәгатьсезлек тойгысында, өзлексез хәрәкәттә. Сәнгатьтә бер дә үзгәрми торган, мәңгелек критерийлар юк, мәңгелек таләпләр генә

бар. Һәм аларның иң әһәмиятлеләре — идеялелек, заманчалык, гражданлык пафосы. Заманчалык һәм гражданлык пафосы сәнгатьне яшәтә, аны бар итә торган төп, нигез сыйфатлар: болардан башка сәнгать яши алмый. Гражданлык позицияләренең анык булмавы, тормыш күренешләренең төп юнәлешләрен дөрес билгели алмау чорны берьяклы һәм беркатлы, примитив аңлауга китерә. Театрда бүген язылган, заман темасына багышланган әсәрләр барырга, ул әсәрләрне бүгенге артистлар уйнарга, бүгенге режиссерлар куярга мөмкин. Бер очракта әсәр зур уңыш казаныр, икенче очракта заманчалыкның эзе дә булмас. Ни өчен? Чөнки бүгенге тормышның өстә яткан, тышкы билгеләрен һәм аерым фактларын күпләп тутыру гына әле сәнгать әсәрен заманча ясамый. Заманчалык төшенчәсе күп мәртәбә тирәнрәк. Ул бүгенге тормыш күренешләренең асылын ачу, замандашларыбыз образларын тулы һәм тирән чагылдыру дигән сүз. Шуның өчен артистлар уеныннан, репертуар сайлау принципларыннан, сайланган әсәрләрне сәхнәгә кую рәвешеннән чыгып кына театрның чын йөзен, аның позицияләрен билгеләп була.

Инде мәсьәләгә якынрак килсәк, бүген татар театрында хәл шулайрак тора. Озакка сузылган ремонт аркасында, узган сезонны театр кыш урталарында гына ачып җибәрде. Шулай да, зур киеренкелек һәм тырышлык белән эшләп, коллектив спектакльләр кую һәм финанс планын үтәп чыга алды. Бу яктан караганда, коллективның эше һәртөрле мактауга лаек. Сәхнәдә без «Карлыгач канат кага», «Яшь йөрәкләр», «Бертуган Таһировлар», «Һиҗрәт», «Тормыш җыры», «Ай тотылган төндә» дигән яңа спектакльләр күрдек. Барысы алты спектакль, шуларның бишесе үз драматургларыбызның әсәрләре, берсе башкорт драматургы Мостай Кәрим әсәре буенча эшләнгән. Хәзер шул әсәрләргә сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәләре, күтәрелгән проблемаларның актуальлеге, гражданлык пафослары ягыннан якын килеп карыйк. Төгәл һәм дөрес режиссер трактовкасы табылган очракта, «Бертуган Таһировлар», «Һиҗрәт», «Тормыш җыры» һәм «Ай тотылган төндә» кебек әсәрләр, ягъни репертуарның зур өлеше, партияле дә, заманча да яңгырый алган булырлар иде. Бу пьесалар җирлегендә, куелышлары буенча да, чишелешләре буенча да, бер-берсен кабатламаслык, менә дигән спектакльләр эшләргә мөмкин иде. Аларның һәрберсе төрле жанрдагы, төрле пландагы чын сәнгать әсәре.

Репертуарда оригинал әсәрләрнең шулай күп булуы бик шатлыклы, күңелле күренеш, билгеле. Бу — безнең драматургиянең байлыгы турында сөйли. Һәм милли театрда репертуарның төп, күпчелек өлешен милли пьесалар алырга тиеш тә. Тик төп өлешен генә, ә бөтен репертуарны түгел. Шунда инде репертуар сайлау мәсьәләсенең дә күләгәле яклары күзгә ташлана башлый. Театрның узган елгы репертуарында бер генә классик пьеса да юк. Ә бит тиздән безнең театрга 60 ел тула. 20—30 еллар турында сөйләп тә тормыйбыз инде. Әле революциягә кадәр үк, театр формалашып кына килгән чорда да, аның репертуарында классик әсәрләр байтак булган. Хәзерге репертуардан Шекспир, Чехов, Гоголь, Шиллер, Пушкин исемнәре әкренләп югала бара. Классик драматургларның әсәрләре югалу шулай гадәти бер хәлгә әйләнгән икән, бу турыда шулай ук уйларга кирәк. Безнең театр өчен классик драматургия, бәлки, искергәндер, коры музей экспонаты гына булып калгандыр?.. Әнә грузин, үзбәк, әрмән, Балтик буе республикаларының милли театрлары классикадан һәм тәрҗемә әсәрләре куюдан курыкмыйлар, зыян да күрмиләр.

Дөрес, мәсьәләне нинди әсәр кую гына тулысынча хәл итми. Хикмәт репертуарда гына түгел әле. Иң мөһиме — сайланган әсәрләрнең ничек куелуы, спектакльләрнең эшләнеш, җитлеккәнлек дәрәҗәсе. Соңгы елларда без барыбыз да драматургиянең артта баруы турында дау куба-

рырга, театр эшендәге бөтен җитешсезлекләрне бары драматурглар өстенә генә аударырга гадәтләнеп киттек. Сүз дә юк, драматургиянең хәле дә әллә ни шаккатырлык түгел. Бу өлкәдә дә кимчелекләр байтак. Әмма, ни генә булмасын, безнең тулы канлы сәхнә әсәрләребез бар бит, һәм алар шактый гына. Безне иң нык борчыган нәрсә дә шул: безнең һәр яктан килгән, тулы канлы пьесаларыбыз, сәхнәгә менгәч, ничектер, сүрелеп, төссезләнеп, чырайсыз булып калалар. Академия театрының соңгы еллардагы кайсы гына спектаклен алма, алар барысы бер анадан туган игезәкләр сыман. Әйтерсең лә, һәммәсе бер үк пландагы, бер үк жанрдагы әсәрләр, аларның барысын да бер автор язган. Әйтерсең лә, аларның һәммәсен бер үк режиссер куя, бер үк артистлар уйный. Төбендә, барысы да этнографик, тормыш-көнкүреш спектакльләре. Театр сәхнәсендә без зур фикер, халкыбызның үткәне һәм киләчәге турында уйланулар, иҗтимагый каршылыкларның асылын ачарлык гомумиләштерүләрне күрмибез. Узган сезонда чыгарылган алты спектакльнең берсе икенчесеннән берни белән дә аерылмый диярлек. Алты спектакль дә психологик драма планында куелган, алтысы да бик шома һәм бер дәрәҗәдәрәк, һәм берсе дә артык дулкынландырмый. Ә бит шул спектакльләрнең нигезенә алынган пьесаларның үзләренә мөрәҗәгать итсәк, бөтенләй башка картина. «Карлыгач канат кага» — комедия; «Һиҗрәт»— сатирик комедия, «Ай тотылган төндә»—трагедия. Калган өчесе—драмалар. Күрәсез, режиссерлар һәм артистлар өчен нинди бай иҗат мәйданы! Бу пьесалар буенча ничаклы оригиналь, бер-берсен кабатламаслык спектакль тудырып булыр иде!..

Мин Хәй Вахитның «Карлыгач канат кага»сын һәрьяктан килгән, камиль сәнгать әсәре дип расларга җыенмыйм. Юк, алай ук түгел. Пьесада кытыршылыклар, каршылыклы урыннар байтак. Әмма бер нәрсә бәхәссез: әсәрнең нигезендә бик көлкеле, чын мәгънәсендә комедиячел ситуация ята. Режиссерга әсәргә сукыр килеш иярмичә, автор белән эшләргә, аны чын комедия дәрәҗәсенә җиткерергә кирәк булгандыр. Шул чагында рәхәтләнеп көләрлек, җанлы спектакль туар иде. Хәзерге вариантында исә спектакль (дөрес, анда көлдерергә тырышу бар) психологик драма кануннары буенча куелган. Артистлар, өйрәнелгән гадәт буенча, бик җиңел һәм гади, табигый уйныйлар. Шулай да, комедия түгел, ә драма уйныйлар. Комедияләрне драма итеп кую бер безнең театр гына ачкан «яңалык» түгел. 50 елларда Хәмзә театры да Мольер комедияләре белән шундыйрак хәлдә калган иде. Хәмзәлеләр бөек драматургның күп комедияләрен куеп карыйлар, ләкин берсе дә уңышлы чыкмый. Сәбәбе шул ук. Безнең театр кебек үк, алар да комедияне психологик драма планында чишкән булалар. Нәтиҗәдә, драматургик материал вагая, авырая, авторның «манерасы», комедиянең очкыны, тере җаны югала. Әйе, комедиядә дә тормыш дөреслеге сакланырга тиеш. Әмма комедия дөреслеген башка жанрлар дөреслеге белән бутарга ярамый. Комедиядәге дөреслек драманыкыннан аерылган кебек, трагедия жанрындагы дөреслек тә водевильнеке белән бер үк төсле түгел. Бер карасаң, Хәмзә театрының 50 елларда уңышсызлыкка очравы табигый күренеш тә. Чоры башка, заманы башка иде. Ул елларда театр сәнгате турында бик үк дөрес булмаган карашлар яши иде. Барлык театрлар диярлек «МХАТ»ча булырга, психологик драма каннуннары буенча гына эшләргә тырышалар иде. Ләкин инде 1953 елның ноябрендә ук «Правда» газетасы:

«Сәнгатьтә бер генә төрле дөреслек юк... Сәнгать өчен иң куркынычлы бәлаләрнең берсе тигезләү, хәтта ул бик яхшы булса да, бер штампка яраштыру. Мондый караштан чыгып сәнгать әсәре эшләргә тотыну индивидуаль аерымлыкларны юа, иярүчәнлеккә, шаблонга китерә, иҗади фикер үсешен тоткарлый, сәнгатьне эзләнүләр бәхетеннән мәхрүм итә», — дип, театр сәнгате өлкәсендәге ялгыш карашлар-

ны тәнкыйть итеп чыкты. Барлык совет театрлары күп төрле сәхнә алымнары һәм формалар эзләү белән актив рәвештә шөгыльләнгән бер заманда, безнең театр әле һаман 30 еллар дәрәҗәсендә кала бирә. Бөтен пьесалар бер калыптан сугыла, трагедияне драмадан, драманы комедиядән аерып булмый. Һәр әсәрнең үзенә генә ярарлык ачкыч табу юнәлешендә берни дә эшләнми диярлек, артистлар уены да, режиссер трактовкасы да искечә. Алынган пьеса театрның еллар буе калыплашкан уен стиленә туры, тәңгәл килгән очракларда гына аерым уңышлы спектакльләр чыга. Безгә калса, «Чаткылар» һәм «Бертуган Таһировлар» спектакльләренең уңышын әнә шул туры килү, драматургик материалның театр стиленә тәңгәл килүе белән аңлатырга кирәк.

Фатих Хөснинең «Бертуган Таһировлар» драмасы турында төрле фикер йөри. Берәүләр аны эшләнеп җитмәгән, ахырга кадәр чишелмәгән пьеса диләр. Ләкин, аның кимчелекләре, житешсез яклары күпме генә булмасын, әһәмиятле, актуаль мәсьәләләр күтәрү ягыннан караганда, бу драманы һәм аның спектаклен заман темасына багышланган иң уңышлы әсәрләр рәтеннән санарга була. Әмма, кабатлап әйтәм, театрның эш методикасы белән әсәрнең жанры туры килгәнгә генә спектакль шулай уңышлы чыкты.

Инде коллектив башка характердагы драматургия белән очрашканда, психологик драма рецептлары ярамый, алай гына да түгел, әсәрне харап итә. Югарыда сөйләнгәннәрдән чыгып, мин һич кенә дә «психологик театр»ның кирәге юк дип әйтергә теләмим. Аллам сакласын. Башка алымнар һәм стильләр кебек үк, ул да яшәргә хаклы. Яшәргә хаклы, ләкин үзе генә түгел, башкалар белән беррәттән. Без стильләр төрле булсын, һәр әсәрнең үзенә генә ярарлык ачкыч табылсын дигән караштә торабыз.

Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» трагедиясе зур социаль яңгырашка ия булган фәлсәфи әсәр. Трагедия чынбарлык тормыш турында тирән уйланулар белән язылган. Анда кеше, аның тормыштагы урыны, азатлыкка һәм бәхеткә хакы турында сөйләнә. Анда яңа, кыю проблемалар күтәрелә, ул тормышчан, тулы канлы һәм катлаулы характерларга бай. Әсәр гаҗәп эмоциональ, темпераментлы. Труппаның күптән инде мондый көчле, камиль сәнгать әсәре белән очрашканы юк иде. Киң җәмәгатьчелек, шулай ук театр коллективы да, әсәргә зур өметләр багладылар, тамашачылар спектакльне зур түземсезлек белән көтеп алды. Кызганычка каршы, психологик драма стиле бу трагедияне дә харап итте.

Салмак кына, акрын гына вакыйгалар ага (спектакль, хәтта, ритмик яктан да акрынайтылган). Сәхнәдә гади, уртача геройлар йөри, алар, берни дә булмагандай, көндәлек, гадәти тонда сөйләшәләр. Трагик вакыйгалар тамашачыга тәэсир итми, аны дулкынландырмый һәм ул сәхнәдә барган хәлләргә салкын, битараф кала. Театрда тагын бер күнегелгән, гадәтләнгән, төссез, чырайсыз көнкүреш спектакле артты. Без ике гашыйкны һәлакәт юлына этәргән иске фикерле картлар турында тагын бер тамаша карадык. Ә башкорт дәүләт академия театры шушы ук әсәрдән менә дигән спектакль эшләгән иде...

Күренекле драматургыбыз Нәкый ага Исәнбәтнең «Һиҗрәт»е дә бик кызыклы һәм үзенчәлекле әсәр. Әмма аңа да яраклы ачкыч табылмады, ул да чираттагы бер спектакль, вакытлы сәхнә әсәре генә булып калды. «Һиҗрәт» 20 елларда ук язылган. Режиссер, күптән иҗат ителгән шул әсәрне бүген сәхнәләштерергә уйлаган икән, аның заманча яңгырашын да табарга тиеш иде. Совет властеның беренче елларында язылган әсәрне бүген ул чордагыча куеп булмый, билгеле. 20 елларда эмигрантлар турында бертөрлерәк сөйләргә кирәк булган булса, хәзер ул теманы башкачарак, заманга яраклаштырыбрак чишәргә кирәк иде. Революция җиңеп чыкканнан бирле 50 елга якын гомер узды. Чит илләрдә яшәп калган ак эмигрант-

ларның авыр, драматизм һәм трагедия белән тулы тормышы хәзер инде һәркемгә билгеле. Үз халкына, революциягә каршы чыккан кешеләр тормышының мәгънәсезлеген, түбәнлеген фаш итүгә багышланган әсәрне һич тә күңелле, җиңел комедия, Гайнетдин хәзрәт гаиләсенең мажаралары турындагы көлкеле спектакль итеп кенә куярга ярамагандыр, мөгаен. Режиссерның ачык идея позициясе булмау әсәрне таркауландырган, каршылыклы иткән, артистларга тулы канлы образлар тудырырга комачаулаган. Гайнетдин хәзрәт әсәрдә иң тулы, тирән эшләнгән образларның берсе. Хәзрәтне уйнаучы Ф. Халитов урыны-урыны белән образның трагик асылын шактый әйбәт ача. Әмма спектакльдә бөтенлек булмау аңа тәмамланган образ тудырырга мөмкинлек бирмәгән. Спектакльдә пьесаның характерына ятышлы бердәнбер образ — Абдулич образы. Р. Бикчәнтәев башкаруында, бернигә яраксыз һәм кызганыч, һаваланырга яратучы бу мескен кешенең образы бик озакка күңелдә кала. Спектакльнең гомуми контекстыннан аерым караганда, Мөфти (Х. Уразиков), Зөһрә (Н. Гәрәева), Сания (В. Минкина) кебек образлар да әйбәт эшләнгән, уңай бәягә лаек. Ләкин контекст эчендә алар бөтенлек, җанлы организм тудыруга хезмәт итмиләр.

Күрәсез, баштан ахырга кадәр диярлек гел уңышсыз спектакльләр турында сөйләргә туры килә. Югарыда әйтелгәнчә, без спектакльләрнең уңышсызлыгын драматурглар өстенә аударырга гадәтләнеп беттек инде. Бәхәсләшмим, начар пьесадан яхшы спектакль эшләү бик кыен эш. Әмма инде мастерларча язылган әсәрләрне мастерларча куя һәм уйный алмыйлар икән, һәм бу хәл һәр спектакль саен кабатлана икән — борчылмый, чаң сукмый булмый. Беркем дә «Дошманнар», «Һиҗрәт», «Тормыш җыры», «Ай тотылган төндә» кебек, соңгы елларда сәхнәгә куелган әсәрләрнең драматургик материалы йомшак, начар дия алмас. Спектакльләре? Шәп дигәндә — уртакул. Режиссер уйлап житкермәгән, артистлар шәп уйнамый, оформлениесе начар — уңышсызлыкны менә шулай җиңел генә аңлатырга да мөмкин. Ә нигә соң һәр спектакльдә оформление начар була, режиссер уйлап җиткерми, артистлар шәп уйнамый? Әллә безнең театрда күзгә бәрелеп торырлык, үзенчәлекле талантка ия булган артистлар азмы?!. Кем Ф. Ильскаяны, Г. Булатованы, Х. Уразиковны, Ф. Халитовны, Ш. Биктимеровны, Ш. Әсфәндиярованы, В. Минкинаны, Р. Бикчәнтәевне, Р. Шәрәфиевне, Р. Таҗетдиновны һәм башка уннарча артистларны сәләтсезлектә гаепли ала?!. Ныклабрак карасаң, театрның һәр артисты үзенчәлекле, кабатланмас талант иясе бит. Нигә соң әнә шул талантлы артистлар бар да бертөсле, сүлпән, күңелсез уйныйлар? Театрның бүгенге коллективы төрле буын артистлардан тора. Беренче төркемгә Х. Уразиков, Ф. Ильская кебек өлкән буын артистлар керә. Алар янына тагын, яшь ягыннан аерма зур булса да, В. Минкинаны кушарга кирәк. Бу беренче төркемгә кергән артистларның уенына тормышчанлык һәм гадилек хас. Мондый артистлар турында сөйләгәндә, «фәлән артист уйнамый, ә сәхнәдә яши», диләр.

Икенче төркем — урта буын артистлар — образ тудыру, уйнау рәвешләре ягыннан өлкән буыннан шактый аерылып тора. Аларда тамаша күрсәтү тенденциясе көчлерәк, образны аның тышкы сыйфатлары буенча тудыру өстенлек ала. Һәм, ниһаять, өченче буын. Болар, нигездә, Щепкин исемендәге театр училищесында һәм ГИТИСта тәрбияләнгән яшь артистлар. Мондый хәл бер бездә генә түгел. Мәскәү, Ленинград театрлары турында сөйләп тә тормыйбыз инде. Хәмзә, Руставили, Сундукян, Марджанишвили исемендәге театрларны алыгыз! Һәрберсендә төрле буын артистлар уйный. Шуңа карамастан, алар бөтен бер коллектив булып яшиләр, аларның һәрберсенең үз иҗат йөзләре, үз стильләре бар. Татар дәүләт академия театры хакында алай әйтеп булмый.

Менә ун ел инде театрның даими художество җитәкчесе, сәнгатьне тирән аңлаучы, югары эстетик зәвыклы режиссеры юк. Баш режиссерлар алмашына тора, театрның йөзе аз гына да үзгәрми. 20—30 елларда Татар дәүләт академия театры Союзда иң яхшы коллективлардан санала иде. Инде бер тапкыр әйтелгәнчә, ул әле һаман шул елларда ирешкән югарылыктан уза алмый. Кызганыч, бик кызганыч. Ныклы җитәкче-режиссер булмау репертуар мәсьәләсендә дә үзен нык сиздерә. Берәүгә дә сер түгел, театрның репертуары шактый ярлы һәм бертөсле бит. Бездә, күбрәк, бериш, беркалыптагы әсәрләр куела. Театр дөнья һәм совет драматургиясенең бай мөмкинлекләреннән тиешенчә файдаланмый. Ни өчендер грузин театры Эврипидның «Медея»сын, Ануйлның «Торна баласы»н, Брехтның «Өч тиенлек опера»сын куя. Ни өчендер үзбәк театры Шекспир, Р. Тагор әсәрләрен сәхнәләштерә. Ә безгә ярамый. Мин безгә дә нәкъ менә Брехтны куярга кирәк, димим. Дөнья драматургиясе бик бай бит. Эзләнгәндә, әйбәт сәхнә әсәрләрен тугандаш әдәбиятлардан да табып булыр иде. Нишләп безгә дә, төп рольгә Ш. Әсфәндиярованы билгеләп, шул ук «Медея»ны куеп карамаска?.. Бәлки, П. Исәнбәт һәм Ш. Әсфәндиярovалар белән үк, Н. Хикмәтнең «Хатыннар бунты»н да уйнап буладыр?.. Эш тагын баш режиссер проблемасына килеп терәлә. Күптән түгел директор итеп Р. Җиһаншина куелды. Ул үз эшен начар башкармый. Ләкин директор режиссер түгел һәм аны алмаштыра да алмый. Бүгенге театрда режиссер, бигрәк тә баш режиссер — төп фигура. «Театр режиссерсыз яши алмый, — дип яза Г. Товстоногов. — Нәкъ менә режиссер театр белән җитәкчелек итә һәм аның иҗат линиясен билгели. Театр сәнгатендәге теләсә нинди мәсьәлә режиссерга бәйле. Спектакль өчен иң зур җаваплы кеше — режиссер. Начар пьеса, начар уйнаучы артистлар өчен дә һәм тиешсез урыннарда көлеп утыручы тамашачылар өчен дә җавапны ул бирә. Театрда режиссерның роле, урыны турында күпме генә бәхәсләр бармасын... тормыш, беркем дә кире какмаслык итеп, бер нәрсәне раслады: театрның бүгенгесе һәм иртәгеге көне нигездә режиссерга бәйле. Чөнки театрның яшәве өчен кирәкле барлык буыннарны режиссер ялгый, ул тоташтыра. Режиссер зур мәгълүматлы кеше булырга тиеш. Ул музыканы һәм сынлы сәнгатьне, сәхнәне, хәтта хуҗалык һәм оештыру мәсьәләләрен дә яхшы белергә тиеш». Безнең театрның шундый җитәкчесе юк та инде. Дирекция һәм артистлар коллективы күпме генә тырышмасыннар, күпме генә азапланмасыннар, талантлы режиссердан башка театрда алга китеш булмаячак.

Безнең академия театры, реалистик сәхнә, сәнгать дөреслеге законнарына таянып иҗат итә. Әмма моннан 20 ел элек тормышчан, дөрес күренгән әйберләрнең күбесе бүген инде искерде. Тормыш гел үзгәреп тора, тормыш гел алга бара. Һәм сәнгатьтәге дөреслек төшенчәсе дә, нindидер, катып калган, бер дә искерми торган әйбер түгел. Бөтен заманнар өчен дә бердәй ярарлык сәхнә дөреслеге була алмый. Заманнар узу белән, театр сәнгате законнары да үзгәрәләр, искерәләр, алар урынына яңалары, тагын да камилрәкләре туа. Кайчандыр, интеллектуаль культурага, киеренке фикерләү сәләтенә аерым талантлар гына ия булган. Бүген бу сыйфатлар һәр артистта булырга тиеш. Безнең театрга, безнең күп кенә артистларга бу сыйфатлар җитми. Бер дә юкка гына татар интеллигенциясе академия театрыннан бизмәде бит. Безнең күпчелек спектакльләрдә бүгенге тормыш пафосын, яшәүнең мәгънәсе турындагы уйлануларны буш, әһәмиятсез акыл сатулар, ир белән хатын арасындагы низаглар каплап китә. Һәм шуларның барысы бергә, ахыр чиктә, заман тормышын, замандашларыбыз образларын берьяклы, бозып күрсәтүгә китерә.

# Китап күзәтү

## ТОРМЫШ ҺӘМ ХАРАКТЕРЛАР ДӨРЕСЛЕГЕ

Мәсгут Шәрифуллинның «Еллар үткәч» повестена гадәти рецензия язып та «котылып» булыр иде. Менә болайрак дип, мәсәлән:

*Повестьта кирәкле, актуаль мәсьәлә күтәрелә. Кешеләр аңындагы хосусый милекчелек калдыкларының зарарын күрсәтергә, хосусый милекчелек моралең фаш итәргә, коллективизм хисләренең көчен, өстенлеген расларга тели М. Шәрифуллин. Әсәрдә хосусый милекчелек моралена совет яшьләре морале, коммунистик мораль каршы куела. Ике мораль вәкилләре арасындагы бу көрәшне сурәтләрлек оригиналь алым да тапкан автор. Бары шәхси интересларын гына кайгыртып яшәүче иске карашлы атага аның үз улы — Таһирҗан каршы чыга.*

*Әсәрдә Сәмигулла искиткеч начар, вак җанлы бер кеше итеп бирелә. Колхоз эшенә ул эленке-салынкы гына йөри. Колхоз мастерскоеннан тактадыр, тугымдыр урлап ташый. Урланган материаллардан тәрәзә рамнары, көпчәкләр һәм башка йорт кирәк-яраклары ясап, кыйммәт бәягә авылдашларына сата. Улы Дәүләтҗан да атасы сыңары. Аның да бармагы үзенә кәкре, аның да колхоз эшендә әллә ни гаме юк. Авылдашларыннан аерылыбрак, үз кабыгына яшеренебрәк яшәүче шушы гаиләгә солдаттан Таһирҗан кайтып төшә. Төшә дә, җиң сызганып, колхоз эшенә алына. Тора-бара әтисенең кыек эшләрен дә күрә башлый Таһирҗан. Шулай черек нигезгә корылган йортта беренче ярыклар хасыйл була. Әкренләп алар киңәя, зурая һәм, ниһаять, Сәмигулла нигезе тәмам таркала, җимерелеп төшә.*

*Әсәрдә бер уку белән хәтердә калырлык вакыйгалар, эпизодлар байтак. Китап итеп чыгарганда*[1] *М. Шәрифуллин повестен кабат эшләгән. Әсәр шактый кыскарган, җыйнакланып калган...*

Беренче кат укуга, повесть турында шундыйрак тәэсир кала. Һәм, беренче карашка, әсәр мондый гына бәягә лаек та. Безнең әдәбиятта М. Шәрифуллинның «Еллар үткәч» повесте дәрәҗәсендәге әсәрләр байтак. Андый әсәрләр хәзер дә чыккалап тора. Инде байтактан язылып һәм басылып чыккан, укучыларга таныш әсәр турында сүз куертып торуның кирәге дә калмагандыр?!. Бәлки, шушы урында нокта куяргадыр? Безнеңчә, нокта куярга иртәрәк әле. Һәм менә ни өчен.

М. Шәрифуллин матур әдәбият өлкәсендә күптән эшләп килүче, берничә җыентык чыгарган автор. Моңарчы ул, күбрәк, кыска хикәя жанрында эшләде. «Еллар үткәч» повесте — аның зур күләмле беренче әсәре. Тормыш юлын җитди рәвештә

[1] М. Шәрифуллин. Еллар үткәч. Повесть. Татарстан китап нәшрияты, 1964 ел.

язучылык эшенә багышлаган авторга зур күләмле беренче әсәре турында күбрәк һәм төрлерәк фикер ишетү зарарлы булмас дип уйлыйбыз. Бусы мәсьәләнең бер ягы.

Соңгы 10—15 ел вакыт эчендә татар совет проза әдәбияты бик нык үсте һәм камилләште. Прозабызның бүгенге дәрәҗәсе безне матбугатка чыккан һәр яңа әсәргә күп тапкыр җитдирәк, таләпчәнрәк килергә мәҗбүр итә. Шуларның барысын да исәпкә алып хөкем йөртсәк, М. Шәрифуллинның «Еллар үткәч» повестена «гадәти» рецензия генә аз булачак. Инде, әлеге таләпчәнлек дигән әйберне көчәйтә төшеп, әсәрне кат-кат укый башладыңмы — картина шактый үзгәрә төшә. Беренче кат укыганда ук күзгә ташланган җитешсезлекләрнең сәбәпләре ачыклана башлый, күп кенә яңа кимчелекләр, моңарчы сизелмәгән җитешсезлекләр табыла, повесть аерым эпизодлар һәм кисәкләр җыелмасын хәтерләтә башлый. Без монда әсәрдә очраган кимчелекле якларның барысына да җентекләп туктала алмыйбыз. Игътибарны үзебезчә әһәмиятле дип санаган ике мәсьәлә тирәсенә тупларга тырыштык. Аларның берсе — әсәрдә сурәтләнгән тормыш вакыйгаларына авторның карашы, икенчесе — язучының образ иҗат итү принциплары.

Сүзне беренче мәсьәләдән башлыйк. Әйтегез әле: авыл тормышыннан алып язылган бу повестьта кайсы чор, нинди еллар турында сүз бара? Сугыштан соңгы еллар турында, билгеле. Ләкин бу бит үзе шактый зур чор. Сугыштан соңгы 20 ел вакыт эчендә колхоз авылы күп үзгәрешләр кичерде, зур үсеш юлы үтте. «Еллар үткәч» повестенда, конкрет алганда, шушы үсеш юлының кайсы этабы сурәтләнә соң? Сез әсәрдән бу сорауга җавап таба алмассыз. Повесть башланганда авыл халкының хәле, тормышы бик авыр була. Йортлар җимерек, абзарлар сөрлеккән, буралар буш тора... Барлы-юклы икмәкне дә заданиегә түләтеп бетерәләр икән. Шуңа да бит, бер атны буш торткан өчен биш хезмәт көнен кискәч, «Нигә егерме бишне кисмәдегез!» — дип көлә Дәүләтҗан. Инде әсәрнең соңгы яртысына карагыз. Бөтенләй башка дөнья! Калай түбәле йортлар, яңа каралтылар, такта коймалар. Кешеләр дә бөтенләй үзгәргән. Күңелләре күтәренке, йөрәкләре дәртле. Өстәвенә елы шәп килә. Игеннәр «котырып» уңа, уңышны искитмәле бүләләр. Задание дә түләтмиләр, ахры?.. Дәүләтҗан да хезмәт көне кисү кебек мәсьәләләргә бөтенләй башкача карый хәзер. Һәм әсәрдәге шаккатмалы шушы үзгәрешләр нибары бер ел, елдан аз гына артыграк вакыт эчендә булып ала. Ышандырамы бу? Юк, әлбәттә. Авыл хуҗалыгындагы кыенлыклар мондый әсәрләрдә сурәтләнгәнчә җиңел хәл ителә торган булса, колхоз авылы инде күптән коммунизмга җиткән булыр иде.

Бер бу мәсьәләдә генә түгел, башка урыннарда да язучы тормыш күренешләренең закончалыгы, эчке хасияте белән артык санашып тормый. Мөлкәтбаевлар Наратлыда гомер-гомердән яшиләр. Сәмигуллаңыкыларның ниндиерәк кешеләр, кем икәнлекләрен авыл халкы, билгеле, күптән белеп бетергән инде. Монда бернинди шик булырга мөмкин түгел. Автор исә, Сәмигулланың колхоз эшеннән качып йөрүче әшәке, карак кеше булуы турында сөйли-сөйли дә, бервакыт укучыны Мөлкәтбаевларның Наратлыда абруйлы, авторитетлы кешеләр булып йөртелүләрен исбатларга тотына. Ни өчен диярсез? Сәмигуллага улы Дәүләтҗанны өйләндерергә кирәк. Килен итеп бригадир Зәки кызын — Галияне алырга кирәк. Шунсыз эш барып чыкмаячак. Һәм Галия, Дәүләтҗанның кем икәнен бөтенләй белмәгәндәй, аңа кияүгә чыгарга була. Коммунист Зәки шул эшкә ризалык бирә...

Алдынгы колхозчыларны бүләкләү болай тормышта була торган нәрсә үзе. Гадәттә көзге байлыкны җыеп алгач эшләнә бугай ул. М. Шәрифуллин исә уракка төшәр алдыннан бүләкли. Чөнки авторга Сәмигулланы көнләштерергә, аңа тагын бер мәртәбә удар ясарга ки-

рәк. Кур, янәсе, бездә эшләгән кешенең кадерен беләләр, тырышып эшләсәң, син дә буш калмас идең.

Повесть гаҗәп эффектлы вакыйга белән — Сәмигулла абзыйның, күршесе Мәрданша бакчасына төшеп, хурлыкка калуы белән башлана. Истә калырлык, мавыктыргыч эпизодлар әсәрдә, моннан башка да, күп кенә. Әмма, ныклап тикшереп карасаң, аларның да байтагы ышандырмый. Акыл белән уйлап карaганда, Таһирҗанга буш ат белән Сәмигулла йортына кайтып йөрисе дә юк иде кебек. Чаганлыбаштан алып кайткан машина көпчәкләрен складта калдыргач, атны конюшняга илтергә дә туарырга. Юл өстендә генә бит. Ә ул илтми. Чөнки бу ат белән Сәмигулла абзагыз тагын бер мәртәбә этлек эшләп күрсәтергә тиеш әле.

Саный китсәң, мондый урыннар шактый алар. Әмма санаган кадәресе дә язучының тормыш күренешләренә мөнәсәбәтен ачыклау өчен җитсә кирәк. Реаль чынбарлыкка ул «сезгә мин хуҗа, телим икән майда йөздерәм, телим икән башыгызны ашыйм» дигән караштан чыгып якын килә сыман. Тормыш вакыйгаларын көчләп үз теләгенә буйсындырмакчы, аларны үзенә хезмәт иттермәкче М. Шәрифуллин. Ләкин вакыйгалар агышының реаль мөмкинлеге белән автор теләге каршылыкка керә — тормыш чынлыгы бозыла һәм әсәр ышандырмый башлый. Эшне тормыш күренешләрен үз җаена яраклаштырудан башлаган автор, тора-бара, үзе үк тормыш стихиясенә буйсына, ул таркаулана, чәчелә башлый. Игътибар итегез әле: повесть башланганда язучының игътибар үзәгендә Сәмигулла тормышы иде. Бара-тора дилбегә Таһирҗанга күчә. Алга таба аларның функцияләре дә нык кына үзгәрә. Сәмигулла тормышына бәйле вакыйгалар игътибар үзәгеннән бөтенләй диярлек төшеп кала. Таһирҗан тормышы да икенче планга рак авыша. Аның каравы, әсәргә берөзлексез яңа ситуацияләр, яңа үсеш линияләре керә тора. Күләме зур булмаган, егермегә якын кечерәк бүлекчәләрдән торган әсәргә, урта бер җиргә җиткәч, шофер егет Зөфәр килеп керә. Шул урыннан Зөфәр — Минҗан арасында мәхәббәт линиясе башлана. Инде әсәр бетә дип торганда, XVI бүлекчәдә, Әсгать катнашып китә. Автор Әсгать белән Галия арасындагы мәхәббәт тарихын сөйләргә керешә. Яңа ситуацияләр һәм үсеш линияләре повестьны тагын да таркауландыра төшәләр, аны күп планлы итәләр. Алай гына да түгел, алар язучыны үз якларына аударалар. Һәм автор, тормыш вакыйгалары стихиясенә бирелеп, һәр линияне ахырга, соңгы ноктага кадәр дәвам итәргә мәҗбүр була. Таһирҗан Зәйнәпкә, Зөфәр Минҗанга өйләнә. Әсгать белән Галия арасындагы мөнәсәбәтләрнең дә уңышлы тәмамланачагына безнең шигебез калмый...

Язучы эшне тормыш вакыйгаларын үзенә кирәкле уңайга яраклаштырудан башлаган иде. Ахыр чиктә моның нәкъ киресе булды. Моннан бик гади һәм күптән билгеле бер хакыйкать чыга инде. Реаль чынбарлык аны теләсә кайсы якка бору, үзгәртү өчен язучы карамагына тапшырылган чимал түгел икән. Ул үзбаш яши, кемгә дә буйсынмый һәм буйсынмаячак. Димәк, язучы үзе аны өйрәнергә, белергә, аның белән санашырга тиеш була.

М. Шәрифуллинның әдәби образларга карашы да тормыш вакыйгаларына карашы кебек үк берьяклы, образлар аңа, тулы канлы, тере кеше булудан бигрәк, берәр вазифа башкару өчен генә кирәк дип раслау — дөрес үк булып бетмәс иде. Әмма әдәби образларга мөнәсәбәтендә дә шундыйрак бернәрсә үзен шактый сиздерә.

Повестьта истә калырлык, уңышлы эшләнгән образларның берсе — Сәмигулла. Дөрес, бер урында ул Галимҗан Ибраһимовның Җәләш мулласы тибындагы дан, шөһрәт яратучы карт булып чыгыш ясый; икенче төштә — эштән чыккан саран; ул да түгел, шушы әшәке карт халыкның начар яшәвенә, тол хатыннарның авыр язмышына ачынып кайтып килә. Ярар, шулай да булсын, ди. Ләкин автор, безнең уебызча, Сәмигулла характерының эчке

пружинасын җитәрлек ачмаган. Шуңа да аның бер халәттән икенче халәткә күчүе, үзгәрүе һәр урында да ышандырып бетерми. Таһирҗаннан бүгенге авыл яшьләренең типик образын гәүдәләндерерлек матур характер тудырып булыр иде. Автор тарафыннан уңышлы сайланган образ ул. Таһирҗан образы, урыны-урыны белән, шактый ачылып китә. Безгә ошап та куя, үзен яраттыра да бу образ. Ләкин Таһирҗан образының үстерелешендә дә эзлеклелек җитеп бетми. Күп урыннарда автор образның характеры, логикасы белән санашып тормый, аны җанлы курчак, вазифа башкаручы дәрәҗәсенә төшерә.

Кайта-кайтышка үз йортындагы атмосфера ошамый егеткә. Әтисе дә әллә нишләгән, абыйсы да... Күрәсең, Таһирҗан армиягә киткәнче Сәмигулла абзый яхшы кеше булгандыр инде. Әтисенең тол хатын белән көпчәкләр өчен сатулашуы аеруча күңелен төшерә егетнең. Бу йортта аңа, ничектер, тынчу булып китә. Ул, урамга чыгып зур таш өстенә утыра да, чылтырап аккан чишмәгә карап, уйга кала. Үткән гомере дә, хәтердә сакланган вакыйгалар да күз алдына килә. Барысы да ышандыра, әйбәт кебек. Тик әтисе йортыннан боегып, күңеле төшеп чыгып киткән егетнең күз алдына нинди вакыйгалар килүен карагыз сез. Гел машина, техника, МТС... Без инде шикләнә башлыйбыз. Тукта, автор безне «машина җене» кагылган егетнең биографиясе белән таныштыру өчен генә тырышмыймы? Нәкъ шулай икән...

Шактый уйланып утыргач, ул алачыкка таба китә. Әйбәт кешеләр янына барасы, алар белән аралашасы, караңгы уйлардан арынасы килә бугай егетнең дип юрыйбыз без. Баксаң, бөтенләй башка эш белән икән. Автор Таһирҗанга тизрәк теге машина калдыкларын күрсәтергә тели икән.

Таһирҗанның тагын бер кызык гадәте бар. Ул бер дә кирәксезгә кызып китә, әтәчләнә, гайрәт күрсәтә, ә нәкъ менә гайрәтләнергә, кызарга тиешле урыннарда авызына су кабып кала. Безгә калса, Таһирҗан әтисе белән булган конфликтта бик нык ачылырга, үсәргә тиеш иде кебек. Ләкин ул конфликтка динамика, үсеш, бөтенләй җитми. Янып, дөрләп китә алмаган учакны хәтерләтә ул. Автор, килеп, нык итеп бер өргәч, кинәт кабынып, ялкынланып китә. Инде, учак дөрләп кабынгач, шартлар дәрәҗәгә җиткәч кенә, я Сәмигулла, я Таһирҗан йомшый. Әшәке Сәмигулла малайны, бәлки, үз ягыма аударып булыр дип өмет өзми. Таһирҗан исә эти чыннан да начар кешеме икән, бу йорттан китәргәме-юкмы дип шикләнеп йөри... Сигезенче бүлекчәдә учак яңадан дөрләп китә. Әтисенең начар кеше булуына тәмам ышанып җиткән, ярсыган Таһирҗан аның кулыннан үлчәү таягын тартып алып, берничәгә сындыра да, читкә томыра. Менә хәзер күптән көтелгән шартлау булачак! Моннан соң инде Таһирҗан бу йортта кала алмаячак! Юк, шартлау булмый кала, учак тагын сүнә. Автор исәбе буенча, иртәрәк икән әле. Һәм язучы үзе үк кыздырган, соң чиккә җиткергән конфликтны сүрелдерә төшә. Сәмигулла белән Таһирҗан, берни булмагандай, яңадан тыныч кына яши башлыйлар. Һәм әнә шул күп тапкырлар кабатланган дөрләү-сүнүләр дәвамында Таһирҗан образы да һаман сүрелә, чырайсызлана бара. Һәм менә бер заман, уйламаганда, көтмәгәндәрәк, шартлау тавышы яңгырый. Туган йортын, эти-әнисен ташлап, Таһирҗан чыгып китә.

Әсәрдә катнашучы персонажлар болар белән генә чикләнми, билгеле. Сәмигулла белән Таһирҗаннан тыш та, повестьта дистәгә якын персонаж бар. Повестьтагы вакыйгалар барышында төрлесе төрле дәрәҗәдә катнашучы бу персонажлар арасында Таһирҗан белән Сәмигулла кадәр үк эшләнгәннәре юк диярлек. Аларга киңләп тукталып тормыйча да, М. Шәрифуллинның әдәби образ тудыру принциплары турында мәгълүм бер фикергә килергә мөмкин кебек. Авторның теге яки бу эпизод аша әйтергә, үткәрергә теләгән ниятенә карап, әсәрдәге образлар да гел үзгәреп торалар. Бер үк образ бер картинада бер

кыяфәттәрәк күренсә, икенче урында инде бөтенләй башкарак планда ачылырга мөмкин. Без катлаулы, күпкырлы кеше характерларына каршы түгел. Ләкин М. Шәрифуллин иҗат иткән образларның бер кыяфәттән икенче төскә керүләре дәлилләнмәгән, ышандырып бетерми, повестьтагы характерларга эчке бөтенлек җитми.

Әнә шул без монда тукталган һәм әле телгә дә алмаган эпизодларны, төрле вакыйгаларны, ышандырырлык, җанлы кеше булып эшләнеп җитмәгән образларны бер бөтен итеп оештырырга, әдәби әсәр итәргә туры килгән М. Шәрифуллинга. Дөресен әйтергә кирәк, бу эшкә ул зур көч куйган. Һәм билгеле дәрәҗәдә теләгенә ирешкән дә. Әмма игътибар беләнрәк карарга тотындыңмы, җөй урыннары, ак җепләр күренеп тора. Повестька сюжет-композиция төзеклеге җитми, ул мавыктырмый, авыр укыла.

Ярар, шулкадәр көч куеп язылган бу әсәре белән М. Шәрифуллин укучыларга моңарчы кабатланмаган нинди яңа фикер әйтергә теләгән соң? Әйтүе бик кыен. Бөтен бәла дә менә шунда инде. Авторның укучыга әйтергә теләгән яңа фикерен, ачышын күрү бик кыен бу повестьтан. Шуңа әсәр таркау чыккан, шуңа повесть мавыктырмый.

*Ф. МИННУЛЛИН.*

### УДМУРТ МӘКАЛЬЛӘРЕ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘРЕ

Чиста эшне эшләргә пычрак куллар ярамый.
Якын дус янына барсаң — озын юл да кыскара.
Үзең дә һәлак булма, дусларыңны да сакла.
Сыерчык белән саескан бер ояга сыешмый.
Кизләү кипсә, елга да кибә.
Зур көтү бүредән курыкмый.
Биеклеген белим дисәң, тауның түбәсенә мен.
Аз гына белер өчен дә бик күп укырга кирәк.
Бәйләгәнеңне чишә бел.
Күзләр еракка карый, акыл — тагы да арырак.
Баш уйсыз түгел, уй башсыз булмый.
Кулларга баш булышса, эшләр җиңелрәк бара.
Бик хәйләле төлке дә капкынга килеп каба.
Җиде елга кичеп тә аякларын чылатмый.
Койрыгы кыска булмаса, ул да куян тотасы.
Көчле кеше кыйнашмый.
Ат җиккәндә дуга бөкмиләр, кышын арба җикмиләр.
Кадагын саклап дага югалган.
Төлкенең койрыгы башыннан кыйбат.
Күлмәгең булса, төймә табылыр.
Күктәге болытка карап җирдә урын билгеләмә.
Ябык авызга чебен керә алмый.
Кызу пешкән аш көя.
Җирнең мае — ашлама.
Бер көнгә иртәрәк чәчсәң — бер атна алдан урырсың.
Игенченең хакиме — көз.
Биттән пычрак тиз юыла, ә тормыштан — юылмый.
Харам акча кесә тишә.
Кеше балыгы сөяксез була.
Саран базарга чыкса — намусын да сатачак.
Саранның сүзе «юк» белән бетә.
Туры сөйләп кыек эшләмә.
Ялагай да баш игәнне көтә.
Кабып йотар алдыннан төлке дә тавыкны мактый.
Китеп югалган сарыкка бик күп хуҗа табыла.
Мыштым зат каты тешли.
Ал көпчәк кайда барса, артнысы шунда узар.
Юаш сарыкны кыркуы җиңел.

# Яңа китаплар



*Т. Миңнуллин*

## ДУСЛЫК ХАКЫНА

Яшь прозаик Туфан Миңнуллин республикабыз газета-журналларында шактый еш басылып килгән юмористик хикәяләре белән укучыларга беркадәр таныш иде инде. Әле күптән түгел генә Татарстан китап нәшрияты бу яшь авторның «Дуслык хакына» исемле беренче җыентыгын бастырып чыгарды. «Фирдәвес, Нәҗибә һәм мин», «Әче мәхәббәт», «Бәхил бул, Нәфисә», «Аучы», «Дуслык хакына», «Гаян апа», «Майбәдәр батыр», «Казанны ягам», «Туй», «Дәрәҗә бәласе», «Порука», «Прастуй эшче», «Ярты помидор», «Пөхтәлек үрнәге», «Бер минут», «Сәнгать һәм Аллаяр Болгаерович», «Су кыярда да бар», «Телеграмма», «Футбол вакыйгасы» исемле хикәяләрне эченә алган бу җыентык нигездә җинел укыла һәм күңелдә елмаю хисләре уята торган юмористик әсәрләрдән тора. Дөрес, ул әсәрләренең барысын да әдәби яктан камил эшләнгән дип булмый. Әйтик, әдәби әсәр өчен бик кирәк булган нәрсәсе — вакыйгасы уңышлы сайланмаган һәм юморы да чамалы гына булган «Әче мәхәббәт», «Аучы» кебек хикәяләр дә бар анда. Аларны җыентыкка кертми калдыру хәерлерәк булыр иде шикелле. Ләкин, руслар әйтмешли, беренче белен төерсез булмыйдыр инде, күрәсең.

Ә гомумән алганда, Т. Миңнуллинның әлеге җыентыгын укучылар җылы каршыларлар диясе килә. Ни өчен дигәндә, соңгы елларда безнең өлкән язучыларыбыз юмористик хикәяләр язудан, бөтенләй үк булмаса да, шактый читләштеләр бит. Шунлыктан, укучылар андый әсәрләрне бик сусап, зарыгып көтәләр иде.

## ДУСЛЫК

Соңгы дүрт-биш ел эчендә әдәбиятыбыз мәйданында яшь язучылар тавышы шактый нык һәм ышанычлы булып яңгырый башлады. Рәдиф Гатауллин, Клара Булатова, Мөхәммәт Садыйков, Шамил Маннапов, Нурмөхәммәт Хисамов, Данис Хәбибуллин, Борһан Садретдинов, Хәниф Хөснуллин — бу яшь шагыйрьләрнең әсәрләре республикабызда чыгып килә торган газета-журналлар битләрендә еш кына күренгәләп тора. Шушы көннәрдә генә Татарстан китап нәшрияты әлеге сигез яшь шагыйрьнең әсәрләреннән төзелгән «Дуслык» исемле җыентык бастырып чыгарды. Һәр авторның ун-унбиш шигыре урнаштырылган бу җыентыктан шул нәрсә ачык күренә: аларның һәркайсы үз тавышы белән җырларга, үз юлын табарга, башкаларны кабатламаска тырыша. Яшьләргә хас булган зур эшләргә омтылу да:

Ах, минем дә килә киң
юлларның
Иң яктысын сайлап
аласым,
Гел кояшка карап,
гел кояшка карап,
Гел кояшка карап
барасым.
*(К. Булатова.)*

сөю-шаяру да:

Өскә карап тилмерәм
гел,
Түбән чагың була сирәк
Үзем кебек җирдә
йөргән
Миңа башка иптәш
кирәк.—
Дигән идем уйнап кына,
Нигә инде үпкәләдең?
Авыр йөкләр күтәргәнне,
Шул сүзләрне
күтәрмәдең?..
*(Д. Хәбибуллин, «Кранчы кызга».)*

кешеләрнең уңышына эчкерсез куану да, кимчелекләргә чын күңелдән әрнү дә бар аларның шигырьләрендә. Җыеп кына әйткәндә, «Дуслык» исемле бу шигъри җыентыкны укыгач, аның авторларына карата күңелдә җылы хисләр уяна һәм алар киләчәктә тагын да яхшырак әсәрләр язарлар әле дигән өмет туа.

## ГЕРОЙ БАЛАЛАР

Балаларның батырлыклары, зурларга ярдәм итеп, кайчакта бик зур әһәмияткә ия булган эшләр башкарулары турында хикәяләр, очерклар һәм мәкаләләр республикабыздагы вакытлы матбугат битләрендә әледән-әле чыккалап торса да, моңарчы әнә шул батыр балалар турында кулга тотып карарлык аерым китап юк иде әле бездә. Күрәсең, менә шул хәлне искә алыптыр, бу ел Татарстан китап нәшрияты «Герой балалар» исемле җыентык бастырып чыгарган. Җиде ярым басма табактан торган бу җыентыкка егерме авторның очерк һәм хикәяләре тупланган, һәм ул әсәрләрдә нигездә гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы чорында балалар эшләгән батырлыклар турында сүз бара.

Китапка кертелгән барлык әсәрләр дә русчадан тәрҗемә ителгән. Ләкин аларның тәрҗемә икәнлеге һич тә сизелеп тормый. Җыентыкны тәрҗемә иткән Т. Таһирова, Р. Вәлиева һәм Р. Гыйззәтуллина иптәшләр һәр әсәрне татарча уңышлы яңгырашлы итәргә тырышканнар һәм шул максатларына ирешкәннәр дә. Яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләү өчен көрәш барган хәзерге чорда «Герой балалар» исемле бу китапның дөньяга чыгуы бик вакытлы хәл. Батырлыкка омтылучы, романтик табигатьле балаларыбыз кызыксынып һәм яратып укырлар аны.

### УДМУРТ МӘКАЛЬЛӘРЕ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘРЕ

Нинди чиста аракы да тормышны болгандыра.
Куркак күзләр мәчене дә аюдай итеп күрә.
Курыккан куян әткә каршы чаба.
Уйлары — күктә, үзе — идәндә.
Җирнең күрке — үсемлек, ә кеше күрке — хезмәт.
Тынгысыз кеше йөрәген беркайчан да май басмас.
Кешегә өстән карасаң, намусың түбән була.
Казаныңда ашың булса, чүмеч табылмый калмас.
Каргадан сандугач тумый.
Балалары булмаса, ир белән хатын ятим.
Елан да тыштан ялтырый.
Сөзгәк сыер мүкләк булып туа.
Көнче кеше уникe күзле.
Дошманыңны җәлләсәң — үзең һәлак булырсың.
Төлке йокыга ятса да, тавык санап төш күрә.
Җәй әзерли, кыш ашый.
Тау бар җирдә тугай да була.
Иртә аткан чәчәк — җимешсез.
Ат эчергәндә — сызгыр, кунак сыйласаң — җырла.
Кунакка барсаң — бәхәс кузгатма.
Коры сәлам тиз сына.
Черек агач — каты ботаклы.
Миләштән алма көтмә.

Сайлап тәрҗемә итте: Зәки Нури.

# ӘДӘБИЯТ һәм СӘНГАТЬ яңалыклары

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Татарстан язучылар союзы партия оешмасының 31 августта уздырылган ачык җыелышында бүгенге драматургия мәсьәләләре каралды. Язучылар союзы каршындагы драма секциясенең председателе Риза Ишморат татар драматургларының иҗат планнары белән таныштырды, аларның нинди яңа әсәрләр өстендә эшләүләрен сөйләде. Татарстан АССР Культура министрлыгының сәнгать бүлеге начальнигы, театр белгече Ильтани Иляловa соңгы елларда язылган сәхнә әсәрләренең җитлеккәнлек, әдәби эшләнеш дәрәҗәләре турында сөйләде, драматургларыбыз каршында торган мөһим бурычларга тукталды.

Бүгенге драматургиябезнең торышы турында фикер алышуларда «Азат хатын» журналының җаваплы редакторы Асия Хәсәнова, Минзәлә дәүләт драма театрының директоры Мулланур Мостафин, филология фәннәре кандидаты, театр белгече Бәян Гыйззәт, Республика күчмә театрының баш режиссеры Равил Тумашев, Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры режиссеры Шириязданн Сарымсаков, язучы Мария Елизарова һәм башка иптәшләр катнашты.

●

14 сентябрьдә Татарстан язучылар союзы партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булып үтте. Җыелышта отчет доклады белән Язучылар союзы партия оешмасының секретаре Ләбибә Ихсанова чыкты. Докладчы шагыйрьләр, прозаиклар, драматурглар һәм тәнкыйтьчеләрнең иҗат уңышларын билгеләп үтте.

— Социалистик реализм принципларына турылыклы булган Татарстан язучылары бай һәм күпкырлы чынбарлык тормышка тирәнрәк үтеп керү, коммунизм җәмгыяте төзүче замандашларыбызның образларын бөтен тулылыгы һәм катлаулыгы белән сурәтләп бирү юлында җитди уңышларга ирештеләр. Соңгы елларда иҗат ителгән күп кенә әсәрләребездә бүгенге көннең актуаль проблемалары, замандашларыбызның истә калырлык образлары белән очрашабыз,— диде докладчы. Докладта әдәби иҗат эшендәге аерым кимчелекләр, җитешсез яклар турында да сүз байтак булды.

Л. Ихсанова доклады буенча фикер алышуларда Госман Бакиров, Мөхәммәт Садри, Хәй Вахит, Зәки Нури һәм Галимҗан Латыйп катнашты. Алар совет язучысының мораль йөзе, яшь язучыларны тәрбияләү, китап сәүдәсен яхшырту һәм башка мәсьәләләр турында әһәмиятле фикерләр әйттеләр.

Җыелыш ахырында КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. З. Тутаев речь белән чыкты. Ул язучыларны Татарстанның халык хуҗалыгы һәм республикада барган культура эшләре белән таныштырды. М. З. Тутаев Бөек Октябрьның һәм Татарстанның 50 еллыгы, Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел якынлашу уңае белән сәнгать кешеләре алдында торган зур һәм мөһим бурычлар турында сөйләде, Татарстан язучыларын халкыбызның бөек эшләренә лаеклы булырлык әдәби әсәрләр иҗат итәргә чакырды.

Язучылар союзы партия оешмасының яңа бюросы составына М. Әмир, И. Гази, Г. Минский, Г. Гобәй, Л. Ихсанова, Г. Паушкин, З. Нури һәм Р. Мостафин кертелде. Секретарь итеп Г. Минский сайланды.

## ЭШ КҮРСӘТКӘН ИРНЕ ИЛ ОНЫТМЫЙ

Август аенда татар халкының бөек улы, турылыклы ленинчы Мулланур Вахитовның тууына 80 ел тулды. Бу зур дата Татарстанда һәм бөтен илебездә киң күләмдә билгеләнеп үтелде. Республика газета-журналларында һәм үзәк матбугатта Мулланур Вахитовның тормыш юлын һәм эшчәнлеген яктырткан мәкаләләр, замандашларының һәм көрәштәшләренең ялкынлы революционер турындагы истәлекләре басылды.

●

Мәскәү шәһәре хезмәт ияләренең Мулланур Вахитов истәлегенә багышланган тантаналы җыелышы башкаланың Тарихи китапханәсе залында уздырылды. Анда М. Вахитовның тормыш юлы һәм революцион эшчәнлеге турында доклад белән 1917 елдан КПСС члены, отставкадагы генерал-лейтенант Якуп Чанышев чыкты. 1917 елдан КПСС члены, запастагы полковник А. Маликов, 1917 елдан КПСС члены, персональ пенсионер П. Шумилов, 1919 елдан КПСС члены, персональ пенсионер М. Шаһиәхметов, журналист Г. Ишмаев, Н. Сәйфи һәм башкалар куркубелмәс ленинчы большевик турында кызыклы истәлекләр сөйләделәр. А. Галикәев иптәш үзенең чыгышын татар әдәбия-

тында Мулланур Вахитов образы дигән темага багышлады.

●

Казан шәһәре хезмәт ияләренең М. Вахитовның тууына 80 ел тулуга багышланган тантаналы утырышы КПСС өлкә комитетының конференц-залында 30 августта үткәрелде. Җыелышны, М. Вахитовның революцион эшчәнлеге турында кыскача кереш сүз белән, КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф. А. Табеев ачты. Мулланур Вахитовның тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» газеталары редакторы Ш. Х. Хамматов доклад ясады.

●

Мулланур Вахитовның якты истәлегенә багышланган тантаналы җыелышлар Идел буе районындагы М. Вахитов исемендәге I нче китапханәдә һәм республиканың күп кенә культура сарайларында, клубларында, уку йортларында, предприятиеләрендә дә үткәрелде.

●

Тагын бер зур вакыйга. Гражданнар сугышы елларында Татарстан республикасын акгвардиячеләрдән азат итүдә турыдан-туры катнашкан легендар полководец Владимир Мартынович Азинның тууына сентябрь аенда 70 ел тулды. Бу юбилейны да республикабыз җәмәгатьчелеге зурлап уздырды. Республика предприятиеләрендә, колхозларда һәм совхозларда, уку йортларында В. М. Азинның тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында беседалар, лекцияләр, докладлар ясалды, карт большевиклар, гражданнар сугышы ветераннары белән очрашулар оештырылды.

23 сентябрь көнне шәһәребез җәмәгатьчелеге Татарстан дәүләт музеена Азин истәлегенә багышланган тантаналы утырышка җыелды. Ялкынлы революционер, данлыклы полководецның тормыш юлы һәм батыр көрәше турында СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, тарих фәннәре докторы М. Мөхәррәмов сөйләде. Җыелышта Азинны якыннан белгән, аның белән бергә көрәшкән гражданнар сугышы ветераннары истәлекләр белән чыктылар.

●

Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең якты истәлеген мәңгеләштерү өчен инде күп эш башкарылды. Дөньяның бик күп телләрендә, зур тиражлар белән, патриот шагыйрьнең китаплары чыкты һәм чыгып тора. Муса Җәлилнең тормыш юлын һәм иҗатын тикшерүгә багышланган аерым мәкаләләрне һәм хезмәтләрне дә санап бетергесез. Татарстандагы театрларның берсе Муса Җәлил исеме белән йөртелә, хәзерге көндә республикада салына торган иң матур, иң гүзәл шәһәр дә аның исеме белән йөртеләчәк. Муса Җәлил исемендәге шәһәр һәм поселок урамнарын, Культура сарайларын һәм клубларны, уку йортларын һәм кинотеатрларны, пионер дружиналарын, колхозларны һәм совхозларны киң илебезнең теләсә кайсы почмагында очратырга була.

Тиздән Минзәләдәге педагогия училищесы бинасының белдерү тактасына да легендар шагыйребез Муса Җәлил исеме өстәләр. Күптән түгел, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы указы белән, Минзәлә педагогия училищесына Муса Җәлил исеме бирелде.

## ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Мәрхәмәтсез үлем аның үзен безнең арадан алып китте инде. Ә исеме халык телендә калды, әсәрләре сәхнәләрдән төшми. Таҗи Гыйззәт татар совет әдәбиятының бик үзенчәлекле һәм талантлы драматургы иде. Безнең әдәбиятка ул күп санлы тулы канлы образлар өстәде, театр сәнгатебезне дистәләрчә драмалар, комедияләр һәм либреттолар белән баетты. Күренекле драматургның тууына 70 ел тулу бәйрәме, зур итеп, бөтен республика күләмендә үткәрелде.

●

Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлеге һәм Әлмәт татар дәүләт драма театры Таҗи Гыйззәтнең 70 еллыгын нефтьчеләрнең Техника йорты бинасында 11 сентябрьдә билгеләп үттеләр. Кичәне КПСС-ның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре С. Хәкимова ачты. Таҗи Гыйззәт турында истәлекләр белән күренекле драматургның замандашы, Әлмәт театрының баш режиссеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Габдулла Юсупов чыгыш ясады. Театр коллективы тамашачыларга Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар» драмасын күрсәтте.

●

ТАССР һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Таҗи Гыйззәт истәлегенә багышланган тантаналы кичә Казан шәһәрендә 22 сентябрьдә Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында булды. Драматургның тормыш һәм иҗат юлы турында доклад белән филология фәннәре кандидаты Бәян Гыйззәт чыкты. Драматургның замандашлары — язучылар, артистлар — Т. Гыйззәт турында истәлекләр сөйләделәр. Соңыннан Таҗи Гыйззәт әсәрләреннән төзелгән зур концерт бирелде. Концертта аерым спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде, җырлар, арияләр башкарылды.

## ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНДА ӘДӘБИЯТ АТНАЛЫГЫ

Татарстан районнарында әдәбият атналыклары уздыру матур бер традициягә әйләнеп бара. Соңгы бер-ике ел эчендә генә дә татар язучылары, Чистай, Зеленодольск,

Арча, Әгерҗе һәм республиканың башка күп кенә районнарында булып, район культура йортларында, китапханәләрдә һәм мәктәпләрдә, колхоз клубларында һәм кыр станнарында китап укучылар белән очраштылар, конференцияләр уздырдылар.

Авыл халкы язучыларны бик җылы каршы алды, атналык көннәре һәр җирдә чын сәнгать бәйрәме төсендә үтте. Сентябрь аенда шундый атналыкларның берсе Татарстанның Октябрь районында булды. Татар язучылары Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, Г. Минский, М. Садри, З. Нури, С. Сабиров, Г. Афзал, М. Фәйзуллина, К. Фәсәхов, чуваш язучылары И. Малгай, А. Воробьев, П. Петров һәм М. Егоров район мәктәпләрендә укучылар һәм укытучылар, авылларда колхозчылар белән очраштылар, матур әдәбият сөючеләргә үзләренең иҗат планнары турында сөйләделәр, яңа әсәрләрен укыдылар.

## АСТРАХАНЬ ХАЛЫК ТЕАТРЫ

Нәриманов исемендәге Астрахань татар халык театры илебездәге иң көчле үзешчән коллективлардан санала. Гатаулла Нуруллин җитәкчелегендәге бу театр коллективы шәһәрнең культура сарайларында, клубларда һәм завод цехларында, Астрахань өлкәсендәге авылларда һәм поселокларда, балык промыселларында һәм кыр станнарында ел саен 70 кә якын спектакль күрсәтеп килә. Һәм аның спектакльләрен һәркайда яратып, бик җылы каршылыйлар.

Соңгы берничә ел эчендә генә дә бу талантлы коллектив татар, рус һәм башка тугандаш халыклар драматургларының дистәдән артык әсәрен сәхнәгә менгерде. Күренекле драматург Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» драмасы һәм башкорт драматургы Ә. Атнабаевның «Ул кайтты» исемле пьесасы буенча эшләнгән спектакльләр аеруча зур уңыш белән бара. Хәзер коллектив Ә. Мирзаһитовның «Әниемнең чал чәчләре» исемле драмасын сәхнәләштерү өстендә эшли.

## КИТАП БӘЙРӘМЕ

19 сентябрьдә традицион китап бәйрәме уздырылды. Бу көнне Максим Горький исемендәге Үзәк Культура һәм ял паркына күренекле шагыйрьләр, прозаиклар, драматурглар, композиторлар һәм артистлар килде. Алар анда, шәһәребезнең меңнәрчә китап сөючеләре белән очрашып, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар, матур әдәбият китаплары сатуда катнаштылар.

## КАЗАНДА «ФОЛЬКЛОРИКО ДЕ МЕХИКО» БАЛЕТЫ АРТИСТЛАРЫ

Быел җәй шәһәребез тамашачылары бик күп талантлы сәнгать коллективлары белән очраштылар. Без Петрозаводск һәм Рига театрларының спектакльләрен карадык, Ленинградның Акимов театрын һәм казакъ дусларыбызны күрдек. Казан сәхнәләрендә танылган җырчылар һәм биючеләр, эстрада коллективлары чыгыш ясады. Без күп тапкырлар зур сәнгать белән очраштык, күп ләззәт, рухи азык алдык, баеп калдык. Казан чын мәгънәсендә гастрольләр шәһәренә әйләнде.

Инде җәй үтә дип торганда, август аенда шәһәребезгә тагын бер гаҗәп үзенчәлекле һәм талантлы сәнгать коллективы — Мексика артистлары килеп төште. Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында атнадан артык Амалия ханым Эрнандес җитәкчелегендәге «Балет фольклорико де Мехико» артистлары чыгыш ясады. Кубада, Канадада, АКШта, Франциядә һәм дөньяның башка күп илләрендә булып, зур уңыш казанган бу коллективны шәһәребез тамашачылары гаять җылы каршылады. Атнадан артык тамаша залы халык белән тулы булды, атнадан артык театр бинасында көчле алкышлар яңгырады. «Балет фольклорико де Мехико» артистлары безне ерак Мексика, талантлы мексикалылар, аларның бик бай һәм үзенчәлекле борынгы культурасы белән таныштырдылар.

Кунаклар үз сәнгатьләрен генә күрсәтеп калмадылар, алар татар халкы, аның культурасы һәм бай тарихы белән дә таныштылар. Мексикалы дусларыбыз Казан шәһәрен карадылар, истәлекле урыннарда, музейларда, уку йортларында булдылар, гүзәл Иделдә йөзделәр, шәһәр хезмәт ияләре, Татарстан артистлары белән очраштылар. «Балет фольклорико де Мехико» артистларының Казан шәһәрендә булып үткән гастрольләре татар һәм мексика халыклары арасындагы дуслыкны ныгытуда әһәмиятле вакыйга булды.

## МИНЗӘЛӘ ТЕАТРЫ ГАСТРОЛЬЛӘРЕ

Сентябрь аенда Минзәлә татар дәүләт драма театры Яшь тамашачылар һәм В. И. Качалов исемендәге драма театрлары сәхнәләрендә, шәһәребезнең культура сарайларында, клубларында үзенең спектакльләрен күрсәтте. Минзәләлеләр Казан тамашачыларын «Уракчы кыз» (С. Шәкуров), «Кара чәчәкләр» (В. Галимов инсценировкасы), «Бәхет кошым» (Г. Зәйнашева), «Әйтер идем йөрәк серемне» (Р. Ишморатова), «Сылу кызлар» (К. Шангытбаев һәм К. Байсәетов), «Көйсез килен» (С. Өметбаев, Г. Шәрифҗанов һәм А. Аләветдинов) исемле спектакльләре белән таныштырдылар. Тамашачыларда РСФСРның атказанган артисткалары Н. Җиһаншина һәм Х. Сәлимова, Татарстанның халык артисты М. Кичубаев, Татарстанның атказанган артистлары Ә. Фәсхетдинов, М. Зәйнуллин, Р. Шакирова һәм башка артистларның уеннары җылы тәэсир калдырды.

●

10 сентябрьдә Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлегендә Минзәлә теа-

тры спектакльләре буенча фикер алышу булды. Фикер алышуда театр белгечләре, язучылар, артистлар һәм режиссерлар катнашты.

## ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР, ОЧРАШУЛАР, КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

Софья Радзиевская Казан шәһәренең 12 мәктәп укучылары һәм укытучылар коллективы белән очрашты, матур әдәбият сөючеләргә яңа әсәрләрен укыды, иҗат планнары турында сөйләде.

●

Язучы Гариф Галиев Баулы, Бөгелмә һәм Әлмәт районнарында китап укучылар белән очрашты.

●

Р. Кутуй, М. Фәйзуллина һәм К. Фәсәхов Казан авыл хуҗалыгы институты студентлары белән очраштылар, аларга яңа шигырьләрен укыдылар.

●

Сентябрь аенда Васильево ял йортында ял итүчеләр Габдрахман Әпсәләмов һәм Илдар Юзиев белән очраштылар. Г. Әпсәләмов тыңлаучыларга романнарының язылу тарихын сөйләде, сорауларга җавап бирде, Илдар Юзиев шигырьләрен укыды.

●

9 сентябрьдә язучылардан Э. Касыймов һәм И. Юзиев Алабуга педагогия институты студентлары белән очраштылар. Кичәне институтның татар әдәбияты кафедрасы мөдире М. Фәйзуллина ачты. Э. Касыймов студентларны «Казан утлары» журналының киләсе елгы планы белән таныштырды. Илдар Юзиев поэмаларын һәм яңа шигырьләрен укыды.

Шул ук көнне И. Юзиев, Бондюг унберьеллык мәктәбе укучылары янында булып, аларны әдәбияттагы яңалыклар белән таныштырды һәм шигырьләрен укыды.

●

24 августта Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, яшь шагыйрьләр Клара Булатова, Рәшит Әхмәтҗанов һәм Рөстәм Мингалимов (Казан) Муса Җәлил исемендәге нефтьчеләр поселогында очрашу үткәрделәр, яңа әсәрләрен укыдылар. Г. Ахунов патриот-шагыйрь турында кыскача чыгыш ясады. Әлмәт язучылары поселок китапханәсенә үзләренең китапларын бүләк иттеләр.

●

Әлмәткә экскурсиягә килгән Чаллы районы укытучылары Техника йорты залында бер төркем язучылар белән очраштылар. Очрашуда Мәскәү язучысы Алексей Иванович Никитин, Әлмәт язучылары Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, Г. Ахунов катнашты.

●

Игеннәрне урып-җыюның һәлиткеч көннәрендә Әлмәт язучылары колхозларга чыктылар, урыннардагы радио буенча чыгыш ясадылар, механизаторлар белән очраштылар. Г. Ахунов Әгерҗе районы колхозларында, С. Кальметов Сарманда, М. Хәсәнов, Азнакай эшчеләре поселогы Культура сарае үзешчән сәнгать коллективы составында, Туймазы районы колхозларында булып кайттылар.

Ш. Бикчурин һәм Лениногорскидагы әдәби берләшмә членнары Чыршылы авылында үткән яшь терлекчеләр слетында чыгыш ясадылар.

●

РСФСР Язучылары союзы идарәсе 6 сентябрьдән 16 сентябрьгә кадәр Чита шәһәрендә Ерак Көнчыгышта һәм Көнчыгыш Себердә яшәүче яшь язучыларның семинарын үткәрде. Семинар эшендә, поэзия группасы җитәкчесе буларак, РСФСР Язучылары союзы правлениесе секретаре С. Хәким дә катнашты.

———●●●———

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

**«КАЗАН УТЛАРЫ»** журналы татар совет әдәбиятының барлыкка килүе һәм үсеш тарихы белән аерылгысыз бәйле. Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Гафури, Һ. Такташ, К. Тинчурин, М. Җәлил, Ф. Кәрим, К. Нәҗми, Ә. Фәйзи кебек атаклы язучыларның әсәрләре беренче булып шушы журнал битләрендә күренде.

Журнал үз тирәсенә республикабызның иң яхшы әдәби көчләрен туплады. «Казан утлары» журналы битләрендә С. Хәким, Х. Туфан, Ә. Давыдов, Ш. Галиев, З. Нури, З. Мансур, Г. Афзал поэмалары һәм шигырьләре; Г. Бәширов, И. Гази, М. Әмир, Ф. Хөсни, Ә. Еники, А. Расих, Г. Әпсәләмов, Г. Ахунов, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев хикәяләре, повестьлары һәм романнары; Н. Исәнбәт, Р. Ишморат, Х. Вахит пьесалары, шулай ук башка бик күп шагыйрьләрнең, прозаикларның һәм драматургларның иң уңышлы әсәрләре басылып килә. 1966 елда журналыбыз тагын да эчтәлеклерәк, кызыклырак, баерак чыгачак. Яңа елда безнең журналда сез А. Расихның «Каһарманнар юлы» исемле яңа романы, Г. Гобәй, И. Гази, Г. Бәширов һәм А. Гыйләҗевларның яңа повестьлары, күп санлы хикәяләр, поэмалар һәм шигырьләр, пьесалар белән таныша алачаксыз.

**«КАЗАН УТЛАРЫ»** илебездәге иң өлкән, киң танылган әдәби журналларның берсенә әйләнде. Күләме ун табаклы бу журналның тиражы хәзер 20.000 гә җитте. Ләкин җирле халыкта журнал турында төпле мәгълүмат булмау сәбәпле, Татарстанда һәм бигрәк тә республикадан читтә яшәүче бик күп әдәбият сөючеләр «Казан утлары» журналына язып алмыйлар, татар совет язучыларының яңа әсәрләрен укый алмый калалар.

Менә **«КАЗАН УТЛАРЫ»** журналының 1965 елның беренче январена ничек таралуын күрсәткән таблица:

| Тәртип №№ | Республикалар, өлкәләр | Татарлар саны 1959 ел (меңнәрдә) | Журнал тарала | |
|---|---|---|---|---|
| | | | барысы | татарлар арасында 1000 кешегә |
| | СССР | 4968 | 19246 | 3,8 |
| | РСФСР | 4074 | 17245 | 4,3 |
| 1 | Татарстан | 1345 | 8781 | 6,5 |
| 2 | Башкортстан | 769 | 4217 | 5,5 |
| 3 | Пермь | 166 | 870 | 5,2 |
| 4 | Свердловск | 158 | 712 | 4,5 |
| 5 | Оренбург | 121 | 417 | 3,4 |
| 6 | Кемерово | 67 | 354 | 5,3 |
| 7 | Чиләбе | 130 | 347 | 1,8 |
| 8 | Ульяновск | 97 | 218 | 2,2 |
| 9 | Куйбышев | 74 | 161 | 2,2 |
| 10 | Төмән | 72 | 158 | 2,2 |
| 11 | Удмуртстан | 72 | 122 | 1,7 |
| 12 | Красноярск | 34 | 122 | 3,6 |
| 13 | Киров | 41 | 77 | 1,9 |
| 14 | Чувашстан | 31 | 68 | 2,2 |
| 15 | Курган | 20 | 66 | 3,3 |
| 16 | Мәскәү | 133 | 65 | 0,5 |
| 17 | Сахалин | 12 | 59 | 5,0 |
| 18 | Пенза | 62 | 50 | 0,8 |
| 19 | Горький | 67 | 46 | 0,7 |
| 20 | Астрахань | 57 | 42 | 0,7 |
| 21 | Новосибирск | 25 | 42 | 1,7 |

*Дәвамы*

| Тәртип №№ | Республикалар, өлкәләр | Татарлар саны 1959 ел (меңнәрдә) | Журнал тарала | |
|---|---|---|---|---|
| | | | барысы | татарлар арасында 1000 кешегә |
| 22 | Саратов | 34 | 36 | 1,1 |
| 23 | Томск | 13 | 35 | 2,7 |
| 24 | Иркутск | 39 | 24 | 0,6 |
| 25 | Чита | 12 | 16 | 1,3 |
| 26 | Камчатка | 4 | 12 | 3,0 |
| 27 | Омск | 36 | 11 | 0,3 |
| 28 | Ростов-Дон | 14 | 11 | 0,9 |
| 29 | Тула | 15 | 11 | 0,7 |
| 30 | Бурятия | 8 | 11 | 1,4 |
| 31 | Мордовия | 39 | 9 | 0,2 |
| 32 | Ленинград | 32 | 7 | 0,2 |
| | Калган өлкә, республикалар бергә | 226 | 70 | 0,3 |
| | **СОЮЗДАШ РЕСПУБЛИКАЛАР** | | | |
| 1 | Казагыстан | 192 | 748 | 3,3 |
| 2 | Үзбәкстан | 445 | 496 | 1,1 |
| 3 | Таҗикстан | 57 | 321 | 5,6 |
| 4 | Кыргызстан | 56 | 224 | 4,0 |
| 5 | Украина | 62 | 133 | 2,1 |
| | Луганск | 14 | 62 | 4,4 |
| | Донецк | 24 | 62 | 2,6 |
| 6 | Төркмәнстан | 30 | 67 | 2,2 |
| 7 | Әзербәйҗан | 30 | 6 | 0,2 |
| 8 | Белоруссия | 9 | 2 | 0,2 |
| 9 | Эстония | 2 | 2 | 1,0 |

Таблицага карап, Сез үзегез дә күп нәрсә турында хөкем йөртә аласыз. Илебездә якынча 5 млн. татар халкы яши. Журналның тиражы исә 20 000 данә. Билгеле, бу сан гына бик аз әле. Башка милләт, әйтик, төрки халыклары әдәби журналларының халык санына чагыштырмача тиражын исәпләп карасаң, бу санның, чыннан да, аз икәненә инанасың.

Мәскәү, Чиләбе, Ульяновск, Горький һәм Төмән кебек зур промышленность үзәкләренең һәрберсендә 80 меңнән алып 200 меңгә кадәр татар бар. Бу өлкәләрдә яшәүче татар халкына «КАЗАН УТЛАРЫ» бик аз барып җитә. Чиләбе өлкәсендә һәр 1000 кешегә 1,8 данә журнал, Горький өлкәсендә —0,7 данә, ә инде Мәскәү өлкәсендә һәр мең кешегә ярты журнал гына туры килә. Төркмәнстан һәм Үзбәкстан республикаларында яшәүче татар халкының да иң зур күпчелеге «Казан утлары»н укудан читтә кала.

Башка елларда кайбер укучылар, теләп тә, «Союзпечать» эшчеләренең игътибарсызлыгы аркасында, журналга язылa алмыйча калалар иде. Хәзер «КАЗАН УТЛАРЫ» журналы Бөтенсоюз каталогына кертелде. Аңа илебезнең һәрбер почта бүлегендә, «Союзпечать»ның һәрбер агентствосында чикләүсез язылырга мөмкин.

**Хөрмәтле укучыларыбыз! Редакция Сездән «КАЗАН УТЛАРЫ» журналын укучылар арасында киң күләмдә пропагандалавыгызны үтенә, үзегез язылу белән бергә, иптәшләрегезне һәм туганнарыгызны да «КАЗАН УТЛАРЫ»на язылырга өндәрсез дип ышана. 1966 елда журналны таратуда иң югары күрсәткечләргә ирешкән иптәшләргә һәм почта эшчеләренә редакция истәлекле бүләкләр җибәрәчәк.**

**Әгәр урыннарда, нинди дә булса сылтау белән, журналга язмасалар, турыдан-туры редакциягә хәбәр итүегезне үтенәбез.**

*«Казан утлары» журналы редакциясе.*

**ӘДҺӘМ ГАЙНЕТДИНОВ**
музыкасы

**ЗӘКИ НУРИ**
сүзләре

**Александр Ключарев**
*редакциясендә*

Бу сүздә берләшә бердәмлек, кыюлык,
Иң матур җыр итеп җырлыйбыз без аны,
Язылды йөрәккә мәңгегә уелып:
Яшәсен Партия — чорыбыз вөҗданы!

Партия җитәкли, партия — юлбашчы.
Тик шулай беләбез барчабыз аны без.
Ул — безнең теләкләр, өметләр кояшы,
Ул — безнең үлемсез һәм сүнмәс
данлыбыз.

Дөреслек сүзенең, гаделлек сүзенең
Күңелләр кырына чәчә ул орлыгын.
Күрәсең син, иптәш, бу сүздә үзеңнең
Эшең дә, көчең дә, хисең дә зурлыгын.

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Әмирхан Еники, Ибраһим Гази, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 11/IX-1965 ел. Басарга кул куелды 1/XI-1965 ел. ПФ 08168. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 13,49. Басма табак 10(14). Тираж 20 500 экз. Заказ Л-1195. Бәясе 40 тиен.

Татарстан АССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19. 1965 ел.

# ПАРТИЯ



Бу сүз-дә бер-лә-шә бер-дәм-лек, кы-ю-
лык, иң ма-тур жыр и-теп
poco crescendo
жыр-лый-быз без а-ны Я-зыл-ды йө-рәк-
poco dim
кә мәң-ге-гә у-е-лып.
Я-шә-сен пар-ти-я — чо-ры-быз вež-да-
ны.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс
73367

*Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал*

**КАЗАН УТЛАРЫ**

*(Огни Казани)*

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ